PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2021 МАРТ № 3

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

киявгә чыгаргамы, юкмы
КЫЗЛАР нигә ашыкмый

ДАНИР САБИРОВ
мин идеаль ир

борай, СУДАК ҺӘМ КОРТ
өр-яңа тәмнәр

Ләйлә ФАЗЛЫЕВА:
«Бәхетле хатын-кызның күзләре балкып тора».

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!



Фото: Анна Арахамия

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА

АҺ, БАЛАМ!..

Тирә-якта дус бар, дошманым бар,
Тормыш дәрьясында чайкалам.
Кемгә кирәк соң мин дип уйлыйм да
Көфер уйны куып тукталам:
– Аһ, балам!

Нинди матур минем дөньям, димен,
Ай-кояшка карап сокланам.
Шөбһәле төш күреп уянсам да,
Зиһенемнән читкә аткарам:
– Аһ, балам!

Күләгәләр кунса күзләремә,
Күзге көнгә сылтап акланам.
Төн карасы көнне каплаганда
Бер уй белән бары ак калам:
– Аһ, балам!

Айкалганда тормыш дәрьясында,
Кем соң мине исән саклаган?
Күпләр белгән гади хакыйкатьне
Өр-яңадан ачып шатланам:
– Аһ, балам!

■ Минем әтием – татар, әнием – керәшен. Ике якның да йолаларын үтәп яшибез. Һәр язны Пасхага бер көн кала әбиләргә – Әлмәт районы Кәләй авылына бара идек. Бәйрәм көнне иртүк торып, йомырка җыярга чыгып китәбез. Төрле төстәге бер капчык йомырка җыеп кайтуның күңеллелеген белсәгез!.. Әбием инде исән түгел, ләкин балачак хатирәләре – күңел түрендә. Үзем әни булгач, балаларыма шушы гореф-гадәтне җиткерергә теләп, ел саен Пасхада йомырка буйый башладым. Бу бәйрәмгә әзерләнүебез миңа шундый кадерле! Әбием, әнием белән рухи бер бәйләнеш кебек...

Лилия Заһидуллина. Казан.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Ләйлә Фазлыева
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр
Ильмира Сөләйманова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 26.02.2021 ел.
Чыгу көне: 4.03.2021 ел.
Заказ Е-630
Тираж 10410

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.


Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Россиядә: ПО279 (берьеллык)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Мәдияр Һажиев эше

Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Бүгенге җәмгыятьтә хатын-кызның урыны дигән темага багышланган телевизион тапшыруда яңгыраган бер фикер шактыйдан тынгы бирми. Студиягә шалтыраткан бер ир-ат: «Хатын-кызның урыны билгеле: өйдә утырсын», – дип шаккаттырды... Мин үзем феминизм сүзен яратмыйм, гомумән, кабул итмим. Уйлап чыгарылган кебек тоела ул. Феминизмны кемдер XIX гасыр көнбатыш җәмгыятендә күрә, кемдер амазонкаларны искә төшерә. Ә мин узган гасырның 90 нчы елларына кайтам. Барысы да истә... Илдә – кризис, эшсезлек, эш урыны булганнарга да хезмәт хакы түләнми. Эшсез калган ирләрнең шактые шул вакыт эчүгә сабышты, кемдер якты дөнья белән үк хушлашты... Ул чактагы баш мөхәрриребез Роза ханым Туфитуллованың безгә: «Өйләрегезгә кайткач, ирләрегезгә акча юк дип бәйләнмәгез. Аларга да җиңел түгел, ир-ат та бүген ярдәмгә мохтаҗ. Бөтен ил шушы хәлдә», – дип искәртеп торуы да хәтердә... Әйе, хатын-кызга көчлерәк булырга туры килде. Ул беренче чиратта балаларын ашату, киендерү, укыту турында уйлады. Эшсез калган гүзәл затларыбыз шакмаклы зур сумкалар асып, читтән товар ташыды, аны яңгыр, кар, эссе кояш астында базарда сатып торды. Барысына да җитешер өчен машина руле артына да утырды. Шул ханымнардан бизнес-леди дигән катлам үсеп чыкты. Хатын-кызлар зур сәясәткә килеп кушылды. Алар хәзер хакимияттә: трибуналардан үз фикерен җиткерә, мөһим карарлар кабул итүдә катнаша... Бүгенге хатын-кыз тәвәккәл, кыю, тырыш, өлгер... Әмма беренче чиратта ул барыбер хатын-кыз! Җылыга мохтаҗ гап-гади хатын-кыз... Илсөяр Иксанованың үзем эчтән гел кабатлап йөргән шигырь юлларын яныбыздагы көчле затларның тагын бер кат исләренә төшерәсем килә.

Без бит Алма.
Аңла:
Алма – татлы,
җылы тойса,
Алма – ачы,
суык тисә...

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнең тышлыкта

«...Миңа күп вакыт хатын-кыз сыйфатларым дөрес юл табарга булыша. Шуңа күрә социаль мәсьәләләр белән хатын-кызлар күбрәк шөгыльләнәдер.»



6 Мин – төрле
Лариса Маликова

Заман һәм без

10 Алкышларыбыз, рәхмәтләребез Сезгә!

16 Ялгыз сәяхәтче
Гөлнур Хәсәншина

13 Химик буласы язмышына язылган
Фәнзилә Мостафина

18 «Ашыкмыйм, котәм генә»
Чулпан Галиәхмәтова



12 «Көчле буласым килә, дидем...»
Фәнзилә Мостафина





22 «Идеаль ир булу өчен янәшәдә идеаль хатын кирәк»
Чулпан Галиәхмәтова

Татар дөньясы



24 Төпчек малай
Чулпан Галиәхмәтова

Мәдәни тормыш



30 Кулга-кул тотынса...
Алия Рәхимова

34 Куян мамык бияләй
Рамил Ханнанов



38 Утраудагы утар уртасында...
Роза Хәмидуллина, Рушания Гыйләҗева.

Яшәеш



44 Хатын-кызга ни җитми?
Гөлнур Сафиуллина



48 «Биш балам – биш бәхетем»
Фәридә Вилданова

Хуҗабикә

55 Хайлайтерны дөрес кулланабыз

58 ЭКО-дизайн
Лилия Гәрәева



60 Борай, судак һәм...



Хобби: кулинария, фитнес
Кредо: кәеф никадәр начар булса, үкчә шулкадәр биегрәк.
Яраткан десерт: әбием әзерләгән «Наполеон» торты. Әмма аның рецептын кабатлый алмыйм. Һич аныкыча килеп чыкмый.

МИН – ТӨРЛЕ

Без интервьюны берничә тапкыр күчергәннән соң, ниһаять, ял көнне – 23 февральдә очраштык. Танышуыбыз фотостудиядә башланды. Әңгәмәдәшем әле генә тәмамланган митингтан соң килде. Сөйләшүебез машинада дәвам итә. Интервью башланмаган, диктофон әле кабынмаган. Ә язманың беренче юллары инде күңелдә языла бара... Бервакыт аңа поездда командировкага барырга туры килә. Юлдашлары инде купеда икән.
– Бәхетегез – мин Сезнең белән барачакмын, – дип сәламли ул үзенә хас юмор белән. Аннары телефон аша лекцияләр расписаниесен үзгәртә башлый.
– Сез укытучымы әллә? – дип кызыксына күршесе.
– Әйе, – дип җавап бирә ул.
Әдәп кагыйдәсе буенча, бүген монысын да сорашу кирәк бугай...
– Казанда коронавирус белән хәлләр ничек?
Җаваптан соң, ир кеше шундый нәтиҗәгә килә:
– Юк, сез укытучы гына түгел...
Әйе, әңгәмәдәшебез укытучы гына түгел, ул – Татарстан Республикасының вице-премьеры, COVID-19 вирусы белән көрәшүнең оператив штаб җитәкчесе, балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе рәисе Ләйлә Ринатовна ФАЗЛЫЕВА.
Без барыбыз да – балачактан. Һәм бүгенгебез – ерактагы якын балачакта салынган... Шуңа күрә сөйләшү барышында балачакка да кайтып-кайтып килербез...

Фото: Анна Арахамия



Лариса
МАЛИКОВА

Педагог

«Балачакта аюларым, курчакларым ни өчендер һәрвакыт парта артында утыра иде. Минем хәтта кечкенә грифель тактам да бар. Анда акбур белән язам. Нәрсәдер сөйлим, аңлатам, нәрсәләрдер кисәм, җилем белән ябыштырам, укучыларыма күрсәтәм. Класс журналы да бар, әлбәттә.
Укучыларым «бишле» алса, сөенәм, «икеле»ләргә көенәм.
Беренче педагогик тәҗрибәм шушы иде».

МӘКТӘП • Педагогика, гомумән, мәктәп белән бәйле бар нәрсә – искиткеч тәҗрибә, минемчә. 6 яшьтә башланган «педагогик тәҗрибәм» мәктәптә берничек тә өзелмәде: пионервожатый булдым, түбән класс укучылары белән әвәрә килергә яраттым. Укытучыларыма рәхмәт: миндә педагог сыйфатларын күреп алып, аларны һәрьяклап үстерделәр. Алар мәктәптәге үзидарә көннәрендә дәресләр алып барырга, дәфтәрләр тикшерергә дә рөхсәт иттеләр. Минем өчен болар әйтеп бетергесез шатлык иде. Нинди эшкә тотынсам да, әти белән әни мине һәрчак үсендереп торды, ирек бирде: скрипкада уйныйсың киләме – рәхим ит, укытасың киләме – укыт, әдәбиятны яратасыңмы – укы... Алар мине беркайчан да чикләмәде. Холкым формалашуда исә шулай ук класс җитәкчебез, гаҗәеп педагог, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Людмила Дмитриевна Грезинаның өлеше зур. Ул миннән лидер тәрбияләде. Нәкъ менә Людмила Дмитриевна миңа рус теленең байлыгын, гомумән, филология, әдәбият дөньясын ачты. Ул фантазиягә бирелергә, иҗат итәргә, төрле әйберләр уйлап чыгарырга мөмкинлек тудырды. Миңа филологиягә кагылышлы сораулар, текстны тоемлау, нейролингвистик программалаулар бик ошый, һәм бүгенге көнгәчә шулар белән шөгыльләнәм: бу темага бик күп укыйм. Казан лингвистика мәктәбе вәкиле булуым белән горурланам. Минем бәхетемдер: барлык укытучыларым да тирән белемле, зыялы кешеләр, үз эшләренең чын осталары иде. Шундый остазлар барында ничек укытучы булмый каласың?! Ә аннан университетка укырга кердем. Филология, тел, әдәбият кафедрасы укытучыларым – үзе бер дөнья. Минем морфологиядән генә «дүрт»ле иде. Уку бик ошый, һәм башка билге алырга хакым да юк кебек иде! III курста укыган чакта ук мәктәптә дә укыта башладым. Укыту белән бәйле эштән бүгенге көнгәчә рәхәтлек кичерәм. Төрле курслар, шул исәптән, «Эшлекле этикет» буенча да лекцияләр укыйм. Коммуникация, эмоцияләр, эмоциональ интеллект үзенчәлекләре турында ул. Студентлар миннән өйрәнә, мин – алардан. Туплаган белемнәремне, тәҗрибәмне бик рәхәтләнеп аларга бирәм.

ГАДЖЕТЛАР • Информацион кырны, мәгълүмат агышын тамырдан һич тә үзгәртә, юкка чыгара алмыйбыз инде. Һәркем – ата-аналар да, балалар да үз гаджетларында утыра бүген. Педагогика кануннары буенча, ситуацияне үзгәртүне безгә – өлкәннәргә үзебездән башларга кирәк. Көнебезне күз алдыннан үткәреп, гаджетлардан ничә сәгать һәм нинди максатларда файдалануыбызга анализ ясарга кирәк безгә һәм балаларыбызның да аларны ничек кулланганын күзәтергә. Без – ата-аналар һәм укытучылар – шушы социаль челтәрләрдә нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен бала белән бергә анализлауга өйрәнергә тиеш: нәрсәне, нинди максатлар белән карыйбыз, ни өчен арыйбыз... чаманы югалтабыз... Бала яхшыны яманнан аерырга өйрәнсә, проблемалар кимер иде.
Аның нидер белән мавыгуын әти-әнисе вакытында күреп, үстерә ала, шул исәптән, социаль челтәрләрдә дә. Мәсәлән, кайбер әниләр балалары белән бергәләп нидер ясыйлар да, шуны социаль челтәрләргә куялар. Кызыклы постлар бик күп. Шулай итеп, балаң белән икегезгә уртак бер шөгыль тудыра аласыз.

БАЛАЛАР • Хәзер үзара аз сөйләшәбез. Бик аз! Балаларыбыздан киңәшне сирәк сорыйбыз. Әмма юкка! Ә бит алар безне аңларга, киңәш тә бирергә әзер. Кызганыч, еш кына балалар гаиләдәге кыерсытуларга да түзә, хәтта үзләренең шундый әти-әниләрен яраталар да. Димәк, алар бу очракта безгә караганда күпкә мәрхәмәтлерәк. Балаларны рәнҗетергә ярамый. Ләкин балаңны ак-караны аермаслык дәрәҗәдә үсендерү – яратуга күмү дигән сүз түгел әле.

Соцблок

«Әбием һәрвакыт миңа, барысы да көйләнер, бар да яхшы булыр, әйдә, утыр да аша, дия торган иде...
...Кар атышып уйнау. Ике төркемгә бүленәбез, ничек тә каршы якны җиңәргә кирәк. Чалбарлар, курткалар бозланып ката, ә без барыбер җиңүгә омтылабыз...
...Гаиләбез 1986 елда Казанга күченде. Әти хәрби кеше булгач, артиллерия шәһәрчегендә яшәдек. Офицерлар училищесы ашханәсендә колбасадан пешерелгән борщны хәтерлим. Ул вакыттагы тормышның авырлыгын, минем бар әйберем дә булсын өчен әти-әниемнең ничек тырышуларын нәкъ менә шул тәм искә төшерә. Тагын бер хатирә... анысын искә төшерәсем дә килми. Бервакыт пионер лагеренда бөтен отряд белән конфликтка кердем. Үземне хаклы итеп тойдым. Хәзер аңлыйм, аралашу дөньясы бик катлаулы ул. Бу хәл мине күп нәрсәгә өйрәтте, минем өчен бик яхшы сабак та булды...»

«КУЛГА-КУЛ ТОТЫНЫШЫЙК, ДУСЛАР!» ФЕСТИВАЛЕ • Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен оешмалар Казанның Совет районында башкаларга караганда күбрәк. Шуңа анда тәрбияләнүчеләр – балалар да, өлкәннәр дә өчен фестиваль үткәрү идеясе туды. Яңа ел алдыннан оештырылды ул. Могҗизалар вакыты бит! Бүгенгәчә истә. «Шәп чыгыш ясаган өчен Яңа елда нинди бүләк аласың килә?» – дип сорадым бер кыздан. Зур матур алкалар турында хыяллана икән. Җавап мине сискәндерде – бәхет өчен күп кирәкми икән бит!..

Фестивальнең дуслары күп – артистлар, депутатлар, бизнесменнар, төрле һөнәр ияләре игелекле эш тирәли берләште. Балалар психоневрология интернатында тәрбияләнүчеләрнең чыгышын фестивальнең гаҗәеп



уңышы дип саныйм: сөйләшә дә алмый дип әйтерлек балалар катлаулы җыр башкара. Бу вакыттагы хисләрне сүзләр белән әйтерлек түгел.

Минем өчен «Кулга-кул тотынышыйк, дуслар!» – социаль блок вәкиле булып өлгерүемнең тагын бер этабы. Әлеге чараны уздыруга рухландырган коллегаларыма, хәзер инде республика статусына ия фестиваль белән бүгенгәчә бергә калган игелекле кешеләр командасына рәхмәтлемен.

«СИДЕЛКА» ПРОЕКТЫ • Ул «Демография» милли проекты кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан тормышка ашырыла. Барыннан да бигрәк үз-үзен карый алмаучы һәм читләр ярдәменә мохтаҗ кешеләргә булышу ихтыяҗы белән бәйле ул. Әлеге проектның киләчәге бар, һәм ул алга таба да үсәчәк дип уйлыйм.

ТӘРБИЯГӘ БАЛА АЛГАН ГАИЛӘЛӘР • Мондый гаиләләр мөмкин кадәр күбрәк балалар интернат тибындагы оешмаларда яшәмәсен, ә гаиләдә кайгырту һәм җылы тапсын өчен кирәк. Кызганыч, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә көч куллану очраклары бар. Килешәсездер, гадәти гаиләләрдә дә бар да ал да гөл түгел бит. Шуңа күрә опека органнары тәрбиягә алган гаилә белән бер бөтенгә әйләнергә тиеш. Барлыкка килгән яңа гаилә үзенә бикләнеп яшәми. Балалар яшьтәшләре белән аралаша, бакчага, мәктәпкә йөри. Гаиләнең күршеләре, дуслары бар. Мондый гаиләдәге хәлләрне кайчак опека органнарына нәкъ менә янәшә яшәүчеләр хәбәр итә. Кыерсыту очраклары расланса, әлеге гаилә белән килешү шундук өзелә. Әти-әниләр өчен әһәмиятле булган күнекмәләр һәм белем бирү өчен республикада тәрбиягә бала алучы әти-әниләр мәктәбе эшли. Тәрбиягә балалар алып, аларны аякка бастырган, укыткан искиткеч гаиләләр бар, алар балаларының ирешкән уңышлары белән ихлас горурлана.

АВЫР ҮСМЕРЛӘР • Алар булган, бар һәм булачак. Ул үсмерләрне криминаль үткәннәрдән йолып алып, әйбәт кеше итеп үстерү – уртак бурычыбыз. Хәзер түгәрәкләр, секцияләр, үсмерләр клублары системасы яңартыла. Бу аларны җинаятьләрдән аралап калу өчен үткәрелә торган профилактик чара. Үсмер ялгыш юлга баскан очракта инде икенчел профилактика үткәрергә туры килә, ләкин аңа каты бәрелмәскә генә кирәк. Алга таба инде аның тормыш сукмагын бер эзгә салырга булышу сорала. Республиканың балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе һәм бу юнәлештә урыннарда эшләүчеләр алкоголь һәм тискәре күренешләргә китерүче психоактив матдәләр куллануга каршы профилактикага игътибар итәргә тиеш. Татарстан Республикасының террорга каршы комиссиясе һәм балигъ булмаганнар белән эшләү комиссиясе, Мәгариф һәм Яшьләр министрлыклары, психологик ярдәм күрсәтү оешмалары белән берлектә, үсмерләргә куркыныч яный торган тискәре йогынтылы контент һәм начар социаль челтәрләр белән көрәшә. Бу эштә әтиләр комитеты, әниләр советы кебек иҗтимагый оешмалар да мөһим роль уйный: мәсәлән, бүген блогер әниләр берлекләре популяр. Иң мөһиме – профессиональ булмаган һәм үз инстаграмнарын бик оста үстереп, компетентлы булып күренсәләр дә, чынлыкта бу өлкәдә берни белмәүче кешеләр фикереннән качарга кирәк. Психологик хезмәт күрсәтү үзәкләренә, ышаныч телефоннарына, мәктәптәге педагогларга ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә була. Авыр үсмерләр – игътибар җитмәгән үсмерләр. Мин шулай уйлыйм.

КОРОНАВИРУС • Ел, гомумән, бик катлаулы булды, иң катлаулысы язга туры килде. Моңарчы күрелмәгән, таныш булмаган, аңлашылмаган хәлгә тарыдык. Бөтен дөнья билгесезлектә... Нәрсә ул коронавирус, аның белән ничек көрәшергә икәнен беркем белми. Рөстәм Нургалиевич бөтен карарларны белгечләр – эпидемиологлар, вирусологлар, сәламәтлек саклау министрлыгы, икътисадчылар, финансистлар – белән узган киңәшмәләрдән соң гына кабул итте. Һәр адым уйланылган, үлчәнгән иде. Татарстанның үз эшчәнлеген оператив рәвештә маскалар һәм антисептиклар җитештерүгә көйләгән, маскалар өчен тукымалар җитештерү күләмен арттырган предприятиеләр, профильле министрлыклар һәм ведомстволар командалары актив эшләде. Бу Татарстан Президенты җитәкчелегендәге команданың дәвамлы һәм тәүлекләр буена сузылган эше булды һәм әле дә шулай дәвам итә.

Чит илләрдән кайтучы гражданнарыбыз белән эшләү катлаулы булды дияргә мөмкин: көндез һәм төнлә аэропортта ике-өч рейс каршылау, коммуникацияләр, бу чорда махсус ачылган обсерваторияләргә урнаштыру... Кайтучыларның бөтенесе дә моның белән килешеп бетмәде. Ләкин бу процедура кирәкле, мөһим иде. Ул яңа коронавирус инфекциясенең кинәт таралу мөмкинлеген киметте. Сәламәтлек саклау учреждениеләре аерым режимда эшләде, табиблар тәүлек әйләнәсе татарстанлыларның гомере һәм савыгуы өчен көрәшеп, оператив төстә квалификация күтәрү курсларын узды, клиник рекомендацияләрне үзләштерде. Безнең медиклар бүген дә постта.

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин боерыгы белән регионда балалы гаиләләргә түләүләр оештырылды. Татарстанда «Ярдәм янәшә» хәйрия чаралары уздырылды. Изоляциянең барлык проблемаларын бергәләп җиңә бардык, бер-беребезгә ярдәм иттек, дистантны үзләштердек, иртәнге термометриягә, битлек режимына ияләштек. Соңгы ике яңалык белән безгә әле яшәргә туры килер.

2020 елның көзе шулай ук катлаулы иде, ләкин бернигә карамастан, команда рухы җиңде.

Штаб бүген дә эшли, бурычлар бераз үзгәрә, ләкин барлык мәсьәләләрне без белгечләр белән берлектә оператив хәл итәбез. Хәзерге вакытта штабтагы төп эшебез Татарстан халкына ихтыяри вакцинация ясауга юнәлтелгән. Штаб көн дә COVID белән бәйле барлык шикаять һәм кимчелекләргә, халыкның киңәштәкъдимнәренә мониторинг уздыра, Роспотребнадзор, Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре, социаль хезмәт

күрсәтүчеләр COVIDның таралуына юл куймас өчен өзлексез режимда эш алып бардылар. Кайчагында безгә дөрес булмаган мәгълүмат белән дә көрәшергә туры килде, ләкин теләсә кайсы юлны бары тик баручы кеше генә үтә ала.

Хатын-кыз

«Әтием дә, әнием дә, әбием дә һәрчак: «Син матур, бер җитешмәгән җирең юк, син иң әйбәт кыз», – дип иркәләп-назлап, чын хатын-кыз итеп үстерделәр...»

ГАИЛӘ • Миңа һәрвакыт, хатын-кыз өчен иң мөһиме – әни булу, ир хатыны булу, дип әйтә килделәр. III курста кияүгә чыктым, диплом яклап йөргәндә бала көтә идем инде: сентябрьдә улымны таптым. Ирем, улым, гаиләм – минем өчен иң зур тормыш бүләге шул.

ТӘРБИЯ • Мин шәрык традицияләрендә тәрбияләндем. Боларга гореф-гадәтләр дә, бәйрәмнәр дә, зур табыннар һәм бергә әзерләгән ризыклар да керә. Барыбер барысы да балачактан күчә. Әйе, миндә шәрык традицияләре. Шәрык хатын-кызының күндәмлеге – аның зирәклегеннән. Эшем, әлбәттә, миңа тәэсир итми калмый, еш кына мин җитди, кайчак хәтта коры да. Ләкин миңа күп вакыт хатын-кыз сыйфатларым дөрес юл табарга булыша. Хатын-кыз буларак, бу дөньяны саклап калырга телим. Шуңа күрә хатын-кызлар ир-атларга караганда кешеләр белән күбрәк эшли һәм социаль мәсьәләләр белән дә аңа күбрәк шөгыльләнергә туры киләдер. Өйдә мин башка: йомшак. Гаиләдә бит мәхәббәт: син яратасың, сине яраталар. Яратып-яратылып яшәү – бәхет ул.

ФЕМИНИЗМ • Феминизмга берничек тә карамыйм. Хатын-кыз яратылуга лаек дип саныйм. Аның көчсез күренергә дә хакы бар. Шул ук вакытта беләм: үзендә көч сизә икән, ул идарә итәргә дә алына, үз эшен дә булдыра, аны үстерә, уңышлы итә. Иң мөһиме ул бәхетле булсын. Аның бәхетле икәне шундук күренә, күзләре балкып яна башлый. Без һәрвакыт үзебезне яратуларын, безнең белән горурлануларын телибез. Хатынын күз карасыдай саклаучы, аның өчен барлык шартларны тудыручы, яшәргә, иҗат итәргә, үзен ачарга булышучы ирләргә сокланам. Хәзер күп балалы әниләр дә бизнес белән шөгыльләнә, барысына да җитешәләр, алар барысын да булдыра. Бүгенге хатын-кызлар искиткеч: матурлар, үзләрен карап йөртәләр, уңышларга ирешәләр. Алар – фәндә дә, мәдәнияттә дә, мәгариф өлкәсендә дә, производствода да...

ТРАДИЦИЯЛӘР • Гаиләдә төрле буыннар – әби-бабай, әти-әни булса, алар бергәләп балага шул традицияләрне сеңдерә. Минем улыма, мәсәлән, үз мәхәббәтем, әти-әниләремнеке, иремнеке һәм аның әти-әниләренеке салынган.

ЯЛ • Минем өчен аралашу – һәрчак позитив энергия чыганагы. Кеше гаҗәеп бит ул: матур сүзләр белән бер-беребезгә күп нәрсәләр турында сөйли алабыз. Барлык

■ «Улым. Аны чиксез яратам. Холкындагы бөтен үзенчәлекләре белән яратам. Төпле, акыллы, эшчән, барысына да үз тырышлыгы белән ирешергә омтыла – шуның өчен хөрмәт итәм аны. Миңа, әби-бабаларына, минем эшемә хөрмәт белән карый. Эшемдәге проблемаларны аңлый. Кайбер чакта үзе дә миңа үрнәк була. Шуның өчен рәхмәтле мин аңа».



дусларым һәм гаиләм кунак кабул итәргә ятратканымны белә. Яратып һәм матур итеп әзерләнгән табын, музыка... Кунакларыма рәхәтлек тудыра алудан тәм табам. Алар бер-берсе белән аралаша алырлык урын оештырам яки җыеныбызга бер өстәл артында, бик кысан булса да, рәхәт халәттә күңелле итеп утыру җаен табам.

Пешеренергә яратам. Шунда җаным ял итә. Яхшы музыка уйнап тора, үз уйларым белән калам... Туктатмаслар, туйга әзерләнгәндәй пешерә алам. Рус, татар, Европа аш-суларын әзерлим, татар милли ризыклары аеруча әйбәт килеп чыга. Казан инновацион университетындагы коллегалар белән татар кулинариясе серләре турында китап та чыгардык хәтта. Ә манты пешерү минем өчен үзе бер ритуал! Аңа кушыла торган һәрнәрсәгә аерым бер мәгънә салынган! Мәсәлән, укроп, петрушка – яшьлек билгесе; камыр – байлык символы; борыч – активлыкны күрсәтә.

Мунча да яратам мин. Аның белән бәйле бар процедуралар ошый.

ФИТНЕС • Ул фигураны сакларга булыша. Горький паркында йә Черек күлдә зарядка алып барам, инде үз төркемем дә бар. Теләүчеләр кушыла ала. Күнегүләр бик гади. Иң мөһиме – елмаю. Менә шул миңа көч бирә...

...Ләйлә Ринатовнаны тыңлыйм, ә үзем: «Аның тәүлеге ничә сәгатьтән тора икән?» – дип уйланам. Шул минутта ук җавабын да ишетәм. Анысы да балачактан:

– Әбием Роза гел әйтә иде: «Ахыр заман бар да үлеп бетә дигән сүз түгел әле ул. Ахыр заман – барысы да һәммә нәрсәгә җитешә алмый башлау ул...»

Менә ничек! Сез, димәк, ахыр заманны кичектерүчеләрнең берсе булып чыгасыз, Ләйлә Ринатовна...

АЛКЫШЛАРЫБЫЗ,



Зилә ВӘЛИЕВА, Татарстан Республикасының Иҗтимагый палата рәисе, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе.

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы». Менә ничә-мә-ничә еллар инде шушы республика бәйгесе 8 Март алдыннан елның бик тә зур, мәртәбәле вакыйгасына әйләнә дә куя! Юк, берсен-берсе һич тә кабатламый алар! Һәр елның үзенчәлеге бар! Һәр елны ниндидер яңа исемнәр ачабыз, яңа эшләре, ачышлары, уңышлары белән шаккаттырган хатын-кызларга сокланабыз. Күп алар – бала тәрбияләүдәме, эшмәкәрлектәме, фән өлкәсендә дисеңме... Шушы хатын-кызлар традицион бәйгегә яңа сулыш биреп, яңартып торалар.

Коронавирус аркасында көтелмәгән куркынычлар килеп чыкмасын дип, быел зона турларын үткәрмәскә булган идек. Ләкин катнашучылар саны 140 тан да артып китте! Алар – республикабызның төрле районнарыннан, шәһәрләреннән. Ә кылган эшләре, уңышлары белән Татарстанда гына түгел, хәтта еракеракларда да танылырга өлгергән кызлар бар! Мәсәлән, галимнәр, фән юлын сайлаган хатын-кызлар.

Әйе, пандемия яшәешебезгә шактый үзгәрешләр кертте. Һәм хатын-кызлар эшли торган кайсы гына өлкәне алма, шушы авыр чорда алар үзләрен фидакарьләрчә тотты. Больницалардагы барлык медицина персоналы – табиблар, шәфкать туташлары, санитаркалар, «Ашыгыч ярдәм» машиналарын йөртүче ир-атлар – көнне төнгә ялгап эшләде. Социаль учреждениеләрдә, ятим балалар өчен интернатларда, Картлар йортында шулай ук гел хатын-кызлар эшли бит! Ковид йоктыру очракларын киметү максатларында локдаун кертелгәч тә, алар өйләренә кайтмыйча, атналар буена якыннары белән күрешмичә, пациентлары янында калдылар. Тулаем эш урыннарында яшәп калган ханымнар да аз түгел иде. Коронавируска каршы көрәшне тәэмин иткән Оператив штаб тәүлекнең теләсә кайсы вакытында постта иде! Ел хатын-кызы булырга лаек ханымнар арасында сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр, социаль хезмәткәрләр, Роспотребнадзор хезмәткәрләре күренү очраклы түгел. Моңарчы әле игътибардан читтәрәк кала килгән һөнәр ияләре калкып чыкты. Аларның эше никадәр җаваплы, мөһим һәм кирәкле икәнен тойдык без. Роспотребнадзор коллегиясендә дә, Сәламәтлек саклау министрлыгыныкында да хәйран хатын-кызлар сәхнәгә күтәрелде! Аларга Президентның Рәхмәт хатлары тапшырылды. Сокланып утырдым! Акчалары әллә ни булмаса да, шушындый җаваплы эшләргә алынучылар, үз эшләрен чын күңелдән башкаручылар бит алар. Һәм алар бик дәрәҗәле. Авырлыклар күбрәк булган саен, уйламаган җирдән шуларны җиңәрдәй инициативасы да чыгып тора бит аның. Бу очракта да ачык күренде ул. Асылда хезмәт кешесе, аның дәрәҗәсе күтәрелде! Азык-төлек таратуны, өлкән кешеләргә дарулар алып кайтып бирүме, башка төр ярдәмнәрме... «Ярдәм» мәчетендә хәтта җылы ашлар да пешереп ашаттылар! Бизнесвуменнар, хатын-кыз волонтерлар үз мөмкинлекләреннән чыгып, белемнәрен, җан җылысын кушып, беркемне дә ялгыз калдырмаска дигән теләктә эшләде. Күп балалы гаиләләргә аерууча нык ярдәм күрсәтелде. Дәүләт тарафыннан гына түгел, иҗтимагый оешмалар да теләп кушылды бу башлангычка. Кешелеклелек, гуманлылык, мәрхәмәтлелек түгелмени бу?! Җәмгыятьтә инде югалып бара торган әнә шундый кыйммәтләр кабат әйләнеп кайткан кебек булды. Һәм аларның никадәр кирәк икәне аңлашылды. Хәер, ул кыйммәтләр, ул сыйфатлар болай да хатын-кызларда сакланып калгандыр, минемчә. Болар ялтыравыклы глянец журналлар күрсәтә торган төшенчәләр түгел инде. Күлмәк тә, муенса да, алка да түгел... Ә иң кыйммәтлесе, иң кирәклесе! Алка-беләзекләрдән башка яшәп була икән әле. Сәламәтлек киткән чакта менә иң элек җылы сүз кирәк икән, янында сиңа су бирердәй кемдер булу кирәк икән, сиңа тиешле даруны менә хәзер китерәләр дип ышанып көтәрдәй кешеләр кирәк икән!.. Мондый эшләргә алынган хатын-кызларның бәһасе тагын да артты! Шундыйлар «Ел хатын-кызы» исеменә лаек, әлбәттә. Без эш булдыра торган ханымнарны барлыйбыз. Чибәр, зирәк, талантлы, моданы да онытмый алар. Ләкин төп максатлары – үзләрен хезмәтләре аша таныту. Алар төрле номинацияләр аша ачылалар. Бәйгедә катнашучы олы яштәге апаларга да сокланмый мөмкин түгел. ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм иткәндә, әнә шул фидакарьләрнең республикабыз тормышын үзгәртүдә, аны алга җибәрүдә үзләреннән зур өлеш кертүен тирән ихтирам белән искә төшерәбез.

Менә нинди алтын кешеләребез, асыл кызларыбыз бар безнең! Соклануларыбыз, алкышларыбыз, рәхмәтләребез сезгә!





РӘХМӘТЛӘРЕБЕЗ СЕЗГӘ!



Сәрия САБУРСКАЯ,
Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» конкурсы ел саен республиканың социаль-икътисадый үсешенә, мәдәни һәм рухи тормышка, үсеп килүче буынны тәрбияләүгә, гаилә институтын ныгытуга зур өлеш керткән хатын-кызларны барлый. Һәм әлеге конкурс белән кызыксыну артканнан-арта бара. Әни, хатын-кыз, дәү әни буларак кына түгел, иҗади шәхес, лидер, бизнесын үстерүче җитәкче, производствода, авыл хуҗалыгында, башка тармакларда үзен үрнәк итеп күрсәткән хезмәт кешесе булып та ачыла алар. Республика халкы әлеге конкурс аша бу хатын-кызларны белә, таный. Ә катнашучыларның күбесе, үсеш баскычларыннан югары күтәрелеп, үз районнарында, шәһәрләрендә, республикада танылган җәмәгать эшлеклесе булып китә.

Пандемия аркасында узган ел шактый катлаулы булуга да карамастан, кызларыбыз бәйгегә күңел биреп әзерләнәләр, теләп катнашалар. Хатын-кызлар көне алдыннан үткәрелә торган әлеге колачлы конкурс – Татарстан халкы өчен затлы күркәм бәйрәм ул!



Эльмира ЗАРИПОВА,
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры

Коронавирус инфекциясе пандемиясе социаль хезмәткәрләр эшенә җитди үзгәрешләр кертте. Бу катлаулы чорда алар турыдан-туры үз вазыйфаларын гына үтәп калмады, волонтерлар эшен дә башкардылар: татарстанлыларга азык-төлек продуктлары һәм көндәлек кирәк-ярак товарлар тараттылар, дарулар сатып алдылар, шулай ук өлкән яшьтәгеләргә булдыра алганча ярдәм иттеләр. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләргә чын мәгънәсендә эш урынында яшәргә туры килде. Үзизоляция режимының бар кыенлыгы нәзберек хатын-кызлар җилкәсенә төште, чөнки әлеге учреждениеләрдә, нигездә, гел шулар эшли. Алар айлар буе балаларын, гаиләләрен күрмәде, эш аркасында шәхси тормышлары икенче планга күчте. 1000 социаль хезмәткәр, тоташ 14 әр көнлек 7 сменада эшләп, 5000 кешене карады. Үз бурычларын фидакарьләрчә үтәп, социаль хезмәткәрләр чын хезмәт батырлыгы күрсәтте, үз эшләренә һәм ярдәмгә мохтаҗларга тугры булуларын раслады. Нәкъ менә социаль хезмәткәрләрне без табиблар һәм медицина персоналы белән янәшә куябыз. Алар – бүгенге көн геройлары.



Елена КУЗЬМИЧЕВА,
Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе рәисе

Бу бәйге – республикабызда уздырыла торган конкурсларның иң истә кала торганы. Татарстанның төрле шәһәр-авылларыннан килгән хатын-кызларга – үз эшләренең осталарына ихлас рәхмәтләребезне җиткерәбез ул көнне. Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе күп еллар дәвамында әлеге бәйгенең иганәчесе генә булып калмыйча, «Һөнәрем – минем тормышым» номинациясе өчен дә җаваплы. Ул номинация заманыбыз хатын-кызының позитив образын күрсәтә, хезмәт кешесенең ролен күтәрә. Конкурс барышында республиканың төрле тармакларында эшләүче хатын-кызлар җиңүчеләр булганы бар: нефть, химия, АПК, мәгариф, сәламәтлек саклау, машина төзелеше... Безнең кызлар кайда да булдыра! Һәм һәр ел саен җиңүчеләргә карап, горурланып утырасың. Матурлар, талантлылар, сөйкемлеләр!

Республикабызның барлык гүзәл затларын 8 Март – халыкара хатын-кызлар көне белән тәбрик итәм! Бу матур бәйрәм язгы кояшның беренче нурлары кебек – җылы, якты, нәфис. Бәйрәм рухы күңелләрегездә озак саклансын!

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.







PRESSA



«КӨЧЛЕ БУЛАСЫМ КИЛӘ, ДИДЕМ...»

– Дус кызым белән балконга чыксак, завод торбаларын күрә дә: «Хәтерлисеңме, гел шунда эләгү турында хыяллана идең», – ди. Хәтерлим! Хыялланган урында эшли башлаганыма да 21 нче ел киткән инде. Һөнәрем тормышыма әйләнде, – ди «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең «Һөнәрем – минем язмышым» номинациясендә катнашучы Наилә Әхмәтшина.

Тумышы белән Урта Азиядән – Төрекмәнстан ягыннан ул. 1996 елда тарихи Ватанга – Татарстанга күченеп кайтырга карар кылалар. Ире дә, үзе дә – яшь-яшьләр, кызларына нибары яшь ярым. Башта Чаллыда яшиләр, аннары Башкортстанга чыгып китәләр, аннары Әлмәт... Шулай да гомер буена төпләнеп калырлык җир табылмый, күңел барыбер эзләнә.

1997 елда Түбән Кама турында, «Нижнекамскнефтехим» турында ишетәләр. Колонна булып күккә ашкан завод корылмаларын күргәч, Наилә аңлый: ул монда эшләргә тели! Эретеп ябыштыручы булып эшләүче әтисе, кыз бала дип тормый, үзе белән эшенә, төзелешкә алып йөри торган була аны. Эретеп ябыштыруны да ышанып тапшыргалый. Шуңа күрә кыз кечкенәдән укытучы йә табиб булырга түгел, зур җитештерүдә эшләргә хыялланып үсә. Һәм менә бит ул хыялы – каршысында.

– Заводны күрдем дә: «Монда бик көчле кешеләр эшлидер», – дип уйладым. Ә миңа шул җитми бит. Мин дә шулар кебек көчле булам, дидем, – дип искә ала Наилә ханым.

Ире дә Түбән Камада төпләнеп калуга каршы килми. Шулай итеп, Наилә Әхмәтшинаның көчле хатын-кыз булу этабы башлана. Юк, шунда ук заводка эшкә урнаша алмый әле ул. Белем кирәк! Балалар йортына эшкә керә, параллель рәвештә 44 нче һөнәри училищеда, аннары нефтехимия көллиятендә укый. Башта, әлбәттә, курку була. Бернәрсә белми, беркемне белми. Ләкин куркуны тиз җиңә (көчлеләр заводына керәсе бар лабаса!). 2000 елда «Нижнекамскнефтехим»га урнаша.

Кичә генә булган кебек, дип елмая Наилә ханым. 20 ел аз түгел, аркасында саллы тәҗрибә багажы бар инде: «Нижнекамскнефтехим» ветераны» мактаулы исемен йөртә. Бүген ул – синтетик каучук заводының 1508 нче цехында катализатор җитештерүче бишенче разрядлы аппаратчы. «Безнең эш аш кайнату шикелле: башта бер ингредиентны саласың, әзрәк кайнатасың да, икенчесен өстисең, аннары өченчесен», – дип, гади генә







итеп аңлатып та бирә. «Гел-гел бер үк ашны пешерү туйдырмыймы соң?» – дип кызыксынабыз. Ихластан көлә. Без хәзер чынлап та аш бүлмәсендә кайнашкан кебек. «Ю-у-ук. Яңа «рецептлар» буенча да пешерәбез без. Заман бер урында гына таптанмый бит. Безнең җитештерүдә дә яңалыклар кертелеп тора».

Ире Равил дә нефтехимиядә эшли. Олы кызлары медик булыр дип көткәндә (медицина көллиятен кызыл дипломга тәмамлый), геннар үз эшен эшләгәндер, күрәсең – ул да яңа белем үзләштереп, заводка эшкә керә. Насыйп ярын да заводта очрата. Әхмәтшиннарның һәм туган-тумачаларының нефтехимия өлкәсендә хезмәт куйган елларын бергә кушсаң, 200 елдан да күбрәк килеп чыга. Хәзер менә 9 нчы сыйныфны тәмамлаучы уллары да әти-әнисе юлыннан китәргә җыена, «Бу иң әйбәт һөнәр!» – дип әйтә икән. Ә кечкенәләренә 4 яшь. «Безнең киндер сюрприз ул», – дип, нәни кызына карап елмая Наилә ханым. Анысының әле киләчәктә кем буласын уйларга иртәрәк, ләкин көннәрдән бер көнне килеп: «Әти, әни, мин дә сезнең кебек нефтехимия юлыннан китәм», – дисә дә, берәү дә аптырамаячак.

– Буш вакытны да күбрәк «киндер сюрприз» белән үткәрәбез, – ди Наилә Әхмәтшина. Ул гына да түгел, кызлары белән кияве онык та бүләк иткәннәр – тагын бер сөенеч. Елларда бергә җыелышып, иҗади кичәләр оештыралар икән. Кызлары белән уллары гитарада уйный, гаилә белән кушылып җырлыйлар. «Элек фортепианода уйнасам, хәзер синтезатор алдык, аны шыңгырдаткалыйм», – дип, тыйнак кына өстәп куя.

Сөйләшү барышында Наилә Әхмәтшина берничә мәртәбә: «Мин эшемне яратам!» – дип тә әйтеп алды. Сорамаган да килеш, үзе теләгәнгә. Аның яңәшәсендәге бөтен кеше беләдер инде моны. Теге вакытта ук белгәннәр, сизгәннәр:

– Май аеның соңгы якшәмбесендә нефтехимиклар көнен билгеләп үткәндә, дус кызларым чәчәк бәйләмнәре алып килә иде. Әле ул вакытта заводта эшләмим дә бит. Ә хыялда бар! Кызлар да белә, шуңа бу көнне мине дә котлыйлар. И-и сөенә идем ул чәчәкләргә, әйтерсең мин инде шул зур заводта эшлим, әйтерсең бу – минем бәйрәм...

Шуннан соң майның соңгы якшәмбесендә аның өеннән чәчәкләр бер дә өзелми инде.





ХИМИК БУЛАСЫ ЯЗМЫШЫНА ЯЗЫЛГАН

Кешенең язмышын билгеләүдә туган җиренең роле бик зур. Быел «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең «Хатын-кыз – галим» номинациясендә катнашучы Диләрә Равил кызы Фазилова Түбән Камада туып-үскән. Күкләрдә аның язмышына «бу кыз гомерен химия белән бәйләячәк» дип язылган булгандыр.

Хәер, әти-әнисе үрнәген дә онытырга ярамый. Әтисе нефтехимия оешмасында машина йөртүче, әнисе яшелләндерүче булып эшли. Менә шуларны күреп, шәһәр белән бергәләп үсә Диләрә. Шулай да химия белән ныклап кызыксынуы болай башлана: мәктәп программасындагы әлеге фән аның өчен аңлаешсыз, әмма кызыклы була һәм нәкъ менә шуңа күрә ул бу юнәлештә өстәмә белем ала башлый. 11 нче сыйныфны тәмамлагач та Түбән Кама химия-технология институтына укырга керергә була.

Бүген «Нижнекамскнефтехим»ның Фән-технология үзәгендә сополимерларны тикшерү лабораториясе җитәкчесе булган Диләрә Фазилова белән шул көннәрне искә алабыз:



– Институтта бик көчле төркемдә укыдым. 5 нче курста практикага җибәрделәр. «Нижнекамскнефтехим»да яңа гына булдырылган цехка – бутилкаучукны галогенлаштыру цехына эләктем. Бу процесс минем өчен генә түгел, бөтен предприятие өчен яңа иде. Мин шул яңалыкның үзәгендә кайнадым. Диплом эшем дә шушы процессны өйрәнүгә багышланган беренче фәнни эш булды, – дип сөйли ул.

Фән дөньясына кереп китүе дә очраклы түгел. Гомумән, Диләрә Фазилова үзе турында: «Мин – хыяллары тулысынча тормышка ашып бара торган бәхетле кешеләрнең берсе», – дип кабатларга ярата. Институтның соңгы курсында укыганда Казан илкүләм тикшеренү технология университеты (ул вакытта КДТУ) галимнәре килеп укыта башлый. Көчле укучыларны аспирантурага чакыралар. Диләрә өчен тагын бер яңа дөнья – фән дөньясы ачыла.

Дөрес, теләге зур булса да, фән белән тәмләп шөгыльләнергә вакыты гына калмый. Институтны тәмамлагач, производствода да эшли башлый. Анысына да рәхмәтле әңгәмәдәшебез: булачак ире Илнар белән шунда танышалар. Алгарак китеп булса да әйтик: Диләрә диссертация яклагач өйләнешәләр. Бүген Азалия һәм Ралина исемле ике кыз үстерәләр.

«Нижнекамскнефтехим»да Фән-технология үзәге бар. Диләрәнең бик тә шунда эләгәсе килә. Тели белсәң – теләк. Күпмедер вакыттан Диләрә Фазилованы ул үзәккә чакырып ук алалар.

Бүген ул – лаборатория җитәкчесе. Бу вазыйфага озак бардыгызмы, дип сорыйбыз. «Мин бармадым, ул үзе килде. Беркайчан да җитәкче булам дигән максатым юк иде. Фәнни хезмәтемнең нәтиҗәсе инде бу», – дип җавап бирә Диләрә ханым.

Диләрә Фазилова җитәкли торган лабораториядәге зур проектларының берсе – «яшел шина»лар өчен каучукка катализатор рецептурасы табу. «Яшел шина» резинаның төсенә карап түгел (анысы, әлбәттә, кара), экологик куркынычсыз булганы өчен шулай аталган. Мондый шиналар гадәтиләренә караганда озаграк хезмәт итә, куркынычсызрак та, ягулыкны да азрак «ашый». Хәзерге вакытта «Нижнекамскнефтехим» каучукның яңа маркасын чит ил җитештерүчеләре заявкалары буенча әзерләп җибәрә. Эшләрен бәяләгәннәр: «Нижнекамскнефтехим» республика конкурсында яңа СКДН 44М1 маркасын уйлап тапкан өчен «Инновацияләр лидеры» исеменә лаек булган Диләрә Фазилова «Сыйфат отличнигы» Мактау билгесе белән бүләкләнгән. 2020 елда галимә «Россиянең профессиональ инженерлары» бәйгесендә «Химия» номинациясендә җиңү яулаган.

Химик булса да, беренче чиратта Диләрә Фазилова – хатын-кыз. Минем өчен гаиләм – бөтен нәрсәнең үзәге, ди. Һәм янә бәхетле булуын әйтә: иртән яраткан эшенә бара, кич яраткан гаиләсенә кайта. Кызларына «Химик-экспериментатор» дигән уен алып биргән. Буш вакытта химик булып уйныйлар: төрле реакцияләр уздырып мәш киләләр икән.

Гаиләсеннән һәм фәннән кала, җирне ярата ул. Шәһәр кызы булса да, бала чагы авылда үткән (әтисе – Түбән Каманың Югары Чаллы авылыннан, әнисе – Нурлат якларыннан). Укытучы әбисе аңарда мәхәббәт тәрбияләгән: белемгә, фәнгә һәм җиргә. Быел дача алганнар. Сезон башлангач, бакчада кайнаша башлау турында хыяллана Диләрә ханым.

Химиктан бәхет формуласын сорамый калып булмый. «Серотонин +...» кебегрәк җавап көткәндә, Диләрә Фазилова бөтенләй башка формула әйтә. «Эшең белән гаиләң арасында гармония булса, бер-берсен тулыландырып торсалар, чын бәхет инде ул!»

Фәнзилә МОСТАФИНА







Фото: Александр Ильин



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

МАЛАДИСЛЫК

Бүген һәркем үзен текә итеп күрсәтергә тели. Әнә шул «крутой»лыгын күреп соклануларын, «Маладис!» – дип әйтүләрен тели.

Маладис булырга тырышу. Бу безнең заманда иң таралган бер нәрсә бит инде. Олысыннан кечесенә кадәр, ире дә, хатыны да маладис булырга тырыша. Шуны куәтләү өчен хәтта орчык буе гына баласын да, хәтта песиен дә маладис итеп күрсәтергә омтыла. Маладислыгын күрсәтү өчен ике фатир бәясе торган машинада йөри, миллионлык өстәл артында, миллионлык кәнәфидә утыра. Имиджмейкерлар армиясе тота. Кемнедер үлемнән коткару өчен мең сумын кызганса да, үзенең маладислыгын күрсәтү өчен миллионнарын җәлләми. Мөлкәт, акча – мисал гына, аңларга җайлы булсын өчен. Чөнки хәзерге кешегә мәсьәләне акча мисалында гына төшендереп була. Зур мөлкәт хуҗасы була алмаганнар кулыннан килгәнчә кылана. Һичьюгы, матуррак чыккан фотосын яки алсурак пешкән бәлешен соцчелтәрләргә элә дә «лайк куегыз» дип үтенә. Бер карасаң, моннан да мәгънәсезрәк гамәлне табу авыр: аның ни үзенә, ни башкаларга файдасы юк.

Бу кешенең интеллектуаль дәрәҗәсе белән дә, башка сыйфатлары белән дә бәйле түгел. Иҗатчыга шедеврлы өчен түләнгән зур гонорар гына җитми, аңа кемнеңдер мактавы, соклануы, бөтен халык ишетерлек итеп «маладис» дип әйтүе кирәк. Сыер савучыга алдынгы хезмәте өчен бирелгән Мактау кәгазе кирәк. Бөтен авыл халкы алдында хуҗалык рәисенең кулын кысып шушы кәгазьне тапшыруы аңа әйтеп бетергесез ләззәт өсти. Беркемгә күрсәтмичә генә бирелгән миллион сум да аны бу дәрәҗәдә бәхетле итә алмас иде. Безгә һәрвакыт тамашачы кирәк. Карап торучылар, эшебезне күреп торучылар булганда без тагын әллә нинди юләрлекләр, төрле исемнәр белән аталучы ахмаклыклар эшләргә әзербез. Тамашачыларның «маладис»ы кирәк. Без әнә шуның белән тукланабыз.

Кеше белән үз теләкләре түгел, ә җәмәгатьчелек фикере идарә итә, һәм аннан берничек тә котылып булмый. Хәтта бу фикергә игътибар итмәскә тырышучылар (аларны урыс «пофигист» дип йөртә бугай) да аннан азат түгел. Игътибар итмәү, битарафлык үзе үк имиджга әйләнә.

Бер яктан, бу – яхшы күренеш. Камиллеккә омтылырга, яңа уңышларга ирешергә мәҗбүр итә. Һәрвакыт көчле булырга әйди. Икенче яктан… Авызыңда кара кан булса да, кеше алдында төкермә, диләр бит әле. Анысы да начар түгел. Ләкин сер бирмәскә тырышучылар күп очракта кан йотып яши. Чөнки без һәрвакыт үзебездән дә акыллырак, әйбәтрәк, баерак, көчлерәк булып кыланабыз. Кешенең үзеннән дә камилрәк бер генә нәрсә бар икән, бу – аның имиджы. Һәм үзебез булырга, табигый үз тормышыбыз белән яшәргә вакытыбыз да, көчебез дә калмый. Шуңа кеше нинди уңышларга ирешүенә карамастан, канәгатьсезлек кичерә, үзен бәхетле итеп тоя алмый. Шәхси теләкләре һәм имидж таләпләре арасында адашып йөрергә мәҗбүр була.

Бу ир-егетләргә дә, хатын-кызга да бер үк дәрәҗәдә кагыла. Гомумән, бүгенге җәмгыятьтә ир-ат, хатын-кыз дип бүлү – шартлы күренеш. Тормыш йөген тарту буенча алар бердәй үк. Алар бары тик физиологик һәм психологик яктан гына аерыла.

Шулай да моны хатын-кыз авыррак кичерәдер кебек. Аның хисләре көчлерәк, нечкәрәк. Ә нечкә нәрсә тизрәк кисә. Көндезләрен көчле ханым булып, «маладис»лар җыеп йөрүчеләр арасында төннәрен мендәр кочаклап елаучылар да җитәрлектер. Яки кемнедер елатучылар. Бернәрсә дә юкка чыкмый һәм юктан бар булмый. Кешенең бер юнәлештәге уңышы – ул аның икенче юнәлештәге югалтуы.

Шул рәвешле, «уңышлы ханым» образы кайчагында хатын-кыз бәхетсезлегенең бер төре булып чыга. Уңышка төреп бирелгән бәхетсезлек. Моның сәбәбен мин ир-ат белән хатын-кызны тигезләүдә дип уйлыйм. Бу тигезлек – кешелекнең иң зур хатасы. Хатын-кызны ирләр дәрәҗәсенә төшерергә кирәкмәс иде.

ЯЛГЫЗ СӘЯХӘТЧЕ

– Мин үземә юлдашны бер генә тапкыр эзләдем. Нигәдер Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә үзем генә чыгып китәргә курыктым ул чакта... Табиб булып эшләүче танышым белән бардык. Юлга кузгалганда ук үз-үземә: «Ул да, мин дә ял итәргә барабыз. Кызыксынуларыбыз туры килми икән, бернәрсәне дә көчләп такмаячакмын», – дидем. Кибетләрдә йөрергә җыенуын белгәч, шактый борчылган идем. Әмма ул: «Мин әйберне үзем генә сайларга яратам», – диде. Беребез – шопингка, икенчебез Һинд океаны яры буйлап экскурсиягә китеп барды...

Европага беренче тапкыр чыкканда пенсиядә идем инде. «Нигә кеше көен көйләп йөрергә?» – дип уйладым да тагын берүзем чыгып киттем. Кызым укырга киткән чак. Германиядә, Мюнхен янындагы кечкенә генә бер шәһәрдә белем ала, гаиләдә яши. «Бар да әйбәт», – дип яза. Тик баласының кайда, ничек яшәп ятуын үз күзләре белән күрмичә ана йөрәге тынычланамыни?!

Турист булып Чехиягә, Прага шәһәренә барып төшкән Вәсилә ханымны, алдан килешкәнчә, кызы Алсу килеп алып китә. Баласын сыендырган алман гаиләсендә бер кич кунак була ул. Аннан тынычлап сәфәрен дәвам итә. Ә кызының язмышы шул җирләрдә булып чыга... Аэропортта инде аны хәзер кияве, оныклары каршы ала. Казан–Мәскәү, Мәскәү–Мюнхен... Бу араны узуның бер кыенлыгы юк дип саный Вәсилә ханым. «Кеше артыннан иярәсең дә барасың», – дип елмая...

– Балалары читтә яшәгән ата-аналарны аэропортларда бик еш очратам. Синең үзеңә генә берүзең чыгып киткәнсең кебек тоела... Моннан 15–20 ел элек берәрсенә: «Әле Америкага йөрерсең, өчәр аэропорт аша узарсың, океан буенда оныклар карарсың», – дисәң, ышанмаслар иде. Европага соңгы баруымда Домодедовода бер ханым белән сөйләшеп киттек. Янында зур-зур коробкалар. «Өйдә, бакчамда үскән алманы улыма ашатасым килә», – ди... Читтә яшәгән балалар яңа гадәт тә кертте: алар әти-әниләрен сәяхәт иттерә. Минекеләр дә шулай... Бөтенебез бергә төялешеп чыгып китәбез. Беренче тапкыр Карловы Варыда ял иткәндә оныгым Камилгә кырык көн генә иде. Бездә андый күренеш юк әле: кунак кайтса, чәйдән чәйгә генә йөртәбез...

Истанбул, Баку, Махачкала, Йошкар-Ола... Пандемия башланмаса, исемлек тагын да озын булыр иде! Хаҗ сәфәрен, Гомрә хаҗны санамаганда әле бу. Хәер, нәрсәгә шаккатарга – әбисе 80 яшендә дә Чиләбедә яшәүче улы янына берүзе барып йөргән әнә! Бер авыз сүз русча белмәгән килеш. «И-и, кызым, ниятләп чыксаң, Аллаһы Тәгаләнең җунле бәндәләре өмет итмәгән җирдән очрый аның», – дия торган булган. «Мин дә тел белмим, әмма куллар бар бит – кемгә сүз катсам да, аңлашабыз», – ди Вәсилә ханым.

Юл сорап күбрәк... үзе яшендәге ир-атларга мөрәҗәгать итә икән. Бер генә сынамаган: ир-ат, юлны белмәсә, шундук баш тарта, белсә – төшендерерлек итеп аңлата.

Үзе өчен язылмаган законнары тагын бар әле. Юлга чыкса, паспорт, акча һәм документлар салынган кечкенә сумкасын берәүгә дә ышанып калдырмый. Шулай ышанычлырак. (Дөрес, Сәмәркандка автобус көткәндә бер ир-атның, алдалап, 3 сум акча алып китүен санамасаң, башка андый күңелсез хәлләргә юлыкканы юк аның.)

Янәшә урындыктагы пассажирның сөйләшергә теләге юк икән – йөдәтмәскә. Монысы да – язылмаган кагыйдә. Кызларының берсе Мәскәүдә яшәгәндә, ике шәһәр арасында поездларда да күп йөрергә туры килгән аңа. «Кеше хәзер ябылды, аралашмаска тырыша. Элеккеге кебек вагоннар гөрләп тормый: бергә утырып чәй эчү, сөйләшүләр бетте. Купега килеп кергән юлдашың хәтта исәнләшмәскә дә мөмкин. Минем кебек бөтен нәрсә белән кызыксынган журналистка сөйләшми бару авыррак инде, әмма түзәм», – ди ул.

– Истанбулда йөрим. Инде ике-өч көн шәһәрне карадым. Күрәм: отельгә яңа туристлар килгән, яшь пар. Мин бит әле өйрәтергә дә яратам... «Менә шунда-шунда, һичшиксез, барыгыз», – дим боларга. Янәсе мин инде тәҗрибәле. «Ә без инде маршрутны төзеп килдек», – диләр. Күңелемә салып куйдым, менә кеше ничек әзерләнә икән сәяхәткә, дим. Моны хәзер үземә кагыйдә итеп керттем.

Сәяхәттән кайтканнан соң, кабат интернетка чуму: булган, күргән урыннар турында җентекләп уку – монысы да язылмаган кагыйдәләрнең берсе. Тәэсирләрен, белемен шулай арттыра икән ул. Аннан – тирә-юньдәгеләргә сөйләп! Сәяхәтнамәләр язып. Бер сәфәрнең рәхәтен дүрт-биш айга сузуның сере бу!

Бер күргән урынга икенче кат бармаска – бу да кагыйдә. Барасы килгән яңа җирләр шундый күп булганда соң...

Инде иң четерекле мәсьәлә: нинди акчага сәяхәт итә ул?

– Мин чүпрәк колы түгел. «Бу пальтоны инде өч ел кидем, яңасы кирәк», – димим. Фатирга әледән-әле ремонт ясау, җиһаз алыштыру белән дә мавыкмыйм. Германиядә кызым торган фатир хуҗалары гел күз алдымда. Икесе дә табиблар. Әбиләреннән калган өч катлы йортта яшиләр. Алардагы кебек китап шкафлары безнең өйләрдә алтмышынчы елларда торды. Аның каравы, бөтен дөньяны күреп чыкканнар... Ике елга бер сәяхәт итү өчен 30–40 мең акча җыеп була ул. Балалар да ярдәм иткәли.

Иң рәхәт сәяхәт – су өстендәге круизлар, ди ул. Балык йолдызлыгында туган кеше су ярата инде! Кызыл диңгезне күргән, Ак диңгезне, Кара диңгезне... Янгантауда, Йөрүзән елгасы буенда ял иткән. Санкт-Петербургтан өскә менгән – Кижи, Валаам утрауларына. Хыяллар тагын да күбрәк! Ул күрергә теләгән Агыйдел бар әле, Байкал...

Тагын бер кагыйдәне әйтергә онытып: кунак йортларындагы «кунак дәфтәре»нә һәрвакыт татарча гына яза Вәсилә ханым. Альп таулары итәгендә утырган ул авылларга ялгыш кына барып чыксагыз, тәкъдим-фикерләр теркәлгән дәфтәрләрдә татарча язуга тап булып, шаккатмассыз, яме.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Сәяхәтләр ярату – Вәсилә ханым Рәхимованың канында. Эшли башлагач, иң беренче җәйге ялында ук, «Спутник» турфирмасы аша путевка ала да, укытучылар төркеменә ияреп, Мәскәү күрергә чыгып китә ул. Әсәрләнеп кайта... Читтән торып университет тәмамлаган елны Урта Азиягә китеп бара. Адым саен отельләр юк вакытлар: ерак бер туганын эзләп таба, шуларда туктый. Ташкент, Сәмәрканд шәһәрләрен карый. Хуҗабикә исә аны көн дә яңа бер үзбәк ризыгы пешереп сыйлый... Соңрак сәяхәтләргә гаиләсе – ире, балалары белән кузгала. Профсоюз биргән юлламалар да яңа сәфәрләр бүләк итә: Грузия, Балтыйк буе илләре, Кырым... Үзгәртеп кору елларында гына яңа җирләр күрү хыялын читкә куеп, онытып торырга туры килә.
Ул арада балалар үсә, тормышлар үзгәрә – чикләр ачыла, яңа мөмкинлекләр туа.

Фото: Анна Арахамия



Фото: Анна Арахамия

«АШЫКМЫЙМ, КӨТӘМ ГЕНӘ»



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Җәмгыятьтә хатын-кызларның статусы үзгәрә. Гаилә учагын саклаучы назлы һәм нәзакәтле хатыннар амбицияле максатлар куйган карьерачыларга әйләнә бара. Алар эш, акча дип хыяллана, хакимияткә омтыла, тормышта исәп-хисап белән яши һәм барысына да үзләре ирешә. Әлбәттә, көндәшлек көчле заманда бу начар түгел, әмма... Әле егерме ел элек кенә мондый тенденцияләр булмаган, кияүгә чыкмаган 20–30 яшьлек хатын-кызлар саны да бик аз – бары 7 процент тәшкил иткән. Хәзер бу сан 20 процентка кадәр үскән. Европада ул 35 процент, АКШта бу яшьтә һәр икенче хатын-кыз гаиләсез. Ә ярты гасыр элек кенә кияүгә чыгу, гаилә – терәк, финанс тотрыклылыгы, гомумән, кеше тормышында бердәнбер бәхет чыганагы дип саналган. Ни өчен барысы да шулай үзгәрде? Чибәр, эшлекле туташлар нигә кияүгә чыгарга ашыкмый? Әлеге сорауларга психологлар белән җавап эзлибез.

Телим икән – прәннек, телим икән хәлвә ашыйм

Һәрвакыт әкрен генә, үз көенә генә йөри ул. Үзе дә салмак, тормышы да. Сүзем – яше иллегә таба баручы кияүгә чыкмаган танышым турында. Гомер уртасына җиткән хатыннан ник кияүгә чыкмадың, дип сорау – әдәпсезлектер, мөгаен. Шулай да беркөнне сорарга җөрьәт иттем.

– Нигәдер бу хакта уйланганым булмады. Син сорагач кына анализларга керештем, – диде ул, озак кына уйлап утыргач. – Мин – Казан кызы. Гомерем буе әнием белән яшәдем. Юк, әни кияүгә чыгарга киртә булды дип әйтмим. Ул бик әдәпәхлак саклый торган кеше иде. «Тап инде үзеңә бер кеше», – дип бервакытта да аптыратмады. Туганнарым да сорашып җанга тимәде. Бәлки, институтны тәмамлагач Ленинградка китәсе калгандыр. Шул шәһәрдә яшәргә хыялландым, бәлки, миңа дигән яр да шунда булгандыр. Чыгып китүдән курыкмадым, ялкауландым. Шулай гомер үтте инде... Башка кызлар кебек, кияүгә чыгу, туй, ак күлмәк турында да хыялланып яшәмәдем. Дөрес, җитен тукымадан тегелгән ап-ак күлмәк киеп диңгез буенда кем беләндер җитәкләшеп йөргәнемне күз алдыма китергәнем булды. Очраган беренче кеше белән дә гомеремне бәйлисем килмәде. Башны югалтырлык гашыйк булдым, дип әйтә алмыйм. Бик күп таныштырдылар. Әмма бөтен эмоциям йөземә чыга. Беренче тәэсирләр башны әйләндерерлек булмаганын сизеп, ир-атлар үзләреннән-үзләре югалгандыр. Кылана белмәдем, дип әйтәсем килә. Ир-ат янында артистлану кирәк ул. Бәлки, яратмыйча кияүгә чыгу кирәк булгандыр. Әмма мин хис кешесе, алай яши алмас идем. Кино караганда, мәхәббәт геройларының бер-берсенә булган җылы, матур мөнәсәбәтләреннән тыела алмый елап утырасың. Күрәсең, тормышымда яшь чыгарта алырлык кеше очрамагандыр. Соңга таба үз-үземне тәрбияләп яшәүдән тәм таба башладым. Телим икән – прәннек ашыйм, телим икән – хәлвә. Үземне эш белән дә юатканмындыр.



Психолог Зөлфия МӘКСУТОВА: «Балачакта алган күңел яралары, үпкәләр кияүгә чыгарга киртә булып тора. Әти-әни тәрбиясе бу уңайдан зур роль уйный...»

Дөньяга һәр кеше парлап яратыла, диләр. Күрәсең, өстә минем хакта онытканнардыр, бәлки, планнары башкадыр. Хәзер инде ир белән яшәрмен дип уйламыйм. Шулай да сәяхәтләргә барырлык үзем кебек ялгыз бер ир очрамый калмас әле. 90 яшьтә дә кешенең өмете үлми, диләр. Өмет бар ул...

Парсыз булу – бәхетсезлек билгесе түгел

Бу темага Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының талантлы артисткасы Ләйсән Фәйзуллина белән дә сөйләшеп алдык. Ул – яңа буын вәкиле. Бу нисбәттән яшьләр фикерен дә беләсе килде.

– Без бик бәхетле заманда яшибез, – ди Ләйсән. – Кияүгә чыгуның традицион яше бераз күчерелде хәзер. Башта укыйбыз, үзаңлы булырга тырышабыз, психологлар белән эшлибез, үзебезне камилләштерәбез, гомумән, тулы бер шәхес булырга омтылабыз. Шул чакта гына үзең кебек үк гармониядә яшәгән кешене очратып, бәхетле пар була аласың дип уйлыйм. Үз мәхәббәтеңне табып, кияүгә чыгу – Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән зур бәхет, зур бүләк бит ул! Мин үзем шундый тормышка омтылам. Хәзер мөмкинлекләр күп. Бер яктан, ул бик әйбәт, чөнки гаилә коруга барысын да аңлап өлгерәбез. Ә икенче яктан карасаң, үзаңлы булып җитешкәч, кияүгә чыгуның бердәнбер бәхет чыганагы түгеллеген аңлыйсың. Аны эштә, башка бер яшәү мәгънәсендә табарга мөмкин. Парсыз булып яшәсәк тә, бәхетсез кеше түгелбез.

Кайбер кешеләр өчен кияүгә чыгу – ялгызлыктан котылу чарасы дип саный Ләйсән. Нәрсәдән куркасың, каршыңа шул чыгар, диләр. Йә парлы килеш ялгыз булып яшиләр, йә озак та яшәми аерылышалар. «Җәмгыятьтә гасырлар буе салынган гаиләгә кагылышлы стереотиплар да кияүгә чыгып калырга кирәк дигән уйны ныгыта торгандыр, бәлки?! Әмма хәзерге яшьләр ул стереотипны вата, аңа ышанмый. Миңа да кайчак: «Гаилә корырсың да, бәхетле булырсың. Сиңа хәзер авыр, кияүгә чыккач җиңел булыр», – диләр. Мин аңламыйм, үзем генә булганда нигә начар булырга тиеш соң?» – ди Ләйсән.

Аның фикеренчә, кеше ялгызы да бәхетле була ала, чөнки үзаңы, тәләкләре, һөнәре, кызыксынулары бар. «Мин – халык белән эшли торган һөнәр иясе. Гримеркада дүрт-биш кеше утырабыз, сәхнәдә партнер белән уйныйбыз. Шуңа ялгызым өйдә утырырга яратам, рәхәт булып китә. Берүзем булганда гына ял итә алам. Хәтта кияүгә чыккач та, иремнән берничә сәгатькә ялгызымны калдыруын сорар идем, минем өчен бик мөһим бу. Кайбер чит илләрдә парлар хәтта төрле бүлмәләрдә йоклый, ял иткәндә башка кешенең энергетик кыры тәэсир итмәскә тиеш», – ди актриса. Иң мәгънәсезе: гаиләсез кешеләрне җәлләп, аларга киңәш бирү дип саный Ләйсән. «Киңәш кирәк булса, мин аны сорап алам», – ди бүгенге җәмгыятьнең яшь вәкиле.

Ләйсән Фәйзуллина фикерен «ФемКызлар» хәрәкәте активисты Тасия Альбариньо да куәтләде. «Соңгы елларда аерылышучылар проценты бермә-бер артты. Шуңа да хатынкызлар кияүгә чыгарга ашкынмый.

Кияүгә чыгуның традицион яше бераз күчерелде. Иң элек кызлар тулы бер шәхес булырга омтыла.

Күңелсез статистиканы арттырасы килми аларның, гаилә коруга бик җитди килоләр. Булачак ирләренә бизнес-партнерга караган кебек карыйлар: ышанычлы булырга тиеш! Шартларын, сайлау критерийларын алдан ук сөйләшеп куялар. Гаилә килешүе төзү дә популярлаша башлады. Гомумән, безнең икътисадый вазгыятьтә гаилә кору беренчел ихтыяҗ булып тормый», – ди ул.

Росстат мәгълүматларына караганда, бүген кызлар уртача 25–34 яшьтә кияүгә чыга. 35 яшьтән соң беренче тапкыр ЗАГСка баручылар да, ялгыз аналар саны да арта. Моның сәбәбен ирләр юклык яисә уңмаган ирләр күплек белән аңлатырга яраталар. Бу дөрес түгел кебек. Совет чорында ялгыз хатыннарга җәмгыятьтә үз урыннарын табу һәм карьера баскычыннан күтәрелү мөмкинлеге күпкә аз булган. Тикмәгә генә гаиләсез хатыннарның, сөйгән ярларын табып, гаилә корулары турындагы фильмнар күпләп төшерелмәгәндер инде. Һәм алар бик популяр булган. «Одинокая женщина желает познакомиться», «Самая обаятельная и привлекательная» фильмнарын гына искә төшерик. Ул вакытта җәмгыятьтә гаилә культы була. Җенси тормыш та, гадәттә, кияүгә чыкканнан соң гына башланган. Ә хәзерге җәмгыятьтә бу табу бөтенләй юкка чыкты. Без хәзер муллык вакытында яшибез. Мәгълүмат күп, медицина алга киткән, ахыр чиктә, феминизм чәчәк аткан чор. 90 нчы еллардагы юклыкны белеп үскән буын башка тормышка омтыла. Укып, белем алырга, тәҗрибә тупларга, үзаңлы булырга һәм булачак ярын йөрәк белән түгел, акыл белән сайларга тырыша. Шуңа да хәзер «сөйгән яр», «тиң яр», «өлешемә тигән көмешем», димиләр, ә партнер, диләр. Замананың нәфис затлары аңлый: ана белән хатын булудан тыш та, дөнья кызыклы. Кызлар белем алганнан соң үзләрен төрле өлкәдә сынап карарга ярата, чит илләргә китеп яшәп кайта. 30–40 яшьтән соң карт күренермен дигән курку да юк. Эстетик медицина киредән яшьлеккә кайтара ала. Бу яшьтәге хатын-кызлар 18 яшьлек кызларга оттырмый хәзер. Ирләр игътибары аларны читләтеп үтми. Димәк, гаилә корырга соңга калмыйм дип уйлыйлар.

35 яшьтән соң кызларның ялгыз калуында ата-ана тәрбиясе дә чагылмый калмый. Алар ярты гасыр буе әти-әниләренең мәхәббәтсез яшәүләрен, әниләренең әтиләреннән зарлануын күреп-ишетеп үсәләр. Ятларга зарланмасалар да, үсеп буй җиткән балаларга ирләреннән зарлана әниләр. Бала сөйләп йөрми, аңа гына сөйлим дип уйлыйлар. Ә ул сүзләр булачак ир хатынының күңеленә кереп калыр дип уйламыйлар нигәдер. Шуңа күрә дә гаилә корып, шулай ук интегеп яшәргә теләмиләр. Һичьюгы ирсез бала табып, ялгыз ана статусы алалар. Менә шушы урында кызларның кияүгә чыкмау сәбәпләрен төптәнрәк эзли башлыйк әле. Язмышыбыз туганда ук маңгайга язылган була, диләр. Ә мин балачакта да языла дип өстәр идем. Психолог, бик күп тренинглар авторы Зөлфия Мәксүтова белән әлеге проблема турында сөйләшкәч, бу фикерем кабат расланды кебек.

Балачак яралары, программалар, тәрбия...

– Элек яучылык институты булган. Ата-аналар кызларына ирне үзләре сайлаган. Әмма бу күренеш хәзер югалды. «Мөстәкыйль»лек алган буын сайлый белмәгәнен, кияүгә чыга, өйләнә алмаганын аңлады. Монысы беренче сәбәп, – ди психолог. – Кайбер кызлар турында, ул соры тычкан кебек, киенүенең дә рәте юк, шуңа аңа егетләр карамый, диләр. Әмма бу – сафсата. Хатын-кыз энергетикасы дигән төшенчә бар. Әлеге энергетика көчле икән, пәрәнҗә ябынган хатын-кыз артыннан да ир-ат көтүе белән йөрергә мөмкин. Бер танышымның ике кыз туганы бар. Берсе чибәр, ә егете юк. Икенчесе юан, үзенең бите бетчәле, егетләр аннан күз дә алмый. Моңа бары энергетика гына сәбәпче. Кемдәдер бик зур, икенче берәүнеке аз ул, шуңа күрә аны үстерергә кирәк. Хатын-кыз энергетикасы җенси өлгереш вакытында бик көчле, әмма 20 яшьләрдә, бала тапканнан соң кими. Моннан кала, кайчандыр алган күңел яралары да тәэсир итә.

Хатын-кыз тормышында әти дә зур роль уйный. Әти – кыз бала тормышындагы беренче ир-ат. Ата мөнәсәбәте кызның киләчәгенә бик нык тәэсир итә. «Әтигә үпкәләү – кияүгә чыгуга киртә булып тора, – ди Зөлфия Мәксүтова. – Шунысы да бар: йә ул кызларның әтиләре булмый, йә ташлап китә, йә гаиләдә деспот була. Кияүгә чыгармын да, ирем әтием кебек авырткан урыныма тияр дип курка кыз бала. Миңа интеллигент гаиләдән бер кыз йөрде. Әнисе – йомшак, әтисе бик кырыс булган. Ул гел әнисен мыскыл иткән. «Бәгыремне ашый инде», – дия торган булган әнисе. Билгеле, бу сүзләр, әтисенең кыланышлары кызның күңелендә калган – ир-атларга карата саклану реакциясе барлыкка килгән.

Гомумән, балачактан алган яралар бездә бик күп. Социаль яктан имин дип исәпләнгән гаиләдә үскәннәрнең дә булмый калмый ул. Хәтта әтинең кызына артык игътибар итмәве, аралашмавы, дорфа булуы да яра салырга мөмкин. Бу – «Ир-атлар миңа игътибар итми» дигән программа барлыкка килүгә сәбәпче. Кияүгә чыккан очракта да, әтиләре кебек салкын ирләрне сайлый һәм гаиләдә җылыга интегеп яши. Әти генә түгел, әни дә, якыннар да, беренче мәхәббәт тә, ятлар да сала ала яраларны. Физик һәм психологик көчләү дә сәбәп булырга мөмкин. Әлбәттә, бу кызлар эчтән генә кияүгә чыгарга тели, егетләр белән очрашуга йөри, әмма җитди мөнәсәбәтләр кора алмый.

«Нәселдән килгән программалар да бар, – ди психолог. – Әбидән онықка күчкән, мәсәлән. Клиентлар белән эшли башлагач, «Кияүгә чыгу минем өчен куркыныч» дигән программалар чыга. Ә бу аларныкы түгел, нәселдән килгән булырга мөмкин. Әбисе, әбисенең әбисе иреннән мыскыл ителеп яшәгәндер, бәлки. Алар шуңа түзгән, чөнки заманы башка булган. Ә ир-атлардан курку генетик дәрәҗәдә язылып куела һәм нәселдән-нәселгә күчә. Боларның барысын да хәл итү өчен иң элек проблема барлыгын кабул итә белергә кирәк. Ә күпләр моңа бармак аша гына карый, аңламый, ышанмый, ахырда бөтен гаепне ир-атларга өеп калдыра», – ди Зөлфия Мәксүтова.

Тормыш кора алмауның тагын бер сәбәбе – ата-аналарның артык нык кайгыртучанлыгы. Кызлары, үсмичә, бала булып кала. Инфантиль кеше, диләр алар хакында. «Нигездә, баласы белән ике арада әни «кендеген өзми», шул сәбәпле, аерым тормыш корырга ирек бирми. Бу бигрәк тә ир-егетләр арасында нык сизелә, кызларын «җибәрмәүче» әниләр дә бар», – ди психолог. Алар хатын йә ир урынын энергетик дәрәҗәдә алып тора. Шуңа да ятларга арага керү бик авыр. Бу кешеләр гаилә корсалар да, баласыннан аерылырга теләмәгән ана ир белән хатын арасында торачак. Инфантиль кешеләр дә хәләл җефете белән түгел, әнисе белән дус булачак. Бу ананың куркуы аркасында килеп чыга. Нигездә, ялгыз йә ире белән ике арада җылылык булмаган аналар алар. Эгоист бәхет ул. Бу очракта психологка икәүләп йөрү хәерле. Ананың курку программаларын бетерергә кирәк. Балага сүз белән түгел, энергетик дәрәҗәдә, ягъни күңел түреннән үк мөстәкыйль тормышка фатиха бирү тормышын күпкә җиңеләйтәчәк. Әнисенә артык нык бәйләнгән кешеләрдә, гадәттә, «Мин кияүгә чыксам, әнигә хыянәт итәм» дигән программа була. Алар егетләр белән очрашып та йөрергә мөмкин, әмма җитди мөнәсәбәт барып чыкмый.

Татар халкы тәкъдиргә сылтарга ярата. Вакыты җитмәгәндер әле, дип әйтүчән. Әмма бернәрсә эшләми, кул кушырып утырсаң, ул вакыт җитмәскә дә мөмкин. «Шуңа үз өстеңдә даими эшләргә, анализларга кирәк», – дип киңәш бирә Зөлфия Мәксүтова.

– Ялгыз калудан куркып, беренче очраган кешегә кияүгә чыкмыйча, үз хәлен кабул итеп, тормышны яратып яшәгән хатын-кызлар ярын тапмый калмый. «Миңа ир-ат кирәкми», – дип, бик көчле булып күренергә тырышкан хатын-кыз да күңел түрендә үз ярын табарга ышанып яши. Барысын да бүлешү, җилкәсенә башын салып елап алу өчен янында ямьсез булып күренүдән курыкмаган бердәнбере кирәк аңа, артыннан йөргән дистәләрчә ир-ат түгел. Көчле хатын-кызда да төрле күңел яралары һәм программалар бар. Әмма ул үзенә бу хакта уйларга рөхсәт кенә итми. Битлек кия дә, җанындагы авыртуны белгертми. Читтән бик бәхетле күренсә дә, теләсә нинди хатын-кыз өчен гаиләсез булу – җан авыртуы ул», – ди психолог.

Безнең илдә, чынлап та, хатын-кызларга сазаган, тозланган, карт кыз тамгасын бик иртә сугалар. Шул ук АКШта: «Сиңа 40 яшь, димәк, кияүгә чыгу турында уйланырга вакыт», – дисәләр, бездә: «Йә Аллам, сиңа кырык бит инде, утырып калгансың!» – дип әйтергә мөмкиннәр. Әйтмәсәләр дә, уйлыйлар. Бала табарга бу яшьтә дә соң түгел әле, ди белгечләр. Хәзер организм элеккеге кебек иртә картаймый, җитмәсә, медицина да алга киткән. 40 яшьтә дә кияүгә чыгып, менә дигән итеп балалар үстереп, бәхетле ир хатыны булып яшәп була. Бәлки, ул бәхет 40 ел буе көтәргә лаеклыдыр.

Гаилә кору – акча, дин темасы кебек үк интим тема. Ул кешенең шәхси эше. Шуңа да артыгын сораштыру, киңәш бирү урынсыз. Кияүгә чыгуга кызыксыну бетмәде, миңа калса. Бары тик бүгенге җәмгыятьтә иргә карата яңа таләпләр барлыкка килде: эштән соң диванга сузылып ятып ашарга сораган ирләр рухландырмый замана хатын-кызларын. Йорт эшләрен дә бергә карыйсы, балаларны да икәүләп тәрбиялисе, гаилә учагындагы җылылыкны бергәләп саклыйсы килә...



Гөлназ МӨХӘММӘД, язучы

Күпкырлы мәсьәлә бу. Хатын-кызлар гына түгел, өйләнмәгән ирләр дә бик күп. Үзләренә идеал тудыралар да, булачак ярларын шуның буенча эзләргә керешәләр. Фотодан карап йә бер тапкыр очрашканнан соң ук: «Минеке түгел. Күземдә очкын кабызмады», – диләр. Очкын бер дә кирәкле нәрсә түгел. Тормыш күргән кешеләр белән сөйләшсәң, моның асылына төшенәсең. Очкын ул – хисләр. Ә алар кеше тормышында кабынып, сүнеп тора. Хисләр дулкыны яшәргә комачаулый гына. Кешене бер тапкыр очрашудан гына белеп бетереп булмый. Моның өчен кимендә биш ел яшәргә кирәк. Эшли белгән, өйдә матур мохит тудыра алган ирләрне сайлагыз. Һөнәренә карап та сызып атарга ярамый. Кызлар ир кешенең акча табутапмавына игътибар итә. Монысы да мөһим. Әмма шуны да онытмаска кирәк: бу илдә бөтен кеше дә эшмәкәр булып бетә алмый. Байлык – бер айлык дигән гыйбарәне дә онытмагыз. Хатын-кыз бала тәрбияләүче, ана инстинкты бар анда. Зирәк хатыннар әкрен генә ирне үзенә яраклаштыра, тәрбияли. Әмма зирәклек урта буын хатын-кызларына да җитеп бетми әле ул. Минминлек белән эш итеп, гаилә диварларын ныгытып булмый. Кызларга киңәшем шул: артык сайланмасыннар. Безнең җәмгыятьтә соңгы вакытта кешелеклелек модада түгел. Бу сыйфат булган кешеләр генә ныклы гаилә кора, тәртипле балалар үстерә ала. Тәкәббер хатын-кызларны яратмыйлар. Үзен әдәпле тоткан, матур итеп сөйләшә белгән туташлар һәр ирнең йөзек кашы була ала. Шуны онытмагыз, кызлар.

AELITA ROOMS
8-987-228-29-99
@aelita_rooms
/ авторские шторы / люстры /
/ дизайн-проект / карнизы /
/ производство мебели /
Мы переехали. Ждем вас по адресу:
г. Казань, ул. Родины, 24 Б
РЕКЛАМА

«ИДЕАЛЬ ИР БУЛУ ӨЧЕН ЯНӘШӘДӘ ИДЕАЛЬ ХАТЫН КИРӘК»

Ул күпкырлы эстрада артисты. Пародист, нәфис сүз остасы, җырчы, биюче, шоумен, гомумән, талантлы кеше, үрнәк гаилә башлыгы. Хатынына тугры мәхәббәте, кызларына булган яратуы аны түгәрәк бәхетле итә кебек. Бездә кунакта – Татарстанның атказанган артисты Данир САБИРОВ.



Данир, бүгенге эстрада артисты нинди ул?

– Эстрада бик төрле ул бүген. Бар популяр җырчылар. Минем жанр башкачарак. Үземне җырчы дип санамыйм. Әмма җырлаштыргалыйм, чөнки җырларга яратам. Концертлар да җырсыз булмый. «Күбрәк җырла әле», диюче тамашачыларым да шактый. Курыкмыйча әйтә алам: хит булган җырларым да бар. Кемнәрдер мине сүз остасы буларак кабул итә. Пародия жанрын яратам, миниатюрада да эшлибез һәм, әлбәттә, хореография... Бүген сәхнә тотарга теләгән артист төрле юнәлештә эшләргә тиештер шулай.

Хәзер артистларга, бигрәк тә җырчыларга авырга туры килә. Алар тамашачыларны үзенә каратып торудан битәр, социаль челтәрләрдә язылучыларны да тотып торырга мәҗбүр. Социаль челтәрләрдә сез гаилә белән эшлисез.

– Берни эшләп булмый – замана таләп итә. Артта каласың килмәсә, яраклашырга кирәк. Киләчәк тамашачыларыбыз Тик-Токта утыра. Ә минем иң зур теләгем – яшьләрне җәлеп итү. Социаль челтәрләрдә булу кирәк. Сине мактамыйлар яки хурламыйлар, искә төшермиләр икән, димәк, беркемгә кирәкмисең дигән сүз.

Син – пародияләр остасы. Сәясәткә кагылышлы пародияләр ясарга уйламыйсыңмы?

– Тугызынчы сезон концертларым бара. Дүртенче программага кадәр пародияләрне үзем яздым. Хәзер Сирень Бәйрәмов дигән бик көттә юморист белән икәү язабыз.

Сәясәтне яратып бетермим мин. Аннан соң... өстәге абзыйлар белән бер дәрәҗәгә басып шаяртырлык зур көчем булса, шаяртыр идем. Әле хәзер дә шаяртыштырам шулай да. Бу уңайдан остазым Салават абый белән дә киңәшләшкәнем бар. Ул: *(Салават тавышы белән.)* «Смешно, но не надо», – ди.

Социаль челтәрләрдә сине идеаль ир, диләр. Килешәсеңме?

– Килешәм, дисәм, мактану була инде. Әмма килешмәслек тә түгел. (*Рәхәтләнеп көлә.*) Хатыным да шулай дип торгач, мин шундый дип йөрим инде.

Идеаль ир нинди булырга тиеш соң?

– Идеаль ир булыр өчен хатынның да сиңа яраклашырга тиештер. Гаилә ул – индивидуаль. Шуңа да аны башка гаилә белән чагыштыру урынсыз. Хатын бөтен нәрсәне белергә тиеш түгел, диючеләр дә бар. Әмма безнең хәтта телефон парольләребез дә уртак, гәрчә бер-беребезне тикшермәсәк тә. Кайткач, бер-беребезгә һәр адымыбызны сөйләп чыгабыз. Шулай күнегелгән, шулай рәхәт безгә. Ихлас булсаң гына гаиләдә идеаль мөнәсәбәтләр була. Шәхсән мин шулай уйлыйм. Миләүшә янымда булмаса, чыгырымнан чыга башлыйм, ул җитми. Һәрвакыт кирәк ул миңа.

Хатын нәфис хатын-кыз булып яшәсен өчен нишләргә кирәк?

– Иң элек ул хатын-кызның үзеннән тора. Һәм, әлбәттә, ирнең хатынга яраклашуыннан да. Беренчедән, хатын-кыз тирәсендә һәрвакыт матурлык булырга тиеш. Ул диндә дә әйтелә. Мин бу яктан Миләүшәгә рәхмәтле. Элек өйдә нинди кием бар, шуны киеп куя идек, чөнки без өйдә. Өйләнешкәч, Миләүшә өйрәтте: өй киеме матур, ашаганда өстәл сервировкаланган булырга тиеш. Моны балаларга да өйрәтәбез. Әйе, иртән чәчләр төрлечә була, әмма өстә матур пижама! (*Көлә.*) Хатын-кызның матурлыгы үзен тәрбияләүдән тора. Әйе, бу вакыт һәм акча таләп итә. Ләкин хатыныңның гүзәл булуын телисең икән, акча табарга тырышасың инде. Спорт залларыннан, матурлык салоннарыннан хатын-кыз ял итеп тә кайта бит әле ул. Анысын да онытмаска кирәк. (*Көлә.*) Ләкин шул ук вакытта гаиләдәге вазыйфасын да истән чыгармасын. Миләүшә үзен дә карый, мине ашатырга да җитешә. Мин аңа шулкадәр салынган – парковка өчен дә түли белмим. Чынлап әйтәм. Парковкага килеп туктыйм да: «Әнисе, мин шунда, түлә әле», – дим. (*Көлә.*)

Син тәмам кулга ияләшеп беткәнсең, Данир, аңладым. Шулай да сезнең гаиләдә матриархатмы, патриархатмы?

– Уртариархат *(көлә)*.

Моннан берничә ел элек бик каты күңел төшенкелегенә бирүең турында сөйләгән идең. Бу хәл кабатланмасын өчен нишлисең?

– Әйе, яндым мин ул вакытта, чөнки бик күп эшләргә туры килде. Кире үз хәлемә кайту авыр булды. Шул вакытларда рухи яктан дин ныгытты. Мин бит коммунист әби-бабай белән үскән бала. Миләүшә, аның әбисе дингә якынайттылар. Һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш дип саныйм. Омар Хәйямне яратам мин. Ул болай дип язган: «Несовместимых мы всегда полны желаний: / В одной руке бокал, другая – на Коране. / И так вот мы живем под сводом голубым, / Полубезбожники и полумусульмане». Кем нәрсә әйтүгә карамастан, минем үз карашым. Җомга намазын калдырмыйм. Рәхәтлек алып кайтам.

Артист булмасаң, кем булыр идең?

– Спорт буенча китәр идем. Көрәшче егет идем. Мактанырлык дәрәҗәгә дә ирешкәнем бар. «Татарстан яшьләре» газетасы үткәргән республика ярышларында чемпион булдым.

Хыялың?

– Бәхетле яшәргә! Ләкин бу бик авыр. Бәхетле булыр өчен эшләргә, тырышырга, омтылырга кирәк. Ә моның өчен рухи яктан көчле булу мөһим.

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ

Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.









ТӨПЧЕК МАЛАЙ

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Аларның ихатасында ике йорт тора. Күршеләр аша гына тагын бер йорт – өченчесе өлгереп килә. «Монысы тарих, – диләр, иске йортка күрсәтеп, – ә анысы – киләчәк буын өчен, монда исә бергә яшибез», – ди Гәрәевләр гаиләсе. Яшьләр әти-әнидән аерылып башка чыгуны күз алдына да китерми. «Бергә яшәүгә ни җитә!» – ди өлкәннәр дә, яшьләр дә. Без Буа районы Адав Толымбай авылында кунакта.

Америкада да аны сагындым

Моннан кырык ел элек буш ихата була монда. Ике өй аша гына Гөлфирә үсеп килә. Сугыштан соңгы еллар авыр булса да, балачакның, яшьлекнең үз матурлыгы. Авыл зур, балалар күп. Толымбайның бер башында татарлар, икенче башында чуашлар яши. Мәктәптә дә балаларны икегә бүлеп укыталар: татар һәм чуаш сыйныфлары. Дус-тату яшиләр чуашлар белән татарлар. Әмма бер аермалары бар. Толымбайда яшәүче татарлар читтән кеше кертми, үзләренекен ятларга бирми. Берберсенең нәсел-нәсәбен белгән зур авылда әнә шулай табышалар, кавышалар. Шуңа да гаиләләр дә ныклы. Шомырттай кара күзле кечкенә Гөлфирә мәктәпкә баргач коңгырт күзле Илсунга игътибар иттте микән? Юктыр, мөгаен. Ул яшьтә малайлар белән түгел, кызлар белән дус буласың. Үсмерлек чорына җитеп, күңелдә күбәләкләр оча башлагач, беренче сыйныфтан ук бергә укыган Гөлфирә белән Илсун арасында мәхәббәт уты кабына. Беренче мәхәббәт хисләре гомер буена сузыла аларның. Мәктәпне тәмамлагач, Гөлфирә Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Илсунны армиягә озатып кала, көтеп ала. Көтеп алмаслык егет түгелмени?! Сабан-

туйларда мәйдан тоткан көрәшче, кулына гармун алса, тирә-яктагы кошлар моңлана башлый. Илсун үзе дә җыр-моңга гашыйк.

– Илсун армиядән кайтуга комбайнга утырды. Мин «Энергосбыт»ка учетчик булып эшкә кердем. Озакка сузмый өйләнештек, – дип искә ала ул елларны Гөлфирә апа. – Күп балалы гаиләдән түгел үзем: абый белән икәү генә үстек, Илсуннарга тугызынчы кашык булып төштем. Кайнана белән озак яшәмәдем. Менә шушында буш милек бар иде – иске ызба китереп салдык. Әнигә дә якынайдым. Ул балаларны үстереште.

Хәзер музей урынына калган ул йортта 15 ел гомер кичерә алар. Шунда ике балалары – Гөлнара белән Илнур туа. Бишьеллык планнар, социалистик ярышлар чоры, хезмәт алдынгыларын зурлау... Комсомол, партия рухы көчле. Илсун – алдынгы комбайнчы. Почет билгесе ордены, медальләр ала ул. Районда гына түгел, республикада беренчелекне бирми. Хезмәт кешесен хөрмәтләгән чор. Мәскәүдә ВЛКСМның съездында делегат булып катнаша. Аңа анда Америкага барырга юллама тапшыралар. Армиядән кала, авылдан ерак китмәгән хезмәт кешесе өчен бу мәртәбәле бүләк була.

– Курыкмадыгызмы Америкага кадәр үк җибәрергә? – дим Гөлфирә апага.

– Яшь чак. Уйлый да белмәгәнмендер. Ул бит эшендә алдынгы булды. Хезмәте булгач, хөрмәте дип кабул иткәнмендер. Америкадан балаларга ул вакытта без күрмәгән әйберләр – сагыз, наклейкалар алып кайткан иде.

Сүзгә тыныч кына утыручы Илсун абый кушыла. Бик тыныч, төпле кеше. 48 ел бергә яшәгән Гөлфирә апа да: «Ул шыпырт инде безнең, ә мин күп сөйлим. Хатынкыз инде, нишлисең...» – дип елмая.

– Әле дә хәтерлим, путевка бәясе 27 мең сум иде. 13 тәүлеккә киттек. Беренче тапкыр шулай озакка гаиләдән аерылдым. Сагынып киттем, сагынып кайттым. Америкада да уемда гел Гөлфирә иде, – ди Илсун абый.

Америкада башка дөнья, ә монда тормыш көтәсе бар. Ят кыйтгага барып кайта да кабат эшкә чума гаилә башлыгы. Ир-ат эштә генә алдынгы түгел, өйдә дә терәк булырга тиеш. Ишәйгән гаиләсенә яңа йорт салырга керешә. Урманга барып үзе агач әзерләп, өй бурасы күтәрәләр. Әнә шулай зур йорт тергезәләр. Кырыкның теге ягына чыккан Гөлфирә апа, яңа йортын котлап, ир бала алып кайта. «Шулай язылган булгандыр. Олы кызыбызга – 15, улыбызга 12 яшь иде Булатны тапканда. Алла артыгын бирми ул, тиешлесен генә бирә», – ди. Аның төпчек бала икәнен, шушы йортка хуҗа буласын Булат карында яралганда ук белә Гөлфирә белән Илсун. Төпчек бала – терәк бала. Татарда язылмаган канун шундый.

Өйне төзүен төзиләр, әмма үз көчләре белән салынган, яшьлек хатирәләре белән сугарылган, беренче балалары тәпи киткән иске йортларын ятим итәселәре килми. Ишегалдындагы яңа йортка күченә алмый озак җәфаланалар.

– Бик кадерле иде. Калдырып чыгып китәсе килмәде шул. Югыйсә яңасы зур да, күпкә уңайлы да. Илсун базадан сөйләшеп мебельләр кайтарып тутырды. Бер ел

Татарда язылмаган канун бар: төпчек бала – терәк бала.

җылытып тордык, әмма яшәмәдек. Икенче кышка кергәндә бер кичне Раилнең әтисе (Буа театрының сәнгать җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Раил Садриевның исемен бу өйдә сәгать саен телгә алалар. Булатның өченче буын абыйсы гына түгел, аның язмышын кискен үзгәрткән кеше дә әле ул. – *Ч. Г.*) килеп керде дә, безне әрли-әрли, иң элек малайның бишеген яңа өйгә чыгарып элде. Аннары дырылдатып ашау өстәлен чыгарып куйдылар. Соңыннан үзебез кереп утырдык. Ул килмәсә, кайчанга кадәр күченә алмый йөрер идек, белмим. Кадерле, бик кадерле ызба шул. Шуңа да сүттерәсем дә килми», – дип, иске йорт ягына карап сөйли Гөлфирә апа. Яшьлекне саклаучы бер ядкарь итеп кабул итәләр бу йортны гаиләдә. Эш дип яшәгән гаиләдә хатирәләргә бирелеп утыру гадәте юк. Ихатадагы әнә шул кыеклары челтәрләп ясалган йортка бер күз салып алу да җитә, күрәсең.

– 48 ел бергә яшәгәнсез. «Уф туйдым» дигән вакытларыгыз булдымы? – дип сорыйм йорт хатирәләреннән арынып, бер-берсенең җылысын тоеп утырган Гөлфирә апа белән Илсун абыйдан.

– Ю-у-у-к, беркайчан юк! «Кит әле», дип тә әйткәне юк аның, – ди Гөлфирә апа. – Соң сүзгә килешү булгалый инде. Ярты гасыр буе күзгә-күз генә карашып утырмадык. Балалар киләчәге өчен дип күпме эшләр башкардык. Буш кара җиргә килеп утырган кешеләр бит без. «Син андый, син мондый», – дип яшәргә вакыт булмады. Әрләшергә, гомумән, вакытым юк. «Брат, минем иртән үк эшкә чыгып китәсем бар. Синең белән сүз көрәштереп торырга вакытым юк әле», – дип кенә әйтә идем.

– Шулай да, тату яшәүнең сере нәрсәдә?

– Су капсаң була. Әмма ир су капканыңны аңлый торган кеше булырга тиеш. Ишектән аны атып, моны тондырып, сүгенеп килеп кергән иргә су кабып торып булмый, әлбәттә. Илсун колхоз эшендә бригадир булып та эшләде. Соң кайта. Безнең малайлар елак булды. «Шаулама, малайлар йоклады», – дип каршы ала идем аны гадәттә. Тәртипсез кеше булса, малай йоклаганны белмәс тә иде ул.

– Дус-тату яшәүнең сере бер-береңне хөрмәт итү инде ул, – дип, җайлап кына сүзгә кушыла Илсун абый. – Ярату ул бер-береңне хөрмәт итү инде. Зур гаиләдә татулык булырга тиеш. Күп күрмә, күп белмә. Хәзер картайдык инде. Элек бик күңелле яшәдек. Кулдан гармун төшмәде. Уен-көлке булды. Авылда спектакль-концертлардан калмадым. Хорда да җырладым әле.

– Мәҗлесләрдә парлап җырлаучы матур парларның берсе сез, димәк.

– Юк, мин җырламыйм, – ди Гөлфирә апа. – Биергә яратам. Ут яндырып бии идек. Хәзер дә биер идем әле, аякларның гына рәте китте...

Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



Фото һәм видео: Анна Арахамия

PRESSA

Гаиләдә тыныч яшәү өчен авызыңа су кабарга кирәк.

Гөлназ түгел мин – җимешем...

Без өлкәннәр белән сөйләшеп утырган арада яшьләр кухняда табын әзерли. Икәүләп.

– Нәрсә эшлим, нәрсә кирәк, дип, өйдә булганда янымда йөгереп кенә йөри Булат, – дип көлә Гөлназ.

Булат кечкенәдән төпчек икәнен белеп үсә. Төп йортта каласын да, әти-әнисенә терәк буласын да. Аны яратып, апасы белән абыйсы да «Йомырканың сарысы бит син», – дип әйтә торган була.

– Яшьләр авылдан качу ягын карый. Ә син артист башың белән авылда.

– Авылның һавасы рәхәт. Сулыш алулары да икенче инде. Яратмыйм шәһәрләрен. Укып кайттым, җитте. Монда минем нигезем, – ди яшь-яшь Булат, картларча фәлсәфә йөртеп.

Булат беренче сыйныфтан гарәп алфавиты өйрәнә башлый. Үзе теләп. Өйдә дини кануннар тотучы юк. Хәзер уйлый: әби тәрбиясе шулай тәэсир итмәде микән? «Мин бәхетле, балалар бакчасына йөрмәдем, әби белән үстем», – ди үзе дә. Унынчыда укыганда, әбисе үлә. Булат аңа үзе Йәсин чыга. Гөлнара апасы, энесенең киләчәген уйлап, Россия Ислам университетына укырга керергә әзерли башлый. Әмма мәктәпне тәмамлаганда Булатны алыштырып куялармыни. Өзми дә куймый: «Артист булам», – ди.

– Унынчыда укыганда әти үз янына комбайнчы ярдәмчесе итеп алды. Көне буе иген кырында нишлим? Җырлыйм! Шуннан сәнгатькә тартылып китмәдем микән? Мәктәптә спектакльләрдә, КВНнарда катнаштым. Шул вакытларда Раил абый: «Мәктәптән соң кая барасың?» – дип сорады. «Өйдәгеләр, укытучы булырсың, диләр», – дим. «Синнән укытучы чыкмый инде. Әйдә, театр училищесына, аннан безгә эшкә кайтырсың», – ди. Миңа шул җитә калды, укырга керергә әзерләнә башладым. Гармунда уйнарга өйрәндем. Училищеда башны бәрә-бәрә укыдым. Вакытны заяга әрәм итмәдем. Укуны бетергәндә курс җитәкчебез Ринат Әюпов үзенә чакырды. Калада каласым килмәде. Мин бит әби белән үскән кеше, тынычлык яратам. Аннан соң кайда тудың, шунда файдага ярарга тиешсең дип уйлыйм. Буага кайттым да театрга эшкә кердем. Казан дәүләт мәдәният институтының режиссура бүлеген кызыл дипломга тәмамладым. Ләкин театрга килгәннән бирле өйдә торганым юк. Әлегә әти-әниләр нык, квартирант булып кына яшим. Без әле әти-әни кочагында яшәүче балалар.

Елмаеп кына торган хатыны Гөлназны да ике малай әнисе димәссең, яшь кызлар кебек. Ул да, ире белән килешеп, баш кагып тора.

– Узган ел коронавирус аркасында гына өйдә булды ул. Айлар буе гастрольләрдән кайтып керми.

– Нигә артистка кияүгә чыктым икән дигән уйлар килмиме соң? – дим Гөлназга, икебез генә калып серләшкәндә.

– Юрап китердем бу тормышымны, – ди тыйнак кына көлеп Гөлназ. – Укытучым Лилия апаның күршесендә Раил абыйлар фатир арендалап яшәде. Шуларга карап: «Эх, танылган кеше белән яшәргә иде», – дип уйлый идем. Менә хәзер үзем артист хатыны. Кемгә кияүгә чыкканымны белеп бардым. Яраттым. Җимешем генә дип торган кешене ничек яратмыйсың инде?! Гөлназ дип эндәшә икән, сискәнеп китәм. «Мин Гөлназ түгел – җимешем», – дип төзәтәм.

– Хәзер яшьләр кайнана белән яшәргә талпынып тормый...

– Ә мин башка тормышны күз алдыма да китерә алмыйм. Монда килен булып төштем. Инде үзем әни булсам да, һаман бала булып яшәвемне дәвам итәм. Әни белән әти янында рәхәт инде барыбер. Балалар караулы, тормышны буш җирдән башламадык. Әни дә, әти дә бик әйбәт кешеләр. Бала дип яшәүчеләр. Әти – минем яклаучым. Булат белән кайчак чак кына сүзгә килсәк тә (тормыш булгач, табак-савыт бераз булса да шалтырамый калмый), әти: «Минем кызга сүз әйтмә», – генә ди. Абый да бик яхшы иде.

– Төпчек мин дип әйттем бит, – ди, яныбызга килеп утырып, сүзне шаянга борган Булат. – Миңа бит хатынны да абый мәрхүм табып бирде. Әйе, чын әйтәм! Абый күрше авылда мәктәптә физкультура укытучысы иде. Укучыларны районга кросска алып барырга билгеләнгән машиналары килмәгән. Театрда ял көнем иде.







Абый шалтыратты. Абый сүзен ничек тыңламыйсың. Чыгып киттем. Укучыларны машинага утырттык та киттек районга. Яшь егет бит, көзгегә карыйм: артта бер чибәр кыз утыра. Күз кысам. Ул елмая. «Әһә, – мин әйтәм. – Булды бу». Юл буе шулай күз кысышып, елмаешып бардык. Районга барып җиткәч, абый: «Машина бар, син кайтып кит», – дигән иде. «Юк, – дим. – Алып килдем, кайтарып куям». Күңелгә ятты бит таныш түгел кызның елмаюы. Кайтарып куйдым. Кичен абыйдан телефон номерын сорап алдым. Шалтыраттым. Шулай очраша башладык. Өйдән дә чыгармый минем өчен саклаганнар Гөлназны. Ярты елдан соң өйләнештек тә. Төпчек малайның бер миссиясен үтәдем инде. Нәсел дәвам итәчәк, Гәрәевләр фамилиясе яши!

Малайларны үзем укытам!

Гөлназ белән Булатның бер-бер артлы ике малайлары Хәйдәр белән Илфат туа. Бала үстергән вакытта Гөлназ техникумны читтән торып тәмамлаган. Хәзер институтта укый. Балаларны карашырга Гөлнара апалары ярдәм итә. «Апа мине укытты, хатынымны укытты, малайларыбызны да укытачак әле ул», – ди Булат.

Әлегә малайларны әби укыта. Хәзерге вазгыять аркасында татар телен укыту әби җилкәсенә төшкән. Элекке кебек мәктәптә аерым класслар юк. Татар белән чуаш балаларын бергә кушканнар да, русча белем бирәләр. Балалар бакчасында да, нигездә, русча. Җаны-тәне белән татар хатыны булган Гөлфирә апа кул кушырып утыра алмаган. Татарча әлифба кайтарткан. «Ә», «ө», «ү», «җ», «ң», «һ» хәрефләренең мәгънәсен, татар сүзләренең асылын өйрәтергә үзе алынган.

– Татар телендә укып үскәннәр генә туган теленең чып-чын мәгънәсен аңлый. Өч сыйныф булса да чиста татарча укытырга кирәк, – ди тормыш тәҗрибәсе зур булган гап-гади авыл хатыны Гөлфирә апа. – Мәктәбебез русча укыта. Туган телдә укырга-язарга үзем өйрәтәм малайларны. Кулымнан килгәнчә телне саклап калырга ярдәм итәсе иде. Әле гарәпчәсен дә өйрәтермен дип торам. Тел белү зыян итми ул. Ә менә туган телне онытырга ярамый. Ата-баба теле ул. Буыннар өзелә аннары.

– Ә мин малайларны гармун уйнарга өйрәтәм, – ди Булат, гармунын кулына ала-ала. – Татар егетләре гармунда уйный белергә тиеш.


Аннан сыздыртып уйнап җибәрә. Малайлар әтисе тирәсендә сикерешә башлый. Әти кулга гармун алгач, өйдә бәйрәм! Бәйрәм итәселәре алда әле. Бабай да кулына гармун алачак. Әлегә инсульттан соң тернәкләнеп килә. «Гөлназга рәхмәт инде, ул карый. Бабайның кан басымын, шикәрен тикшереп кенә тора, укол ясарга да өйрәнде», – ди Гөлфирә апа.


Бергәләп табын янына утырышабыз. Өстәл тирәсендә кайнашкан Гөлназны Гөлфирә апа кат-кат табынга чакыра. «Ашамаган бит син!» «Ярар, өлгерермен», – ди тыйнак кына итеп Гөлназ. Гаиләдә бер-береңә булган хөрмәт әнә шундый игътибардан башланадыр, мөгаен. Кайтыртып торучы булганга да яшьләрнең чыгып китәсе килмидер. Күрше өй аркылы гына абыйсы сала башлаган йорт тора. Эше беткән диярлек, аңа да ягып торалар. «Анда күчү башка да килгәне юк», – ди яшьләр беравыздан. «Ул малайларга калыр. Бу йортны зурайттык. Әле гараж төзергә исәпләп торабыз. Яшәр өчен бар шартлар да бар», – ди Булат.

Килен белән кайнана һәрберсе үз урынын белә бу өйдә. Дилбегә өлкәннәр кулында. Яшьләр шуны танып яши. «Мин – оптимист. Килен төшкәч тә бернинди кагыйдәләр булмады. Ничек яшәсәк, шулай яшәвебезне дәвам иттек. Гөлназның нәсел-нәсәбен белә идем. Ул авылда да учетчик булып эшләдем. Килен түгел ул, үз кызыбыз. Нәрсә кушсак, шуны үтиләр. Аларны беркая чыгарып җибәрәсе килми. «Син акыллы булганга тавыш чыкмый сездә», – диләр авылда. «Юк, – мин әйтәм, – тату яшәр өчен бер генә кешенең акылы җитми, барысы да акыллы булырга тиеш». Аллага шөкер, бер-беребезне хөрмәт итеп яшибез. Тәтием дип кенә үстергән бердәнбер улыбызның яраткан хатыны бит ул Гөлназ. Илнурыбыз менә гаилә корырга да өлгермичә якты дөньялардан китеп барды шул...

Без китәр вакыт җиткәч, Булат та рюкзагын җыя башлады. «Мин репетициягә, кич спектакль, соң кайтам. Кичке ашка мине көтмәгез». «Ярар, балам», – диде ана, улына иркә караш ташлап. Гөлназ да бу сүзләргә күптән күнгән инде. Озата чыккач, безгә дә, иренә дә хәерле юллар теләде. Әкрен генә зирәклек туплаган Гөлназ белә: бар юллар да өйгә, төп нигезгә алып кайта. Исән-сау гына йөрсен җаные.









Шактый еллар балалар матбугатында эшләп, хатын-кызлар журналына күчү – әйбәт фал ул. Синең белән бергә ихласлык, яктылык, җылылык та күчә, һәм шулар болай да нәфис-нәзберек хатын-кызлар галәмен яңа төсмерләр белән баета. Сәйдә Зыялы иҗатының чишмә башы да «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасында. Аннары «Азат хатын» («Сөембикә») журналында әдәбият бүлеген җитәкли, җаваплы сәркатиб вазыйфаларын башкара. Талантлы журналист, үзенчәлекле шагыйрә, әсәрләрендә тормыш гаме, яшәү мәгънәсе бөркелеп торган язучы бу көннәрдә үзенең олуг юбилеен бәйрәм итә. Сәйдә апаны 80 яшьлек юбилее белән котлыйбыз! Укучыларыбызга аның өр-яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.



Сәйдә ЗЫЯЛЫ

АШЫГАБЫЗ, АШКЫНАБЫЗ...

Үзебезгә кирәк

Сау була күр,
Милли яшь җилкенчәк,
Денең дә юк синең, көнең дә –
Туган телдән йөзен чөергәннең
Сукыр йолдыз янсын күгендә!
Зөлфәт.
«Татар теленең каргышы».

Моңлы җырлар биргән –
син, туган тел!
Тел җимеше – безнең шигърият!
Тик үз теле булган халык кына
Җир йөзендә була чын милләт!

Телебездә – барлык гореф-гадәт,
Телебездә – халык йоласы.
Башын палач тоткан хәлендә дә,
Татар шигыре – Җәлил догасы!

Телебезнең саллы яңгырашы
Җирдән генә түгел,
Күкләрдән!
Юкка гынамыни, Габдулланы
Бөек Тукай итеп, йолдыз итеп
Зәңгәр күкләренә күтәргән!

Белә татар башка телләрне дә,
Ялкаулардан түгел милләтем.
Татар теле кирәк татар өчен!
Татар теле кирәк үзебез өчен!
Мөдәррисчә язсак,
Мин әйттем!

Заман

Ашыгабыз, ашкынабыз –
Нәрсәдер җитми һаман.
Без туктасак, дөнья үзе
Куалый торган заман...

Ашыгабыз, ашкынабыз –
(Алып калырга кирәк!)
Уйламыйбыз алын-ялын,
Ничек түзәдер йөрәк?

Ашыгабыз, ашкынабыз...
(Килгәнмени мәңгегә?!)
Ә гомер ул – бердәнбер ул,
Һәркемдә дә бер генә!

Кылларның тартылган чагы –
Күңелем шуны тоя.
Күңел тоя...
Әйтерсең лә
Кыллар өзелеп куя.

Тукталып тыңлап та алам,
Ә куллар кылда һаман.
Без кумасак, дөнья үзе
Куалый торган заман...

Болыт киткән

Агыла да болыт агыла...
Хәсән Туфан.

Безгә тигән кырыс язмыш сыман,
Агыла да болыт, агыла;
Балачакның болын-тугайлары
Аның агышында чагыла.

Агыла ул шулай...
Агыла да,
Туктап кала, тынып тын ала;
Сурәтендә – яланаяклы кыз
Басма өстенә басып су ала.

Басмада кыз. Көянтәсе иңдә.
Үрелә-үрелә тутырып су ала.
Гаҗәпләнеп ак болытка багам:
Мин үзем лә икән бу бала.

Мин үзем лә икән ак болытта,
Бөдрә чәчем җилдә тузынган...
Тар басмага басып яшьлек калган,
Болыт киткән,
Гомер узылган...

Тик игелек калды

Әйтелгәндер кайчак усал сүзләр...
Акыл йөри арттан. Сүз – элек.
Аткан уктыр сүзем.
Әмма нишлим? –
Күңелемдә бары игелек.

Ачу килгән чакта акыл китә...
И үкенәм хәзер тилмереп.
Ачу күптән үтте,
Әмма нишлим? –
Күңелемдә бары игелек.

Тән ярасы бетә, төзәлә ул...
Сүз ярасы сызлый илереп.
Җанда яши яра.
Нишләргә соң? –
Күңелемдә бары игелек.

Көннәрне дә төннәр алыштыра,
Тормый якты һаман сибелеп.
Җил-бураннар кичеп яши-яши,
Күңелемә тулды игелек.

Август

Җәйнең кулы ишек тоткасында.
Җәй ашыга, беләм, ашыга.
Алма кебек пешкән кыз баладай,
Йөгереп чыга көзнең каршына.

Җәйнең кулы ишек тоткасында –
Тукталган ул, гүя, киңәшкә...
Вәгъдәләшкән ярын көткән сыман,
Сөялгән ул моңсу миләшкә.

Серле көч

Тәгәрәде кояш офыкка ук,
Соңгы нурын сибеп, таратып;
Урап алды җирне төн пәрдәсе,
Сихри бер көч җәйде канатын.

Шул канатның җиле кагылуга,
Табигатькә булды әллә ни;
Миллион чакрымнардан
нурын сузып,
Җир гөлләрен йолдыз иркәли.

Кинәт шул мәл аваз сала җанга
Яшәешнең бетмәс аклыгы;
Ул авазда бөек сөю хисе,
Көмеш чишмәләрнең пакьлеге.

...Урап алды җирне төн пәрдәсе,
Серле бер көч җәйде канатын...
Табигатьнең бөек шушы серен
Гомерем буе яшим яратып...

Гамәлләр

Бер килгән без җиргә. Бер китәсе...
Табигатьнең катгый кануны:
Үз-үзеңне эзләп табу өчен,
Кешеләргә биргән януны.

Бер килгән без җиргә. Бер китәсе...
Һәрбер гомер җирдә санаулы.
Тану өчен яхшы һәм яманны
Кешеләргә биргән сынауны.

Бер килгән без җиргә. Бер китәсе...
Бездән кала бары гамәлләр.
Гамәл арасында хәләлне дә
Юлдан яздырырлык хәрам бар.

Бер килгән без җиргә. Бер китәсе...
Алмагач та коя алмасын.
Бездән калган гамәл арасыннан
Хәрам килеп чыга алмасын.

Сайлап кына бирер идем

Уенын-чынын
бергә кушып сөйлим,
Ачуланам кайчак, әй улым,
Үтсә иде, димен, ялгышларны
Читләп кенә синең һәр юлың.

Йөрмәсен, дип, балам җәфа чигеп,
Калмасын дип, юлда интегеп –
Сайлап кына бирер идем дә бит
Юлларның мин сиңа иң киңен.

Әмма кеше сайлый бар юлларның
Үзен чакырганын, дәшкәнен.
Тармасын, дип, юлың хаталарга,
Хафаларга минем төшкәнем...

Кисәтергә телим:
Язмышларның
Гыйбрәтлесен сөйлим яңадан.
Бу борчылу бездә – аналарда –
Дөнья яралганда яралган.

Чегән

«Тик дөресен сөйлим, –
дип, бер чегән
Ябышты ук минем кулыма –
Әйләнеп кайткандай булырсың,
Узылган гомереңюлыңнан».

Елмаеп карадым чегәннең
Хәйләле һәм серле күзенә.
«Гомерем юлы, – дим мин аңа, –
Язылган ич минем йөземә...»

Һәм чегән текәлеп карады
Сызыклар чуклаган йөземә.
Ни хикмәт: гаҗәеп үзгәреш –
Моң тулды чегәннең күзенә...

Төнге манзара

Учак сүнде.
Кыр-басулар өстен
Бөек төн пәрдәсе каплады.
Ишетелә ташлар арасыннан
Сай инешнең чурлап акканы.

Ялгыз кошкай моңлы көен суза.
Тавышы шәп, әйдә, көйләсен.
Инешкәйнең шушы агышына
Дөнья гаме сыйган диярсең.

Хөкем сөрә монда дөнья гаме,
Караңгы дип тормый ул тынып.
Учак сүнде,
Шушы караңгыда
Күңелемә инде яктылык.

Үкенеч

Хыял дулкынында гомер бакый
Җырлар яздык сөю турында;
Баралмадык
Тик икебез өчен
Кыйбла булыр изге урынга.

Ә ул урын мәгърур, биек кыя!
Нур түшәлгән барыр юллары;
Гөл-чәчәкле гүзәл үзәнлекләр,
Тынып тормый былбыл җырлары.

Шул кыяга басып,
йолдызларның
Һәрберсенә килде дәшәсем...
Таң калдырып күкне,
минем йөрәк
Әй яшьнәсен иде, яшьнәсен!

Һәр йөрәккә керсен бөек күкрәү,
Күз чагылсын мондый яшеннән!
Төн пәрдәсе безне яшергәндә,
Серләремне синнән яшермәм.

Тәкъдирләргә шулай язылгандыр:
Бәргәләнә, шаша дулкыннар...
Баш очымда йолдыз яңгырлары
Синең йөрәк булып сулкылдар.

Баралмадык изге урынга без...
Гөнаһ икән, аны кем аклар?
Күккә карыйм:
Күктән йолдыз ява,
Ә кыяда көзге яфраклар...





Алия РӘХИМОВА

Алия Рәхимова (Сипова) 1990 елда Әгерҗенең атаклы Иж-Бубый авылында туып-үсә. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы кызы буларак, мәктәптә үк иҗат дөньясында яши. Район, республика газеталарына мәкаләләр язып тора. «Алтын каләм» республика конкурсында призлы урыннар яулый. Иҗатка мәхәббәте көчле булса да, кечкенәдән табиб булырга хыялланган кыз Ижау дәүләт медицина академиясен сайлый. Бүгенге көндә Чаллыдагы БСМП ашыгыч ярдәм күрсәтү хастаханәсендә төбәкара кан тамырлары авырулары үзәгендә невролог булып эшли. «Бөтен кешеләргә дә: «Үзегезне, зинһар, саклагыз, сәламәтлегегезне кайгыртыгыз!» – дип дәшәсем килә», – ди ул. Алияне «Сөембикә» журналындагы беренче дебюты белән котлыйбыз! Игелекле хезмәтендә, иҗатында, гаилә тормышында уңышлар телибез!

КУЛГА-КУЛ ТОТЫНСА...

(Хикәя)

– Хәерле иртә! Иртәнге аш әзер! – дигән ягымлы тавыш Дамирның уйларын ераклардан, әллә кайсы почмаклардан тартып алып, салмак кына чынбарлыкның үзе каршына кайтарып куйды. «Ә-ә, иртә җиткән... – дип уйлап куйды ул. – Тормыш агымының чираттагы иртәсе җиткән...»

Төн үтеп таң атуга – галәмгә кояш нурлары сирпелүгә һәрбер җан иясе, һәр кеше, бар тереклек уяна, җанлана. Күзләр үзеннән-үзе ачыла, куллар, ирексездән, өскә сузыла, гәүдә үзенә бер рәхәтлек белән киерелеп куя, ә күңел ниндидер яңалыкка омтыла. Шулай булмыйча соң, дөньяга бит яңа көн туа! Бу күренеш һәр кеше өчен гадәти һәм шулай булырга тиеш тә кебек, ләкин Дамир өчен түгел. Ул икенче... Ул үзенчәлекле... Инде дүртенче ел рәттән Дамир өчен көн һәм төн дигән сүзләр берни аңлатмый, алар – бер төшенчә. Алар чуалган. Әйтерсең шаулап үсеп утырган гөл сабагына чүп үләне уралып үскән. Сынып, шиңеп төшәргә дә бирми, гөрләтеп яшәргә дә. Көн белән төн генә түгел, Дамир өчен вакыт төшенчәсе дә аңлата алмаслык нәрсәгә әйләнде. Вакыт чылбыры диләр, димәк, минут сәгатькә, сәгать тәүлеккә тоташырга тиеш. Дамир дөньясында бу закончалык та көчен югалткан. Аерым уйлар, ватылып төшкән көзге кисәкләре сыман китек-китек фикерләр. Хәтер хәзинәсе дә саеккан. Анда-санда гына ул кичергән тормышның якты һәм матур вакыйгалары аңында чагылып үтә. Бер мәл чайкалып тора да, диңгез өстендә уйнаган кояш нуры кебек, билгесезлек һәм чиксезлек эченә кереп тә югала. Нәрсә икән бу? Ник аның тормышы үткән заманда сурәтләнә? Бүгенгесе нәрсә дә киләчәге нинди аның? Бар нәрсә ниндидер караңгы пәрдә белән капланган. Ә чаршауның икенче ягында гына әнә бит тормыш кайный. Ул ишетә – аңа «Хәерле иртә!» теләделәр...

Сорасаң, бу хәлен Дамир үзе дә аңлатып бирә алмас, ни дип атарга да белмәс иде. Бу кадәрле чуалган хис-кичерешләрне бер кысага сыйдырырга аның аңы рөхсәт бирмәс иде. Ә медицина теле бу халәтне бер сүз белән атарга җөрьәт иткән: «кома». Дамир дүртенче ел инде шифаханәдә комада ята. Менә дүртенче ел инде аның язмышы тормыш бизмәненең нәкъ уртасына эленеп калган һәм бер якка да авышырга җыенмый кебек.



Рәсем: Наталья Васильева

Аның гәүдәсе тере, ул сулый, ул яши. Табиблар әйтүенчә, аның организмында матдә алмашы сәламәт кешенекеннән бер тамчы да аерылмый. Ул ризыкны кабул итә, бүлеп чыгара (трубкалар ярдәме белән, әлбәттә). Хәтта сулавын ул үзе сулый. Тик аның гәүдәсе бер хәрәкәтсез, шомырт кара күзләре дә бертуктаусыз йомык. Әнә шул караңгы пәрдә аерып тора аны дөньядан. Андый авыруларны еш кына үсемлек белән чагыштыралар, янәсе алар берни уйламый да, ишетми дә, сөйләшми дә. Тик шулай микән? Үз хәлен Дамир үзе генә белә шул...

Бу рәвешкә Дамирны эшендә юлыккан фаҗигале җәрәхәт китерде, баш миенә зыян килде аның. Операция арты операцияләр кичерде, тик алга китеш булмады. Иминиятләштерелгәнлектән, Дамирның хастаханәдә дәвалануын һәм кыйммәтле даруларны ул эшләгән оешма тәэмин итеп тора. Монда аңа аерым палата бирелде, шулай итеп, дүртенче ел аның йортын шифаханә алыштырды. Ул ялгыз түгел. Аның янында әнисе «яши». Утыз ике яшьлек улын ана ике яшьлек сабыен тәрбияләгәндәй киендерә, ашата, юындыра. Улының бар нәрсәне тоеп ятуын Хәлимә апа сизенә иде сыман. Ана күңеле бит ул, аны алдап буламы соң... Шуңа да ул улы белән сөйләшә, бернинди җавап кайтармаса да, бар җаны белән ышана – «Улым кайтачак, нygытып талган йокысыннан гына айныр да, менә-менә уяначак!» Әнә хәзер дә, таң атып, бүлмәгә шыпырт кына яктылык иңә башлауга, сикереп торып улына хәерле иртә теләде, шәфкать туташы керткән махсус ризыкны улына хәстәрли башлады. Ә Дамир? Нинди хисләр белән иртәне каршы ала икән ул? Тагын бер төн үткән, тагын бер көн түзәсе...

Үзенең халәте түгел, башка нәрсә борчый. Аның нygып кына килә торган яшь гаиләсе бар иде. «Ә ник «иде»?» – дип сорау бирә ул үзенә эченнән генә. Чынлап та нигә? Алар бит, шөкер, исән-сау – яраткан хатыны Гөлүсә һәм бәләкәче Данияр. Тик хәзер бернәрсә дә элеккечә түгел, алар янәшәдә юк. Йорт тутырып шау-гөр килгән бәхетле мизгелләре артта калды. Гөлүсә ялангач калган гаиләсен торгызырга көн-төн эшли иде. Ә кечкенә Даниярны әтисе янына алып килмиләр, нәни сабыйның нечкә күңелен җәрәхәтләүдән курыкты алар. Ә бала исә, эштән талып кайткан әнисе янына йөгереп чыгып, гел бер сорау белән каршы ала: «Әни-әни, ә әти синең белән кайтмадымы?» Нәрсә дип аңлатырга да, нинди сүзләр уйлап юатырга да белми әни кеше нарасыен. «Кайта, үскәнем, әлбәттә кайта», – дип, кочагында эретә «йомшак йомгагын» (Дамир улын шулай дип сөя иде бит)... Сагына Гөлүсә еракта калган ул бәхетле мизгелләрне. Әйтерсең моңарчы кайгы белми пыр-



хылдап очкан күбәләкнең чуар канатын каерып киткәннәр. Яңадан алып кия алырмы ул сыңар канатын? Элеккечә рәхәтләнеп еракка-еракка, биеккә-биеккә оча алырмы, Дамиры белән бергә «тигезлек» аланында «бәхет» нектарын җыя алырмы чәчәкләрдән?.. Авыр аңа бер ялгызы тормыш йөген тартулар. Ә көннәр үтә тора, кара пәрдә элеккечә ябык...

Дамир күңеле менә шуларны уйлап сыкранды. Йомык күзләр, хәрәкәтсез гәүдә эчендә хисләр шаукымы, каршылыклар, борчулы уйлар өере кайный. Эчке дөньясын күрсәтә алса, хет бер сүз әйтә алса икән ул! Инде туганнары, дуслары Дамирның аңына килүенә ышанмыйлар, хәл-әхвәлен белешергә килүчеләр дә сирәгәя. Дамирның җавап бирүен бер ялгыз ана күңеле һәм соңгы тамчы көчен җыеп Гөлүсә көтә.

– Улым, тышта ябалак-ябалак кар ява. Бар галәмне бүген баштанаяк аклык күмеп китте, син бер генә күрсәң икән! Зифа каен кызларым купшы бүрекләрен алып киде, нечкә билле чыршы сеңелләрем затлы шәлләрен иңнәренә салды. Ә шаян-шук песнәк малайларының тирә-юньгә исе дә китми. Алар миләш тәлгәшләре белән дус. Песнәк халкы бик җитез ул, әнә тәрәз артына салган җимне чүт кенә кул учымнан чүпләмиләр! Дусларым песнәкләре-е-ем... – Олы йөрәкле Хәлимә апаның кул җылысы тирә-юньдәге һәр җан иясенә җитәрдер ул... Палата тәрәзәсендәге күренештән озак кына хозурланып торганнан соң, Хәлимә апа Дамир янына килеп утыра, улының куе чәчләрен сыпырып ала да дәвам итә:

– Ә исеңдәме, улым, кечкенә чагыңда син атлар ярата идең. Әтиең атын тугаруга, син йөгереп килер идең дә, алардан бер адым калмас идең. Ә туган авылыбыздагы җәй көннәренең ямьлелеген искә алса-а-ак!.. Печән өсте җитә калса, бар авыл халкы пошаманга төшәр иде, авыр янәсе. Ә без әтиең белән сөенер идек, чөнки табигатьне бик яраттык. Текә елганың аръягы иде безнең печәнлек урыны. Хуш исле каен җиләкләре, бөтнек-мәтрүшкәләре дисеңме... Печәнен өеп, әтиең арбаның иң өстенә сине утыртыр иде. Ә син, бәләкәч, печән арасыннан чүпләп, өзелгән каен җиләкләрен татып кайтыр идең...»

Дамир тыңлап ятты, самими балачагын искә алып, күңеленә җылы йөгерде. «Их, бер мәшәкатьсез рәхәт бала чакларым! Әнкәй, ә син туктама, сөйлә син, сөйлә...»

– Ә хәтерeңдәме, улым, берсендә әтиең сиңа елан тиресе табып алып кайтты. Син аны камчың тоткасына бәйләп куйдың. И-и, күрше малайларының кызыгуы шул ялтырап торган бизәкле камчыңа!.. – Хәлимә апа кеткелдәп көлеп куйды...

Озын көннәр менә шулай үтә торды. Хөр күңелле, сабыр холыклы Хәлимә апаның улы белән бертуктаусыз сөйләшүе Дамирга ниндидер көч бирде. Шуңадыр да Дамир, бар күңеле белән калтырап, тынлыктан курыкты. Бер ялгызы калса, аңы тагын да томалана, башы белән ниндидер төпсез чокырга ташланган кебек була.

«Әнкәй, кая югалдың, эндәш. Ташлама мине кара упкынга...»

– Тыныч йокы, улым. Исән-имин иртәгәсе көннәрне дә каршыларга язсын, – дип, Хәлимә апа шулчак тавыш бирә, улының юрганын рәтли. Бераздан аның пышылдап укыган дога тавышы, дисбе тартуы ерактанрак ишетелә – Хәлимә апа үз урынына барып ята.

«Әһә, төн дә җиткән», – дип уйлап куйды Дамир. «Әнкәй, тәрәзәдән җил өрмәсен, юрганың җылымы икән...» – бала күңеле анасына эндәште. Их, сикереп торасы иде дә, әнкәемнең аяк очына егылып рәхмәт укыйсы, бала чактагыдай рәхәтләнеп бер үкси-үкси елыйсы иде... Тагын ничә төннәр, ничә көннәр үткәндер, Дамир урамда ничәнче ел икәнен дә тәгаен дөрес җавап бирә алмас, мөгаен.

...Бүген Дамир янына Гөлүсә киләсе көн. Дамир хатынын гадәттәгедән ныграк зур түземсезлек белән көтеп алды. Әллә нидер сизенде шунда... Бер мәл палата ишеге ачылып китте, эчкә тын гына узган аяк тавышлары ишетелде.

«Гөлүсәм, килдеңме, күз нурым, нинди яңалыклар алып килдең? Йомшак йомгагым ниләр «кыра»? Сәлам җибәрдеме миңа?.. Тукта, ник син тынып калдың, Гөлүсәм. Әллә нинди син бүген...» – дип хафаланды Дамир. Гөлүсә тын яткан «гәүдә» янына килеп утырды. Дамирның яше барса да, ничә ел инде урын өстендә ятса да, гәүдәсе элеккечә нык һәм төз иде. Аны авыру дияргә һичкемнең теле әйләнмәс. Шаккаткыч хәл, әйтерсең яшьлеге чәчәк атып килгән егет бераз черем итеп алырга, ял итәргә дип кенә яткан. Күптән корал тотмаган куллар һәм кояш назы тоймаган йөзе яңа яуган кардай агарып калган. Бу күренеш Дамирны тирә-яндагылардан, гомумән, җир йөзе кешеләреннән өстен куя, аның гәүдәсеннән ниндидер якты нур сирпелеп тора кебек. Гөлүсә Дамирның кулын үзенең кулына алды. Авыр тынлык урнашты.

– Дамир, син беләсең, без бик бәхетле булдык. Яшьлегемнең иң күңелле һәм иң кадерле мизгелләре синең белән үтте. Гомеребезнең соңгы көненәчә бергә булырбыз дип ышандык без. Мәхәббәтебез җимеше Даниярыбыз булды... – Данияр сүзен әйткәндә Гөлүсәнең күзләренә яшь җыелды, тамагына төер утырды. – Беләсеңме, Даниярыбыз үсеп килә, тиздән мәктәпкә аяк баса. Инде ул сабый түгел, күп нәрсәләрне аңлый. Дамир, әйтәсе килгән сүзем шул, Даниярга әти кирәк... – Гөлүсәгә бу сүзләрне әйтүе кыен иде, тамагындагы төерне һич йота алмады ул, алсу бите буенча йөгергән яшь бөртеге Дамирның кулына тәгәрәп төште. Төште дә кайнар юл ярып, Дамирның йөрәгенә барып кадалды.

Азат бик яхшы кеше, Дамир. Улыбызга әти булырга, аңа ышанычлы таяныч булырга теләк белдергән кеше ул. Син, зинһар, берүк дөрес аңла. Синең ризалыгыңны сорарга килдек, Дамир... – Гөлүсә яшьләренә буылып, Дамирның гәүдәсенә капланды.

Шулчак моңарчы ишек төбеннән алга узарга кыймаган Азат сүзгә кушылды:

– Гөлүсә, тынычлан, тиргәмә үзеңне. Дамир, әти кеше буларак, аңларга тиеш, сезгә ул тик бәхет кенә телидер дип ышанам. Сиңа да, улыңа да ярдәм һәм терәк кирәк, тормыш бит дәвам итә.

Гөлүсә үксүеннән туктап, бераз тынычланып калды, башын күтәрде. Яшь хатынның йөзе үзгәргән, күзләрендә – сагыш упкыны. Әйтерсең ул күзләрдә сагыш ялкыны шашып-шашып янган да үзеннән соң бары тик ике кара күмер кисәге калдырган. Ә йөзе тораташ катып калган. Әлеге кеше инде Гөлүсә түгел, кайгыдан сүрелгән күңеле нишләтсәләр – шуны тыңлый, кая борсалар – шунда борылды. Азат бу хәлне күтәрә алмады, тормышында очраган әлеге ханымны кара упкыннан тартып чыгаруны һәм аның улын аякка бастыруны үзенең бурычы итеп куйды. Азат Гөлүсәне палатадан чыгарды да үзе Дамир янына килеп басты, аңа нидер әйтергә теләп, иреннәре кыймылдады... Тик Азат әйтәсе сүзен әйтә алмады... Әллә авызы кипте, әллә нык булып күренергә теләгән ир-ат чыннан да каушап калды. Күз яшьләре җыелуын сизеп, үзен тиз арада кулга алды, кинәт кенә Дамирның кулын алып ир-атларча ныгытып кысты да, палатадан ыргылып чыгып юк булды. Ике ир-ат сүзсез генә шулай аңлашты бугай...

Дамир янә бер ялгызы калды... тагын җаннарны өшетердәй тынлык урнашты. Ике минут эчендә булып узган шушы хәл вакытны тәмам туктаткан кебек булды. Дамирның аңы тагын томаланды. Аңа бу сүзләр куркыныч төш кебек тоелды. Күңеле кар өеренәй бер тузынды, бер тынып калды. Ата булу бәхете, гаилә тормышы, ир-ат горурлыгы, гомумән, киләчәктә җир йөзендә кеше булып яшәүдән ул бүген үзен мәхрүм санады. «Нинди кеше булыйм ди мин, җүләр! Инде ничәнче ел үземне кешегә санап тормыш кичердем, ә чынлыкта мин хәрәкәтсез утын кисәге!» – дип ачынды, үз-үзен сүкте Дамир. Әйе, әле моңарчы хис-кичерешләр белән яшәгән гәүдә хуҗасы ничек үз барлыгын терелә́й «күмсен» ди. Ул ышанды, гадәти тормыш юлына басасына, савыгасына чын күңеленнән ышанды бит ул. Ә бүген бар өметенә нокта куйды. Инде омтылыр максаты, ышаныч чаткысы, яшәү мәгънәсе юк иде шикелле. Гөлүсәгә үпкә тотарга хакы юклыгы белән дә ризалашты. Азат үзе дә начар кешегә охшамаган лабаса. Уйлары белән бер ялгызы калган Дамир үзенә-үзе хөкем чыгарды, ә Азат белән Гөлүсәгә тын гына хәер-фатихасын бирде. Шулчак үзе дә сизмәстән, әллә кайсы почмактан җан авазы, өздереп, бер көй сузып җибәрде, Дамир әлеге көйнең сүзләрен исенә төшерә алмыйча озак азапланды:

Әйткән идең:
Әгәр сөя калсаң
Миннән башка берәр бүтәнне,
Сөй бары тик миннән яхшыракны,
Сөймә ләкин миннән түбәнне...

Шушы көйгә уралып, Дамир саташуын сизде, ә күңеле белән Азатка мөрәҗәгать итәргә ашыкты: «Кара аны, улымны ышанычлы кулларга тапшырам дип ышанам, миннән яхшырак ата бул аңа...» Дамирның соңгы аек теләге менә шул булды... Өермә булып тузынган хисләре тынып калды, уйлары «сыегайды», салмак кына янган яшәү шәмененң ялкыны сүнеп килде... Инде сүнеп юк булам дигәндә, Дамир кинәт сискәнеп китте. Шулчак палата ишеге ачылып китеп, Гөлүсә атылып керде... ә аның артыннан, шул шаукымга бөтерелеп диярлек, тагын кемдер иярде сыман. Гөлүсә йөгереп керүгә үк Дамирның муенына сарылды: «Беркайчан, һичкайчан, берничек һәм беркайда калдырмам сине, җаным! Бары тик сине яраттым һәм яратам! Гафу ит мине! Бернинди киртәләр дә безгә каршы тора алмас, тормышның бөтен сынауларын да бергә җиңәрбез, сүз куешканча, соңгы көнебезгәчә бергә булырбыз! Миңа бары тик син кирәк. Безгә бары тик син кирәк!» Гөлүсә белән ияреп керүче һәм тын гына басып торучы – бәләкәч Данияр иде... Гөлүсә шулчак улын алга кертергә дип ишек турысына борылыйм дисә, ни күрсен! Данияр инде шыпырт кына алга узып, әтисенең кулын нәни учларына алган, алган да аларны тын гына сыйпый иде. Гөлүсә сүзсез калды, күңеле тулды, нәни улын күтәреп алып Дамиры белән икесен бар көче белән күкрәгенә кысты. Барлык борчулары шул күкрәктә кысылып юк булды, ярсып-ярсып аккан бәхет яшьләре еллар буена таш булып каткан сагыш чуерларын юып алды. Әтисенең ничә еллар буена кайда юк булып торганын белмәгән, аңламаган улының читләшмәвенә гаҗәпсенде дә, сөенде дә ана күңеле. Бер гаилә җебе нык булган, күрәсең, анасы кебек үк атасын кичәгедәй көткән, яраткан, сагынган һәм йөрәгеннән җуеп ташламаган икән нарасые! Их, шулай булмыйча соң! Бала бит тәннән ярала, җаннан тама...

Дамир үзен янә төштәгедәй хис итте... Бәхете, сөенече эченә сыймады аның. Әлеге төштән айнырга курыкты ул, ләкин чын-чынлап уяну, яшәү теләге бүген ярларыннан чыгып ташыды! Гөлүсәсе һәм бәләкәче бүген төнне әтиләре белән үткәрергә булды. Ниһаять, бүген аның гаиләсе янә бергә җыелды, нәкъ элеккечә бар да янында... Кешенең ике як җилкәсенә ике фәрештә кунган, диләр. Дамирның бүген уң як җилкәсе янәшәсендә – әнисе, сул як җилкәсе янында – яраткан Гөлүсәсе, ә аяк очындагы юрган почмагына «йомшак йомгагы» уралып яткан. Шуннан да зуррак бәхет тели аламы соң ул үзенә?! Гөлүсәсе исә бу төнне күңелле төш күрде, әйтерсең Дамиры кулын күтәреп аның иңенә салды һәм аны кочып куйды. Гөлүсә шатланып уянып китүгә – әллә төше булдымы, әллә өнеме – үзенең иңендә ул чыннан Дамирның кул җылысын тойды!!! Гөлүсә шул халәттә кыймылдарга да кыймыйча, серле елмаеп куйды. Ул хәзер бер нәрсәне төгәл белә – ышаныч һәм өмет кулга-кул тотынса, бергә алар таулар күчерә!





Рамил ХАННАНОВ

Рамил Ханнанов – бөтен барлыгы белән әдәбият, фән, иҗат кешесе ул. Мәктәп елларында ук татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларда җиңеп чыккан, Шигырь бәйрәмендә Г. Тукай һәйкәле янында шигырьләр укыган Әлмәт егете Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының филология факультетын кызыл дипломга тәмамлый. Рамилне студентларның «Илһам» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе итеп тә, «Яшьлек тавышы» һәм «Дарел-фөнүн» студентлар газеталарына нигез салучы буларак та беләләр. «Мирас», «Казан утлары» журналларында баш мөхәррир урынбасары булып эшли. Әдәбият дәреслекләре, методик кулланмалар авторы. Филология фәннәре кандидаты. Үзенчәлекле хикәяләре белән укучылар күңелен яулаган язучы. «Ул телебез хасиятенә бик сизгер. Образлы итеп, нечкәлекләренә кереп яза. Хикәяләрен җор-йөгерек теленә сокланып укып чыктым», – дип яза Марсель Галиев. Бүген «Сөембикә»дә – Рамил Ханнановның дебюты.

КУЯН МАМЫК БИЯЛӘЙ

(Хикәя)

Эш бүлмәмнең ишеген тыйнак кына шакып, бер абзый килеп керде. Кара төсенә тут кунган киез итекләреннән карашын кыяр-кыймас кына күтәреп исәнләште.

– Энем, исәнмесез! Әнгам абыең булам мин. Ни иде бит... Винарис белән бергә укыган идек – классташлар. Ул керергә кушты да, менә...

Уемына тотка теле кадалып бетмәгән һәм ябылмый калган ишек ярыгы сызылып кына киңәя башлады. Идәннән өч-дүрт карыш биеклектә әүвәл бер баш, аннан соң сөям ярым югарырак икенчесе күренде. Үзен эш бүлмәмә алып кергән тарафка аркасы белән басып торса да – минем күзләрдә чагылган нәни шәүләләр саттымы, әллә колагы белән дә күрергә инде өйрәнгәнме – Әнгам абый җәлт кенә башын борды. Тавышын шелтәле югарылыкта тибрәндереп алды:

– Ишек төбендә шыпырт торыгыз, дидем лә мин сезгә! Кыбырсымагыз!

– Ярар ла, Әнгам абый, керсеннәр. Үсеп килүче буынны һәрвакыт колач җәеп каршы алабыз без уку йортыбызда, – дияргә ашыктым һәм кызыксыну катыш гаҗәпләнү тулы ике пар күзгә таба атладым. – Исәнмесез!.. Менә әле дә «Ачык ишекләр көне» уздырырга әзерләнеп йөреш. Винарис абый әйткәндер...

Ара-тирә кергәләгән кунаклар өчен махсус хәстәрләп куйган урындыкларга һәр өчесен җайлагач, Әнгам абыйны тыңларга әзерләндем.

Әти кеше нидән башларга белми иде бугай. Йомышының җеп очы булачак төп җөмләсенең биатасынмы, бианасынмы авыз эчендә көрмәкләгәндә, балаларның энесенә апа тиешлесе урындыктан шуып кына төште дә өстендәге җылы курткасын салды. Аны тәртипләп төргәч:

– Эссе, кая әле, син дә тирләп беткәнсең, – дип, өч яшьләр чамасындагы зур кара күзле малайның изүен чишеп җибәрде.

– Зифа, кызым, утырсана... Ишек төбендә генә көтегез, дидем бит мин сезгә. Олылар сөйләшкәндә...

Әнгам абый чигәсенә чал кунарга иткән башын янәдән миңа таба борды.

– Кичер инде, кыбырсыклар шул. Бүген авылда калдырырга җай чыкмады. Садикны ремонтка яптылар. Әби-бабалары эштә. Күршедәге Миңлебикә апа районга – кызларына киткән иде. Юкса монда кадәр электричкада ташып та йөрмәс идем үзләрен, – дип акланды ул.

– Әнгам абый, борчылмагыз, алар безгә комачауламас. Шулай бит, үскәннәрем? – дидем мин, чарасыз калып.

– Юк-юк, абый! Без сүз тыңлыйбыз, – дип ярып салды «Әлифба» яше кергән Зифа. – Менә Зөлфәт бераз елаграк иде дә, инде ул да зур үсте – өч яшь аңа хәзер.

– Өс! – дип, бармакларын тырпайтты каракүз.

Зифа коеп куйган әтисе иде: шундый ук түгәрәк йөздә сабыр хәрәкәт иткән уйчан яшькелт күзләр, һич сыгылмасыз кыл керфекләр, үзара сүз сугыштырып аерылышкандай бер-береннән ераграк урнашкан куе кашлар, кылыч борын, чама белән генә уелган авызны каймалаган күперенке иреннәр, кап-кара туры чәч. Зөлфәт исә тач киресе: озынчарак йөзен балкытып, зур кара күзләре елгыр йөгерә, озын керфекләре билдән дугаланып бөгеләләр дә дулкын-дулкын таралышкан маңгай чәченә багалар, кашлар шулай ук куе, ләкин җәлпәграк түгәрәк борын өстендә менә кавышам, менә кавышам дигәндәй, якыннар, бераз җәенкерәк авызны ым тәртибе төгәл билгесез иреннәр әйләндереп алган. Күрәсең, әнисенә тарткандыр малай.

– Әле үзеңнекеләр юктыр, бик яшь күренәсең... Минем кыбырсыкларны ачуланма инде... – дип, гафу үтенү шәкелендә тирән көрсенде Әнгам абый.

Бер тоҗым гына сүз бушлыгы хасил булды. Урынымнан капылт торып, электр чәйнегенең лепкәсенә төртеп килдем. Аның су шаулаткан тавышына кушылып, гаилә башлыгы:

– Шула-а-ай, – дип пышылдады. Аннары төс-кыяфәтен кисәк үзгәртеп, миңа таба сузылды да, сүзләрне өсте-өстенә бастырып, балалар төшенмәсен дигәндәй, теш арасыннан сытып кына тезеп китте: – Хатынны үтердем бит мин, энем! Өзелеп яраткан бердәнберемне. Менә бу балаларның әниләрен. Узган ел, Казаннан кайтканда. Әллә ничек кенә килеп чыкты: әйләндереп капладым машинаны. Сигезенче март бәйрәме иде ул. Хатынымның туган көне дә! Балаларны әниләрдә калдырып, иртүк калага килдек. Утыз биш яше тулган көнне хатынга алка-беләзек алыйк, кием-салым кибетләрендә өс-баш яңартыйк, тәм-том төяп кайтып, гаиләдә бәйрәм ясыйк, дигән идек. Алка-беләзеге дә алынды, өс-баш та яңарды, тәм-том да төялде, тик менә бәйрәме генә җеназа мәрәсименә әверелгән. Миннән башка җирләгәннәр. Аңсыз булганмын. Хушым кайткач, хатынымны эзли башладым. Әти-әнисе үзләре килмәсә, күзләренә ничек күренер идем, белмим – рәхмәт, ташламадылар, суд юлында йөртмәделәр! Ә тикшерүче утыртырга бик теләгән иде... Кайгылы хәбәрне икебезнең әтиләр бергә керәп җиткерде. Өч айга якын больницада яттым. Гомеремдә дә рульгә утырмыйм дип ант эчтем.

Әнгам абый тынып калды. Уйчан яшькелт күзләрендә мөлдерәп-мөлдерәп алган тамчылар тамарга базмады. Күрәсең, читенсенделәр. Әллә болай да шактый түгелгән күңел тәрәзәләрен коргаксытудан куркып кызгандылармы?!

Чынаякка куе кара чәй агызып, Әнгам абыйга суздым.

– Бик кайнар булды инде бу, – дидем, тынлыкны бозып.

Әтиләренең һәр сүзен ишетергә тырышып шым калган, тәкъдир култамгасын иртә таныргa өйрәнеп килүче сабыйлар да кымшанышып куйды. Нарат урманында агач аударып йөргән аю сурәте төшерелгән кәгазьле конфетларны учларына сондым.

– Рәхмәт, абый! – диде Зифа.

– Ә-әх-мәт, абый! – дип кабатлады Зөлфәт.

Кайнар чәйне өрми-нитми зур-зур уртлагач, Әнгам абый сөйләгәннәренә нәтиҗә чыгарды:

– Рәхмәт, энем! Минем авыз пешми хәзер, әллә нишләп, салкын-кайнарга, баллы-тозлыга бер дә исе китми. Хатынсыз ир – тукрансыз агач, дип шаярта безнең авылда бер абзый. Имеш, тукып-чукып торучысы юк. Аның икенче ягы да бар бит әле: тукран – урман табибы. Тукрансыз урман корый. – Күтәрелеп карамый гына дәвам итте: – Менә хатынымның туган һәм... үлгән көне җитә. Сигезенче март көнне елын укытабыз. Радиога бер гыйбрәтле нәрсә язып булмасмы дигән идем... Бөтен татар халкы ишетерлекне. Күзнебашны тондырып, дөньяны йотардай булып чабабыз. Язмышыңа язылганнан ары сикерәм димә икән лә ул!.. Үзем сызып-бозып карадым да – чыкмый. Һәр һөнәрнең үз остасы шул. Винариска килдем, университетта эшләгәч, уку-язу тирәсендә кайнаша, мәктәптә шигырьмигыр да сырлаштыра иде, бер-бер җаен табар, минәйтәм. Ул сиңа кертеп җибәрде. Радиода безнең авыл кызы эшли. Тормышны күрмәгән әле, башкарып чыга алмас. Янына берәр кәгазь кисәге тотып барыйм дигән идем. Менә шул, энем, кире борма инде, буш итмә.

Минем ризалыкны да көтеп тормыйча, Әнгам абый урыныннан кузгалды. Укытучым Винарис Хамматович: «Ни итсә дә итәр, әйткәнеңне вакытында җиренә җиткезер», – дип кертеп җибәргәндер, мөгаен. Гәрчә бер эшкә дә әле беләмәнлек белән ышандырып алынырга тырышмыйм үзе. Укытучымның кичәге шәкертен шулай сынавымы?..

Зифа энесен җәлт-җәлт киендерә башлады. Җылы бинадан буранлы февраль кочагына коелырга тиешле сабыйларын күздән кичереп, башлык-якаларын бераз тәртипләгәч, Әнгам абый миңа дәү кулын сузды да:

– Өч көннән киләм, энем. Борып чыгармассың инде, яме! – дип, ничек тыйнак кына кергән булса, шулай тыйнак кына чыгып та китте. Ул хушлашканда, Зифа белән Зөлфәт инде бүлмәмдә юклар иде.

Ишеткәннәремне фикер чүлмәгендә эшкәртеп исемә килсәм, өстәлемдә Әнгам абыйның хатыны, Зифа белән Зөлфәтнең әниләре турында кыскача мәгълүмат язылган кәгазь бите ята, аңа – арткы ягына – бер конверт



беркетелгән. Ачтым. Эчендә – фоторәсем. Һәм... нәкъ мин күз алдыма китергәнчә, уллары Зөлфәт килбәтеннән фаразлап күзаллаганымча... Тиз генә урынына кире салып куйдым.

Әнгам абый калдырганнарны эш кәгазьләре белән бергә портфелемә тыктым да кайтырга җыена башладым. Ишекне бикләп чыгуга, күз карашым төшеп калган сыңар бияләйгә кадалды. Иелеп алдым. Бәләкәй – баланыкы. Куян мамыгыннан бәйләгәннәр үзен. Кайчандыр кырпак ак булган, шактый керләнгән, күпереп торган өрфия мамыгы да басылган. Зифаныкыдыр инде бу. Малай кешегә ак бияләй кидермәсләр. Эш бүлмәсен кире ачып, табылдыкны өстәлемә кертеп калдырдым.

Шәһәрдә буран котыра. Февраль бураны. Болакны тутырырдай булып кыланган кар туе арасыннан бәргәләнеп очкан ала каргалар пылт итеп килеп чыга, азык юнәтеп йөргән урам этләре җәяүлеләрне куып җитеп, лерт-лерт узып китә, халыкны эштән өйләренә ташыган троллейбусларның мыекларыннан чыртлап чәчрәгән чаткылар күренеп кала. Чебеш күзләп очкан тилгәннәрдәй, капкорсак эвакуаторлар шәһәр өстендә бөтерелә. Ачыгавызларның машиналарын чыелдатмый гына чукып алалар да штрафстоянкаларга илтеп тондыралар. Мондый да болганчык көнне аларга уңыш аеруча киң елмая.

Минем башта да буран. Хисләр, уйлар бураны бөтерелә... Кирәклесен чыелдатмый гына чукып алмалы түгел.

***

Диктор бер сулышта укып чыгып, тыңлаучыларны тетрәндерерлек тирәнлеккә ия каләм җимеше озак өлгерде. Кечкенә генә йомырка салу өчен дә айлар буе түл җыярга кирәк шул. Ә монда – өч көн! Кайта-кайта төзәтеп, үзгәртеп, күп интектем. Әйе, китаплардан укып, телевизордан күреп, кеше сөйләгәнне тыңлап кичерү бер икән, ә менә ике нарасыен кочып, яшьли сыңар канатка калган, тормышының күп принципларын җимереп, тамырдан үзгәрергә мәҗбүр ир йөрәгә аша уздырып әйтеп биреп кара син аны!

Өч көн рәттән, авыл сәгатьләрендә кичке ял вакыты суккач шалтыратып, эшнең барышын сорашып торды Әнгам абый. Укып бирүемне дә үтенде. Күрәсең, шиге зур булгандыр.

Өч тәүлек узды. Дүртенче көнне иртәнге сигездә эш бүлмәмнең ишеге төбендә мине көтеп тора иде инде ул.

Әнгам абый керә-керешкә китаплар шүрлегендәге куян мамык бияләйне күреп алды да сөенеченнән кычкырып ук җибәрде:

– Менә кайда икән ул! Балалар белән тәмам хафага калдык. Зөлфиякәем бәйләгән, күз нурларын, йөрәк җылысын салган бияләй бит...

Үз чиратымда:

– Әйе, теге көнне төшереп калдыргансыз. Кертеп куйган идем шул... – дип җавапладым.

Әнгам абый табылдыкны йөзенә тидереп алды, әйләндереп-әйләндереп карады. Бүген ул икенче иде. Тормыш йөге баскан кырыс ир миңа мәгълүм күңел дөньясының капма-каршы ягын ача иде.

– Рәхмәт, энем! Игътибарың өчен рәхмәт! Бик кадерле... Зөлфиямнең кулы тигән һәрнәрсә бик кадерле бүген. Икесен парлап, керешкә таккан иде ул аларны, берсе өзелеп төшеп калган. Зифаныкы бу. И-и, куанып инде. Табылуы шәп булды, юкса парсыз бияләйнең бу тормышта кемгә хаҗәте бар...

Радиодан укылачак текстны без озак төзәттек: сүзләрен алмаштырдык, җөмләләр, хисләр өстәдек. Мин язганнарның азы гына калды.

– Зөлфиякәемнең сурәтен бир әле, – дип, теге конвертны сорады Әнгам абый. Сак кына ачты, фотоны кулына алды. – Әнә бит ул нинди чибәр, ничек назлы итеп елмая... Күрәсеңме, энем?..

Мин җавапсыз идем. Үз дөньямда идем. Гаебемне таныйм: язганда ул фоторәсемне конвертыннан чыгармадым. Аңа карасам, бәлки, яхшырак текст туар иде. Нигәдер кеше мәхәббәте салынган, җисеме бу дөньяда булмаса да, исеме кемнеңдер йөрәгендә мәңге исән сылуҗан рухын саклаган дүртпочмакны ачып, саф сөюне тынгысызлыйсым килмәде.

Уйларымны Әнгам абый бүлдерде:

– Энем, башкарып чыктык бугай. Рәхмәт инде сиңа! Тик бер үтенечем калды. Мин шагыйрь түгел. Әни яраткан шагыйренең исемен куштырткан булса да, шигырь-мигырьга һәвәслегем юк. Шулай да менә бу юлларны өстәп куйыйк инде.

Һәм кәгазь кисәге сузды. Болай язылган иде анда:

Бүген төнлә бер төш күрдем –
Арыш тараткагымны.
Чардуганыңа сөялеп
Сөйлим яратканымны!

Шунда Әнгам абыйга шагыйрь исемен юкка кушмаганнарын аңладым: аның йөрәге мөлдерәмә шигырь, күңеле тулы мәхәббәт иде. Күгәргән йөрәктә сөю сусәрә. Ул моңа юл куймаска тырыша, күрәсең. Йөзе сагышлы булса да, шул ук вакытта бик канәгать тә иде.

...Радио хезмәткәрләренең хәер-фатихасын гына көтәсе калды.

***

Халыкара хатын-кызлар көненең кемнәргәдер күпне вәгъдә иткән таңы атты. Хатынлы тормышымның тәүге Сигезенче марты. Яңа өйләнешкәннәргә хас булганча, Казандагы иң матур чәчәк бәйләменазланып ятучы сөеклем уянганны көтә. Аш бүлмәсендә талгын гына сөйләп торган радиодан бәйрәм котлаулары яңгырый.

Иртә әле...

Бераздан караңгылык тәмам таралып бетте, һәм шәһәр өстенә яз кояшы елмайды. Өй эченә кояш нуры керсә, могҗиза көт, ди халык. Бүлмә дә, җирле гөлләребез дә, вакытлы шатлык өләшеп утырган чәчәк бәйләме дә нурга коендылар...

НИНДИ ТӨСЛЕ КИЕМ КИЯРГӘ?



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Ни өчен кайбер төстәге киемсалымны кияргә рөхсәт ителми? Мәсәлән, ир-атларга кызыл төстәге киемне сайларга ярамый, диләр.

– Шәригатьтә киемнәрнең төсләренә карата таләпләр, чыннан да, бар. Ләкин бу таләп кызыл төскә генә кагыла, анысы да, сез әйткәнчә, ир-атларга гына. Пәйгамбәребез ирләрне җете, ачык кызылдан булган киемнәр киеп йөрүдән тыйган. Шундый бер очрак булган: Пәйгамбәребез яныннан бер кеше узып киткән. Ул сәлам биргән, әмма Пәйгамбәребез аңа җавап кайтармаган. Чөнки бу кеше баштанаяк кызыл киемнән була.

Шулай ук сары, дөресрәге, куе сары, кызылга якынрак төс тә ирләр өчен тыела дип телгә алына. Кызыл яки сары төстәге кием кигән ир-атны күрсә, Пәйгамбәребез аны үз янына чакырып: «Моны хатын-кызларга калдырыгыз», – дип әйтә торган булган. Ә ни өчен ярамый дигән сорауга туа. Бу мәсьәләгә карата ислам галимнәренең фикерләре төрле. Җавапның берсе шушы – кызыл, сары төстәге кием хатын-кызларга гына хас кием булып кабул ителгән. Мондый төстәге киемне сайлаган ир-ат та хатын-кызга охшап кала.

Икенчедән, кызыл киемне мөселман булмаган халыклар кигән – аларга охшамас өчен дә бу төс тыелган.

Өченчедән, кызыл төс ерактан игътибарны тартып, чекрәеп тора, ә бу ирләргә килешмиди дип саналган. «Бу дөньяда кешенең игътибарын җәлеп итәр өчен шөһрәт киемен кигәнгә Аллаһы Тәгалә хөкем көнендә кимсетү киемен кидерер һәм аңа бөтенләй карамас», – дигән юллар бар.

Хатын-кызлар өчен тыелган төсләр бармы?

– Хатын-кызларга менә тыелган төсләр бөтенләй юк. Алар теләсә нинди төстәге киемне кияргә мөмкин. Ләкин шундый шарт бар: ул кием игътибарны артык җәлеп итәргә тиеш түгел. Киемнең мәгънәсе – хатын-кызның гаурәтен каплау, аны чит-ят күзләрдән саклау. Әгәр инде кием, киресенчә, игътибарны аның хуҗасына җәлеп иттерә башласа, бу вакытта әлеге киемнең шарты үтәлми. Шуңа күрә хатын-кызларга да төсләр сайлаганда барысын да уйлап эшләргә киңәш ителә – артык күзгә бәрелеп тормасын. Тик, тагын кабатлыйм, бу киңәш йөзеннән генә әйтелә.

Нинди төстәге кием-салымны сайлау хуплана?

– Пәйгамбәребез: «Ак төстәге киемнәр киегез. Чынлыкта алар иң яхшы киемнәрдән санала. Һәм җәсәдләрне дә акка төрегез», – ди. Аның үзенең ак төстән киенеп йөрергә яратканлыгын гел әйтәләр. Безнең җирлектә ак кием бик кер күтәрми инде. Әмма әбиләребез гомер-гомергә ак яулык ябынган.

Кара төстәге киемгә дә өстенлек бирелә. Ул ир-атлар өчен дә, хатын-кызлар өчен дә рөхсәт ителгән. Пәйгамбәребезнең дә өс киемнәре, чалмалары кара төстә дә булган. Мисал өчен, бер хәдистә пәйгамбәребез Мәккә ачылганда кара чалмадан була, диелә.

Кара төс күп халыкларда, мәсәлән, христианнарда мәрәсим – хәсрәт төсе дип санала. Ләкин ислам динендә ул кайгы-хәсрәт белән берничек тә бәйләнмәгән. Хорафатларга ышанырга кирәкми. Кеше кара кием киеп йөрсә, аннан бернинди дә зыян юк. «Ул гел карадан киенә, бигрәк куркыныч», – дию дә урынсыз. Шул ук вакытта хәсрәт килгәндә махсус кара кием кию безнең шәригатьтә хупланмый. Башка халыкларга охшамас өчен, болай киенергә кирәкми.

Яшел киемне дә Пәйгамбәребез яратып кия торган булган. «Мин Аллаһы Тәгаләнең Пәйгамбәрен (с.г.в.) күрдем, аның өстендә яшел төстәге кием иде», – дигән сүзләр бар. Ул нинди төсне яратса, безгә дә шул төсләргә өстенлек бирү хәерле санала. Пәйгамбәребез сайлаган төсләр – нейтраль төсләр: алар матур да күренә, шул ук вакытта игътибарны да артык җәлеп итми. Яшел төс тә шундыйлардан.

Аннан яшел төс – җәннәт әһелләренең киемнәре төсе дә. «Аларның өсләрендә калын һәм юка яшел ефәк киемнәрдер, алар көмеш беләзекләр белән зиннәтләнерләр, Раббылары аларга пакь, татлы эчемлекләр эчертер», диелә «әл-Инсан» сүрәсендә. Җәннәт үзенчәлекләре хакындагы түбәндәге аятьтә дә яшел төс телгә алына: «Ул бакчалардагы мөэминнәр яшел түшәкләргә вә гаҗәеп матур паласларга таянучылардыр» («әл-Рахман» сүрәсе, 76 нчы аять). Шулай итеп, яшел төс мөселманнарның аңында оҗмах матурлыгы белән тиңләнә.

Кием турында сүз кузгаткач, тагын шуны да өстәп әйтәсе килә. Ир-атларга ефәк тукымадан тегелгән киемнәрне кию шулай ук тыела. Алтыннан эшләнгән бизәнү әйберләре тагарга да ир-егетләргә рөхсәт ителми. Хатын-кызларга исә бу тыюлар кагылмый.





Без – Чаллы шәһәренең «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзалары, шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Әлмәт шәһәренең Почетлы гражданины Клара Булатова яшәгән Яңа Нәдер авылына юл тоттык. Авылга килеп керүгә, машинабызны туктатып, беренче сораган кешебез үк Клара апа гаиләсенең кайда яшәвен аңлатып бирде. Гаилә утары зур, төзек; якты төсләргә буялган булуы белән ул әллә кайдан үзенә чакырып тора. Ишектән керә-керешкә безне затлы кызыл юка халатыннан Клара апа каршы алды. Сагынышканбыз: кочаклашып күрештек. Кып-кызыл чәчәк атып утырган роза гөленә күрсәтеп:
– Сезне – кадерле кунакларымны гөлемне чәчәк аттырып көттем. Иртәгә тагын берсе чәчәк ата, – дип елмая Клара апа. «Анысын каян беләсез?» – дигән сорауга да әнә ничек кенә җавап бирә: «Төштә күрдем!.. Сез аның шаһитлары булырсыз!»

УТРАУДАГЫ УТАР УРТАСЫНДА...

Без чәйләп утырабыз, ә Клара апа сөйли дә сөйли...

– Туктатмагыз мине, телем сөйли алганда сөйлим әле... Авырып та алдым... Менә бит, сезнең килүегез аягыма бастырды, – диеп, безне яратып, үзенә генә хас бер аһәң белән көлеп тә куя. Андый көлү Клара апада гына буладыр, мөгаен.

...Стенада Клара апаның ире Нәфис абый белән төшкән фотосурәте урын алган. Сурәткә игътибар итүебезне сизеп, Клара апа сүзен дәвам итә:

– Менә шушы егет ул, мин бит аны ундүрт яшемдә төшемдә күргән идем. Мин шулкадәр төшкә ышанам. Озын буйлы егет, погонында бер йолдыз. Минем өчен бер йолдыз – майор ул. Мин аңа майор дип кияүгә бардым. Ә ул микромайор – младший лейтенант булып чыкты. Аның хәрби училищеда икенче курста укып йөргән чагы иде, отпускага кайткан булган. Нәфис 1971 елның 27 декабрендә мәктәпкә килеп керде. Укучыларның көндәлекләренә, журналларга күмелеп, чирек чыгарып утырган мәлем. Ун көн дә үтмәде, 1972 елның 7 гыйнварында туй ясадык. Туйда Рәис Нәгыймов булды. Улым тугач та килде. Бүгенге көндә дүрт оныгыбыз бар: Марат, Камилә, Гайшә, Кәрим. Гомеренең соңгы көненәчә Рәиснең гаиләсе белән дуслыгыбыз дәвам итте. Менә минем язмышым шулай бу фотосурәттәге кеше белән бәйләнеп китте...

Бу фотосурәттән тыш, аш бүлмәсе диварында тагын бер рәсем эленеп тора. Монысы Клара апаның 80 яшьлек юбилеена Мактама рәссамы Рөстәм Әхмәтов бүләк иткән портрет икән. Рәсемнең миләш тәлгәшләре белән бизәлүе шагыйрәнең эчке дөньясына тәңгәл килеп тора...

...Клара апа безне йортның икенче катына чакыра. Башта беребезгә, аннан икенчебезгә карап, «Ягез әле, кызлар, түшләр – алда, туры итеп бастык, барлык җирләрне җыйдык, җыелдык», – ди. Аның сүзләрен укучылары кебек тыңлап үтибез. «Менә шулай, кызлар, һәрвакыт шулай йөрегез, – дип, кеткелдәп көлеп тә җибәрә. – Әйдәгез, киттек...»

Без Клара Булатова иҗатына багышланган музейда. Мондый хәлне

Шагыйрә безгә үз музеенда үзе экскурсия үткәрә.



Клара апаның олы оныгы Марат хатыны һәм кызы София белән Яңа Нәдердә кунакта.

әле тарих белмидер дә. Ә бар бит, бар Клара Булатова музее.

– Шушы шкафта пионер, комсомол, Ленин турында җыелган китапларым булачак, сез алып килгән кызыл галстук та шушы бүлектә урын алыр, – ди ул.

Үз куллары белән эшләгән панно янына килеп: «Бу нәрсә өчен дип уйлыйсыз?» – ди. Бизәкле панноны төбәлләбез. Уртада матур чәчәкләр тегелеп куелган. Текәлеп карасак... кесәләр икән ләбаса!

– Чәчәкләргә, ягъни кесәләргә бакыр акчалар салырга кирәк булачак, музейга керүнең төп шарты шул, – дип, серне чишә. Бакыр тиеннәр салып, музейның эченәрәк үтәбез.

– Монда минем өчен бик кадерле материаллар, – ди ул, борынгы шкаф янында тукталып. – Күрәсезме, уртада инәем – Нәфиснең әнисе сурәте. Ул минем тормышымда кумирым булды... Ә үз әнием – Хәнифә. Дүрт кыз, бер малай табып, тәрбияләп үстерә. Миңа ул елларның герой кызы Клара Цеткин исемен кушалар. Әдәбиятка килү дә әнидән башланды. Әни безне исән-сау асрау өчен көнетөне тегү тегә иде. Мин гел аның янында ярдәмче тегүче булдым. Әни мине тегәргә, бәйләргә, чигәргә һәм үзе сөйләгән бик күп шигъри һәм чәчмә әсәрләрне тыңларга да өйрәтте. Мәктәпкә йөри башлаганчы ук мин сәхнәгә менгән идем инде.

Әнисе фотосурәте янәшәсендә Габдулла Тукай, Һади Такташ, Хәсән Туфанның шигырь китаплары. Клара апа һәр җөмләсен шигырь юллары белән йомгаклап куеп, сөйли дә сөйли.

Мин Тукайны тумышымнан
беләм,
Мин Такташны янып яраттым.
Мин Туфанның үзе оныткан
Шигырьләрен ятлап тараттым.

Шунда ук Лермонтов, Пушкин фотосурәтләре. «Лермонтовның иҗатын күбрәк яратам, ул моңлырак», – ди шагыйрә.

...Клара ападан язучылар белән булган төрледән-төрле истәлекләрне тыңлау кызык.

– 1958 елда Хәсән Туфанга минем шигырьләрне бәяләргә биргән булалар. Без Гамил Афзал белән «Казан» гостиницасыннан Хәсән абыйлар яшәгән йортка юл алдык. Кунакта гел шигырьләр турында гына сөйләштек. Инде китәргә җыендык. Хәсән абый озатырга чыкты, яңгыр коеп ява. Мин алдан барам, юлдагы яңгыр суы аяк киемемнең алдыннан керә, артыннан

Ул, гомумән, **шигырь телендә** сөйләшергә ярата.





■ Әнә, шагыйрәнең рәссам Нәҗип Нәккаш ясаган туграсы... Шагыйрәнең 80 яшенә укучылар бүләк иткән чигешле сөлге... Сарманнар бүләк иткән электрон сәгать шагыйрәнең шигъри мизгелләрен саный...

чыгып китә, чыландым. Өеп куйган чәчләрем манма су икәнен күреп, Хәсән абый: «Әллә плащымны киясеңме, Клара, чыланасың бит?» – ди. «Юк, мин яңгырда йөрергә яратам», – дип җавап бирдем.

Ә Хәсән абый соңыннан Кларага шигырь юллары белән хат юллый.

Исеңдәме безнең тәүге адым,
Яңгыр ничек матур сибелде?
Хәерлегә, шуның геройлары,
Чын күңелдән иде шикелле.

Хәерлегә булсын, хәерлегә,
Синең шулай тынып калулар,
Бер сәбәпсез генә кебек итеп,
Керфегеңнән яшьләр тамулар.

Хәерлегә булсын, хәерлегә,
Хәерлегә булсын, акыллым,
Син Әлмәттән ничек
кайткан булсаң,
Мин Себердән шулай кайтырмын.

Хәсән Туфан Кларага шигъри хатлар яза. Беренче хатка «Кояш» диеп аталган шигырен салган була.

Кояш, әллә син генәме?
Кояш әллә бер генәме?
Мин дә бүген йөрәгемдә
Кояш төсен сиздем әле.

Ап-ак, ап-ак кояш төсе,
Балкып тора җанда төсе.
Ә үзе бит кояш түгел,
Ә үзе бит бары кеше.

– Икенче хатта «Әйткән идең» шигыре булды. Бүгенге көндә бик популяр җыр. Шигырьнең беренче исеме «Ул нәкъ менә синең шикелле» иде.

Шагыйрәнең архивында Туфаннан килгән 76 хат саклана. Ул аңа Тәнәкә диеп хатлар юллаган. Тәнәкә – башкортчадан төпчек кыз мәгънәсендә.

– Ул яраткан, ә мин аны аңламаганмын, – дип сөйләп китте Клара апа. – Аңламадым, нык рәнҗеттем. Гомер юлымда ике кешене бик рәнҗеттем. Берсе – Рәшит Әхмәтҗанов, икенчесе – Хәсән Туфан. Бервакыт «Казан утлары» редакциясенә килеп кердем. Бөтен өлкән язучылар утыра. Нури Арсланов керә-керешкә: «Ниләр яздың, Клара?» – дип сорап куйды.

– И, яздым шунда, пародияләр... Менә монысы Мәхмүт Хөсәеннең «Ак каеннар» шигыренә. Күтәреп тә тормый сөйләп тә бирдем:

Ак каеннар, ак каеннар,
Шаулый җилләрдә.
Бер карт шагыйрь гашыйк булган
Мин – шыр юләргә.
Ак каеннар, ак каеннар,
Исә таң җиле.
Ахмак баштан, минем арттан
Чаба карт тиле.

Хәсән абый көл төсендәге костюмнан иде, йөзе дә көл төсенә керде, кулын йөрәгенә куеп, чыгып китте.

Хәсән абыйны рәнҗетүемнең тәэсире хатларыннан сизелә иде. Чөнки ул хатларны еш язды. Ул аларны тулай торакның почта ящигына китереп сала иде. Хатлары Казанны урап-урап өч-дүрт көннән әйләнеп килә торды. Һәрбер хат биш-алты шигырьдән гыйбарәт.

Ә Рәшит Әхмәтҗанов армиядән икенче курска кайтты. Мин әнисенә 70 тиенлек яулык бүләк итеп җибәрәм. Ә ул килсә, 8 метр материя алып килә. Шул материядән әниемә күлмәк, үземә костюм-платье да тегә идем. Үзе бүләк иткән материалдан үземә дә теккәнне күргәч: «Убырлы, ник үзеңә тектең?» – дия иде. Убырлы исемен дә үзем куштым. Үз-үземә гайбәт таратырга оста идем. Минем сул кулымның икенче – атсыз бармагы зәгыйфь. Кечкенә вакытта бала караучы апа кулыма ит тоттыра да, башка эшләргә күчә. Ә миндәге ит кисәгенә песи дә кызыга – ит тоткан бармагымны да чәйни башлый. Елаган тавышка апа килә, әти больницага алып китә. Чәрдәкләнгән бармакны кисәргә, диләр, әти кистерми. Менә шулай исән кала бармак, һәм минем тарафтан «убырлы» бармакка әйләнә, – дип кеткелдәп көлеп алды Клара апа.

Озатып кайткан, ләкин мин сөйләшәсе килмәгән егетләрнең кулын да шул бармагым белән тота идем. Тегеләр тиз генә кулларын алалар. «Бу нәрсә?» – дип сорыйлар. «Убырлы» бармагым, бу әле берсе генә», – диеп, егетләрдән шулай котылу җаен таптым.

...Шагыйрә апабыз истәлекләре кызыклы да, гыйбрәтле дә.

– Минем ике байлыгым бар: беренчесе – хәтерем, әлегә ул яхшы, барысын да хәтерли; икенчесе – автографлы китапларым. Иң кадерлесе – менә монысы, – дип, кулына Хәсән Туфанның яшел тышлы шигырьләр җыентыгын алды. – Сәрия дустымның архивына ничек эләккән булгандыр, кырык елдан соң үземә кире әйләнеп кайтты...

Китапның беренче битендә яшел каләм белән язылган. Нәкъ без ишетеп белгән, «Хәсән Туфан яшел кара белән генә яза иде», дигән сүзләрнең дәлиленә тап булдык. Бу китап җырлар, шигырьләрне үз эченә алган. Татарстан китап нәшриятының матур

әдәбият редакциясендә 1958 елда басылып чыккан. Яшел кара белән Туфан язган сүзләрне укыйбыз: «Мин түгел бу, җырны мин түгел, илһамың теркәде дәфтәргә: бу синең бүләгең, бирнәңдер иленә, теленә, Тәнәкә. 29 июль 1959 ел».

Бу бүлектә шагыйрәгә култамга белән бирелгән китаплар шактый...

Бүлмәнең бер почмагында Клара апаның үз куллары белән теккән, чиккән күлмәкләре. Ул һәр күлмәгенең нинди уңайдан тегелү тарихын белә, хәтта кайда, ничек алынган материалдан булуын да ялгышмый сөйли.

– Тегү машинасы да исән, әле дә тегә, ләкин хәзер утырырга гына мөмкинлек юк, куллар гаепле, тыңламыйлар, – дип акланып, янәдән үзенең кеткелдәп көлүе белән сөендереп ала Клара апа. – Дәүләт миңа бүләкләрен җәлләмәде, ә үземнән мин бүләкне җәлләдем. Кунакка кайтканда инәйгә 7-8 сумга күлмәклек алсам, үземә 1,30 тиенгә алам. Үземә 35 сумга шәл алсам, инәйгә 120 сумлыгын ала идем. Башка туганнарыма, якыннарыма, дусларыма да шулай булды...

Музейның бу зур бүлмәсенең утларын сүндереп, икенче бүлмәгә үтәбез.

– Монысы дини бүлмә. Улым, оныклар, шөкер, диндә. Безнең яшьлек елларында динне дәүләттән аеру зур хата булды, – ди ул.

Икенче кат тәрәзәләреннән аларның гаилә биләмәсе, авылның матур манзарасы белән танышабыз, бакча артыннан агучы елга авыл читендә үк урнашкан Очлы тау күренә.

...Истәлекләр, хатирәләр аша шагыйрә тормышындагы вакыйгаларны барлыйбыз.

Клара Булатова 1936 елның 18 мартында Татар Карамалысы авылында туа. Иң дөресе – ул юлда туа. Ул турыда «Дөмәй буе» поэмасында язылган. Әнисе ачуы килгән саен: «Юньле булсаң, юлда тумас идең, Җитлекмичә туган нәрсә», – дия торган булган.

Ул беренче шигырен 7 яшендә чыгара. Бу вакытта Клара укый белсә дә, яза белми әле. 1944 елда беренче класска Сарман районы (элек Ворошилов районы) Югары Чыршылы авылындагы мәктәпкә укырга керә. Мәктәпкә кергәнче үк гарәпчә дә, латинча да, яңа әлифчә дә укый белгән, язу үрнәкләрен дә үзләштергән була. Латин шрифтына әнисе өйрәтә. Әтисе математика укытучысы була, 33 ел мәктәптә укыта, 28 ел буена мәктәп директоры булып эшли. Үзе салган, җиде ел җитәкләгән Карамалы мәктәбеннән аны «халык дошманы» дип куалар.

Клара Булатова – сугыш чоры балаларының бер вәкиле. Ләке, Сарман мәктәпләрендә белем алганнан соң, язмышын Әлмәт шәһәре белән бәйли. Көнкүреш комбинатында, мәдәният өлкәсендә эшли. Ә 1962–1965 нче елларда Колшәрип мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1969 елда 33 яшендә Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1967 елда студент чорында «Язларым алда» исемле беренче шигъри китабы дөнья күрә.

Диплом эшен бары тик шигырь белән генә язуы – университет тарихында бердәнбер очрактыр. Ул өлгереп җиткән шагыйрә булып Яңа Кәшер урта мәктәбенә укытырга кайта.

– Яңа Кәшер мәктәбе миңа өр-яңа дөнья булды. Яраттым мин аны. Миңа кадәр балаларны Гыйләҗева Фидания Шариһздан кызы укыткан. Балаларны татар теленә чын мәхәббәт белән тәрбияләгән, – дип искә ала ул.

Клара апа, юлда очраган йөк машиналарына утырып, Әлмәттән Кәшергә эшкә йөри.

– Минем алтынчы дәресем була, ә Мауа апаның – юк. Ул мин укыткан бүлмә ишеген акрын гына ачып, кулы белән ишарәләп чакыра да: «Безгә кайт, унөч тәкә салдым», – ди. «Нишләп унөч?» – дигәнгә ул: «Соң син дә киләсең бит», – ди. Автобус килгәнче педсовет үтсә, мин Әлмәткә кайтып китәм. Автобуска җитешмичә, Мауа апаларда кунып калган чакларым күп була. Ишегалларында мал-туарның исәбе-хисабы юк. Бервакыт иренми санадым: казлар, тавык-чеби, сарыклар, сыер – барлыгы 102 баш. «Мауа апа, бу малларны ашатырга ничекләр өлгерәсең? – дигән сорауга:

– Йөз дә ике генә түгел, күбрәк, ди. Шуларга өстәп, алты баланы куш, ирне, үземне дә өстә», – дип җавап кайтара. Шулкадәр күп гаилә әгъзалары янына мин дә сыенам. Гаиләдә ипине кибеттән Мауа апаның улы Рәис алып кайта иде. Ул аңа көн дә утыз ике тиен акча бирә. Ипи уналты тиен тора иде ул елларда. Бервакыт Рәис һаман кулын сузып тора икән. «Тагын ни кирәк инде?» дигән сорауга Рәис: «Клара апа килә бит», – ди икән. Егет гаиләнең ишәюен, ипинең күп тотылуын шулай аңлаткан.

...«Сәяхәтнамә» китабын кулга алып, тагын бер кызыклы вакыйганы тыңлыйбыз.

– Ул буш урында гына тумады, – ди Клара апа. – Мин сәяхәтләрдә бик күп йөрдем. Советлар Союзы вакытында мин бармаган республика калмады. Ничек йөрелде диген? Түрәләр иҗат йортына гариза биреп куялар: кайсы люкска, кайсы нәрсәгә. Алар безнең илгә түгел, чит илгә бару ягын кулайрак күрәләр, путевкалары яна, ул путевканы безгә, укытучыларга тагалар. Чөнки авыл укытучысының ике ай ялы бар. Мин рәхәтләнеп, сөенеп, шул путевканы алам да, бабайны, улымны ияртеп, китәбез диңгез буена. Алар кызыналар, суда коеналар. Кайткач малай әйтә:

– Әни, синең ялың ничек үткәнне күрсәтимме? – ди.

Фотога төшереп алып кайта бу.

– Күрсәт, мин әйтәм. Берсендә
мин йөзтүбән язып ятам. Икенчесендә чалкан ятып газеталар укыйм.
Өченчесендә чигү чигеп утырам.
Ул чорда, Сабантуйга бүләк ясап,
ел саен чигү чигә идем. Бер баруыбызда әтисенең иске чалбарыннан
Марска шортик тегеп кайттым.
Бу укытучы Клара апаның ялы
шулай үтә торган булды.
Сәяхәттән, ялдан буш кул белән
кайтмыйм, шигырьләр язып кайта
идем.

...Кунак кешенең вакыты чикле: бүгенге очрашудан рәхәт бер дулкынга күчеп, кайтыр юлга җыена башладык. Ә хушлашканда: «Мин сезне үз, якын иттем. рәхмәт килүегезгә!» – дип саубуллашты шагыйрә апабыз.

Ал чәчәкле роза гөле, очрашулар насыйп булсын дигәндәй, Клара апа кебек ихлас елмаеп калды.

Роза ХӘМИДУЛЛИНА,
Рушания ГЫЙЛӘҖЕВА.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Без яңа китапларны гел көтеп барабыз. Ләкин китапны укуы бер хәл, аның авторы белән очрашып, күзгә-күз аралашкач, әсәрнең кыйммәтен ныграк тоясың.

Әнә шундый очрашулар Калмия авылы китапханәсендә матур бер гадәткә әйләнде. 6 февраль көнне дә Калмия авыл китапханәсендә, Туган телләр һәм халыклар берлеге елы уңаеннан, Раил Гатауллин һәм балалар язучысы Йолдыз Шәрапова белән чираттагы очрашу узды. Кичәгә авылыбызның китап сөючеләре – укучылар, укытучылар, күпсанлы халык килгән иде. Шагыйрьләр булган җирдә шигырьсез була димени?! Аларның әсәрләрен үз авызларыннан ишетү, алар белән якыннан аралашу бик тәэсирле шул. «Татар – китаплы халык» дип аталган бу очрашу өч сәгатьләп барды. Халык кызыксынучан бездә: язучыларны тын да алмый тыңладылар, соңыннан исә сорауларга күмделәр.

Үз чиратыбызда без дә кунакларыбызны буш кул белән каршы алмадык: укучылар яттан шигырьләр сөйләде, җырлар җырлады. Ветераннарыбызның «Киңәш» һәм балаларыбызның «Өмет» клубы икесе берлектә «Әбиемнең сандык серләре» исемле өзек тә әзерләделәр. Сүз уңаеннан Кашбелова Гөлбостан, Гәрәева Хәния, Гәрәев Филәрид, Әхмәтшина Гөлүсә апаларга рәхмәтебезне белдерәбез. Матур һәм истә калырдай кичә булды ул. Сәлимова Вера җитәкчелегендәге «Гөсләкәй», «Шаян кызлар һәм малайлар» төркеме дә чыгыш ясады, Әюпов Данил дигән егетебез дә җырлары белән күңелләрне күтәрде. Очрашудан рухи азык алып, күңелле тәэсирләр белән таралыштык.

Балаларыбызга китапны яраттыру өчен, мондый чараларны ешрак уздырырга кирәк икән.

Энҗе ГАЛИӘХМӘТОВА.
Тукай районы, Калмия авыл китапханәсе мөдире.

Кеше кызык инде: начарны тиз күреп алсак та, яхшылыкны абайламый да калабыз. Тормышыбызда нәрсәдер җитешмәсә, зарланабыз. Уңайлы, яхшы икән, анысы үзеннән-үзе шулай булырга тиештер кебек.

Рәхмәт сүзләрен сирәк әйтәбез шул. Башкаларны гаепләп язуым түгел әле, мондый яман «чир» үземдә дә бар. Югыйсә бу хатны инде күптән язасы иде бит...

Җәйләрен үзебез кайтып йөри торган авылның урамнары берничә ел элек бик начар хәлдә иде. Яз-көз бөтенләй керерлек булмады. Җәй көне дә күккә карап, болыт килгәнен сагалап кына торабыз: яңгыр яуса, машина белән урамнан узармын димә. Өченче ел җәй көне урамыбызга ак таш түшәп, тигезләп киттеләр. Бу әле юлны рәтләүнең башы гына иде. Ак таш тотрыклы материал түгел, суда җебеп, боламыкка әверелә. Шуңа күрә аның өстеннән тагын бер кат калын итеп чуерташ түшәлергә тиеш. Ләкин ул елны урамның буеннан-буена чуерташ түшәргә мөмкинлек җитеп бетмәде, ахрысы, эш яртылаш башкарылган килеш калды. Хәтта шул рәвешендә дә инде урамнан йөрүләре күпкә уңайланды. Күңел дә тынычланды: ярты юлда калдырмаслар, быел булмаса, киләсе елга төгәлләрләр, дидек.

Узган җәйнең бик матур иртәсендә тар гына урамыбызны зур КАМАЗлар, тракторлар гөрелтесе күмде. Күңелле ыгы-зыгы башланды. КАМАЗлар йомры-йомры чуерташларны урамга бушаталар да, авыр тракторлар шуны юлга тигезләп җәяләр, тыгызлыйлар. Бер-ике сәгать эчендә әнә шулай юллы булдык та куйдык. Ничә еллар көткән шатлык иде бу! Хәзер рәхәтләнеп капка төбебезгә кадәр машина белән үтә алабыз. Яңгыр да, кар да куркытмый.

Безнең авыл зур түгел. Күпчелек халкы пенсионерлар. Үзара салым акчалары да иркенләп ниндидер зур эшләр башларга җитәрлек түгелдер. Ләкин шулай булса да, авылда күркәм эшләр гел эшләнеп тора. Әйтәм бит, күп вакытта без аларны күрми үтеп кенә китәбез. Әле менә бу җәйдә авылдашлар муллабыз Радик Кәримов җитәкчелегендә борынгы «Сабыр» чишмәсен чистартып, елга аша басма салып куйганнар. Хикмәтле чишмә ул. Суы тәмле, йомшак. Тау

Фото: Анна Арламова



астындагы колач җитмәс тал төбеннән ничәнче гасыр чурлап агуында...

Соңгы кайтуыбызда тагын бер күңелле яңалык көткән булып чыкты. Яңалык дип әйтүе дөрес тә түгелдер, без үскәндә ул гадәти хәл иде. Авыл урамнарында утлар балкуын әйтәм. Аннары баганаларда утлар сирәгәйде. Хәер, утсыз баганалар гына түгел, тәрәзәсендә нуры сүнгән йортлар да шактый инде авылымда. Безнең йорт каршындагы баганада утның соңгы тапкыр кайчан кабынганын да хәтерләми идем. Ә бу кайтуыбызда ишегалды яп-якты нурга күмелгән. Ак карданмы бу яктылык, күктәге айданмы – бер мәл аңламый да тордым. Аннары гына күзем төште – багана башында «Ильич уты» балкый лабаса! (Без кечкенә вакытта электр лампаларын «Ильич уты», диләр иде.) И-и күңел булды да соң! Утлы авыл – нурлы авыл ул. Димәк, монда тормыш бар, димәк, авыл яши!

Быелгы кыш кар-буранга юмарт килде. Без үскәндә кышлар шулай салкын һәм карлы була торган иде бит. Язын дым күп булып, үсемлекләр өчен уңай булачагын уйлап куандырса да, карның күплеге Авыл советлары өчен чын сынау булгандыр дип уйлыйм. Бураннардан соң авыл урамнарын, юлларны кардан чистартып өлгерт кенә! Рәхмәт Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Энҗе ханым Минҗановага – кайчан гына кайтсак та, урамнар кардан чистартылган, юллар эттерелгән. Бу хезмәтне күрми һәм бәяләми калу мөмкин түгел. Энҗе ханымның әлеге вазыйфага керешүенә яңарак кына. Шул кыска вакыт эчендә дә авыл халкы өчен кирәкле никадәр эш башкарылды.

Шулай ук авылдашларыма да рәхмәтем чиксез. Кайдадыр көн саен берәр авылның соңгы уты сүнгәндә, минем туган авылым яши. Кайтып сиенер авылы булганнар, ни әйтсәң дә, барыбер бәхетлеләр.

Лилия ГӘРӘЕВА.
Арча районы, Кышкар авылы.

Безнең әбиләребез, әниләребез борын-борыннан матур киенеп йөргән. Алар яулыкны да үзләренчә бәйләгән, һәм бу аларга бик килешеп торган. Кызганыч, әбиләребезнең киенү рәвешен хәзер онытып барабыз.

Иртән иртүк, эшкә киткәнче дип, базарга барып кайтырга булдым. Башыма яулыкны кыеклап кына бәйләдем дә, чыгып китәр алдыннан көзгегә күз салдым. Яулыкны болай бәйләү миңа бер дә килешми икән. Алай да бәйләп карадым, болай да...

Тукта әле, безнең әбиләр яулыкны бөтен килеш бәйли иде бит, дип, әниемнең мережкалы ак яулыгын таратып бәйләгән идем – бөтенләй башка кешегә әйләндем дә куйдым. Яшәреп, яшь киленгә охшап калдым. Өстемә әниемә дип алган озын җиңле, матур тегелешле зәңгәр күлмәкне киеп, әни каршына килеп бастым. Болай киенүемне ул да бик ятатты. «Яшь чагыма охшап калгансың», – дип сөенде. Теләкләр теләп, озатып калды.

Урамга чыктым. Юлда очраган кешеләр, исәнләшеп, артымнан борылып карап калалар. Туктап сөйләшергә вакыт юк, ашыгам. Базарда чират – балык китергәннәр. Мин дә чират койрыгына барып бастым. Сатучы ханым белән якыннан танышлыгыбыз юк, шулай да исәнләшеп йөрибез. Күзе белән генә ымлап, мине янына чакыра, янәсе, кил, чиратсыз гына биреп җибәрәм. Кыймадым, бөтен кеше дә минем кебек эшкә ашыга, кеше рәнҗетеп, чиратсыз алган ризыкның бәрәкәте булмас кебек тоелды. Башына ак яулык япкан кеше хәрамгә кушылмас!

Шунда көтелмәгән күңелсез хәл булды: бер хатын яныма килде дә, әҗәтеңне кайчан кайтарасың инде, дип, чираттан тартып чыгарды. Аптырап киттем. «Син мине беләсеңмени? Исемем ничек соң алайса?» – дип сорыйм. «Үзеңне беләм, исемеңне белмим. Син яшелчә базасында эшлисең», – ди. «Мин Нәфига исемле булам, Оргсинтезда аппаратчы булып эшлим. Сез мине кем беләндер бутадыгыз, халык алдында нахак гаеп тагып, мәсхәрә иттегез», – дип җавап бирдем. Ә бит ул көн минем туган көнем – 40 яшем тулган көн иде. Хәзер миңа 84 яшь инде. Еллар узса да, нахак гаеп һаман онытылмый.

Бая әнием турында телгә алгач, аның турында да язып китәсем килә. Аның да язмышы бик гыйбрәтле. Әнинең әнисе Хөсниҗамал әбием Молотов өлкәсендәге улында яшәде. Әни беркөнне аны төшендә күреп уянды да, хәлен белеп кайтырга булдык. Без барып җиткәндә әби вафат иде инде. Чардуганына тотынып, күңелебездән генә әби белән сөйләшеп йөрдек. Икенче юлы барганда ул зиратны сүткәннәр иде. Әбиемнең кабере өстеннән трамвайлар йөргәнен күреп, җаныбыз бик әрнеде. Әйткән булсалар, барып, җәсәден казып алып кайта идек бит.

Әни – йөрәге тибүдән туктап та, могҗиза белән исән калган кеше ул. Әле дә хәтерлим: май ае иде. Берике көннән ураза башланырга тиеш. Абыйның хәлен белергә киткән җирдән, күчтәнәчләр белән кайтты да әни, шуларны урнаштырып йөргәндә кинәт йөрәген тотып кычкырып җибәрде. Сеңлемнең кочагына авып кына төшкән әнигә тизрәк табиб чакырдык. Ашыгыч ярдәм табиблары килеп, пульсы юк, үлгән, диделәр. Поликлиникага справкага килергә куштылар. «Аллаһы Тәгаләм, зинһар әнине алма, исән калдыр. Әтисез дә үстек, әнисез дә ятим итмә», – дип догалар кылып, елап утырганда әниебез кабат күзен ачты. Аннары да бераз яшәде әле. Бу хәлгә ышануы да кыен, ләкин бу чын могҗиза иде.

Нәфига КАСЫЙМОВА.
Казан шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан,
Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru



Чынлап та нәрсә җитми аңа? Бу тормыштан нәрсә көтә ул? Максатлары нинди? Җәмгыять йөкләгән вазыйфалар – ир хатыны, балалар анасы булу гына канәгатьләндерәме бүгенге хатын-кызны? Сораулар күп, ә җавапны һәркемгә үзенә эзлисе. «Үз-үзеңне табарга беркайчан да соң түгел», – ди ул. Әңгәмәдәшем – продюсер, режиссер, автор-башкаручы Рузилә САФИНАның бу сүзләре кемнеңдер күңелендә өмет уятмый калмас. Ачыктан-ачык сөйләшәбез.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Фото: гаилә архивыннан

ХАТЫН-КЫЗГА НИ ҖИТМИ?

– Габделфәт белән безнең өйләнешү бик тиз булды. Минем үзебездә – Балык Бистәсе районы мәдәният сараенда өлкән методист булып эшләп йөргән вакытым. Эшемне яратам! Түгәрәкләр алып барам. Халык театрында төп рольләрне уйныйм. Әле күптән түгел генә актер Василий Лановой вафат булды бит. Бу хәбәрне ишеткәч искә төшереп йөрдем: театрыбыз белән ул чакта Мәскәүдә Бөтенроссия фестивалендә катнаштык. «Сүнгән йолдызлар»да Сәрвәрне уйнадым. «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә җиңдем, һәм миңа бүләкне нәкъ менә Лановой тапшырды. «Татарча бер сүз белмәсәм дә, хәрәкәтеңнән, йөзеңнән, ымнардан барысын да аңладым, татарочка», – дигән иде ул миңа... Кечкенәдән артист булырга, театрда уйнарга хыялланган кешегә канат куя торган сүзләр!

Ә беркөнне безгә «Сорнай» ансамбле килде. Концертлары матур узды – рәхәтләнеп карадык. Татар чараларында рәхмәтне гел мин әйтә идем: ул көнне дә ахырда сәхнәгә күтәрелдем. Өстемдә үзем теккән бик килешле сары күлмәк иде. «Син алда, тамашачыга якынрак басып сөйләдең, ә без арттарак тезелеп тордык. Йөзеңне күрмәдем диярлек, әмма тавышыңа шунда ук гашыйк булдым. Төнлә эзләп тә йөрдем, тапмадым», – диде ул соңыннан. Концертта Габделфәт тә чыгыш ясады, тик мин аңа игътибар итмәдем – нәрсә җырлаганын да хәтерләмим...

Ике көннән соң кинәт ишектән килеп керде ул. Ниндидер концерт башланырга тора иде. «Бәтәч! – дим. Безнең якта шулай сөйләшәләр. – Сез китмәдегезмени?» Ансамбльләре ай буе Балык Бистәсе авылларында концерт куйды, инде гастрольләре башка районда дәвам итәсе иде. «Ринат абый Гыйләҗев газетада безнең хакта чыккан материалны алырга җибәрде», – ди. «Әйдәгез алайса, бирәм», – дим. Тик кабинетка керүгә: «Газетага дип килмәдем», – дип, ул мине... кочаклап алды. Бөтен тәнем буйлап бер дулкын, тетрәнү узды... Без ул көнне Кама буенда бик озак йөрдек. Габделфәт гел елмая, сөйләштерә, сораулар бирә... Мине шундый аңлый кебек. Үземне аңлаган кеше очрасын иде дип күпме хыялландым!.. Ялга җыена идем. «Нәрсә эшләмәкче буласың?» – ди. «Ике атнадан абыем өйләнә. Бәлки әле үзем дә кияүгә чыгармын», – дим. «Ә кемгә чыгасың?» – дип сорады. «Анысын белмим әле», – дим. Уйнап-шаярып сөйләшеп барабыз бит. Чынлыкта бер елга якын йөргән егетем бар иде һәм өйләнешү турында инде сүз чыккан иде... Өч көннән соң Габделфәт тагын кайтып җитте. «Безнекеләр туйга әзерләнеп калды. Әйдә, синең кулны сорарга барам», – ди. Аптырап калдым. Монысы инде мәзәк түгел иде. Әмма аның белән очрашу минем дә күңелне урыныннан кузгаткан иде шул... «Алар әле синең хакта белмиләр дә», – дигәч, ул мине Казанга – абыйлары белән таныштырырга алып китте. Икенче көнне Арчага – әниләренә кайтырга тиеш идек. Вокзалга ике сәгатькә соңарып килдем. Мәскәүдән алып кайткан босоножкамны ремонтлатып йөрдем. Җайлы да, матур да иде ул – нәкъ менә шуңардан кайтасы килде аларга. «Китсә – китә инде», – дип уйлыйм. Көткән! Бу ике сәгать көтүнең Габделфәт өчен ни икәнен, аның холкын мин ул чакта белмим бит әле...

Күңел тулы икеләнүләр белән кайттым юлда. Әтисе белән әнисе капка төбендә утырып торалар иде. Өйгә уздык. Әнисе миңа ап-ак, чип-чиста йон носки алып килеп бирде кияргә. Алардагы чисталык, тәртип! Берсе кигән галошны икенчесе кими. Әтигә хәзер 99 яшь: мин кияүгә чыкканда өйдә кайчы кайда булса, бүген дә шул урында тора. Кайсы гына әйберне кулыңа алсаң да, нәкъ шул урынга кире куясы.. Әти-әнисе янына кайткач кына, Габделфәтнең күп сөйләшми торган кеше икәнен аңладым. Беренче очрашуыбызда бөтенләй башка иде бит... Аңа гел тиз кирәк: нәрсәнедер хәл иттеме, бу эш шунда ук эшләнергә тиеш. Монда да шулай булды...

«Әйдә, башта без өйләнешик, аннары икенче атнада абыең өйләнер», – ди. Мин, әлбәттә, ризалашмадым. Әмма шул атнада ук алар мине сорарга да килделәр. Габделфәт абыйның туена да кайтты. Алай гына да түгел, абыйның классташы баш тарткач, кияү ягыннан шаһит та булды әле. Бер күренеш гел истә. Өйдә туй бара, ә мин урамда савыт-саба юам. Авылда артымнан йөри торган бер егет бар иде. Ул минем яныма баскан да сөйләшеп тора. «Аңа кияүгә чыксаң, бәхетле булмыйсың», – ди. Кинодагы кебек... «Үзеңә тиңне табарсың әле, минем күңелем авылда түгел», – дип әйтә идем аңа. Гел кемнедер көттем... Өйнең бөтен тәрәзәләре ачык – табында сөйләшкән сүзләр, җырлар ишетелеп тора. Шул вакыт Габделфәт җырлый башлады. Юасы савыт-сабамны, теге егетне калдырып, өйгә йөгердем. Аның җырлавын беренче тапкыр чынлап торып шунда ишеттем... Казан төзелеш институтын тәмамлавын, җырчы түгеллеген белә идем. Җырчы булса, уйлаган булыр идем әле. Ул вакытта артистларга караш башка иде бит, әнинең дә әйткән сүзе бар иде. «Алар гаилә кешесе түгел, кәеф-сафа корырга ярата, ерак тор, кызым», – дия иде ул. Эшемдә җырчылар белән дә шактый аралашырга туры килгәнен белгәнгә әйтә иде. Аның бу сүзләре күңелгә тирән кереп утырган...

Кайсы вакытта уйлыйм, кем соң мин, дим. Мәдәният хезмәткәреме? Алай дисәң, 20 ел газета эше эчендә кайныйм...

Абый август ахырында өйләнде, без сентябрь башында кавыштык. «Кыз озатырга килегез», – дип, эштәгеләрне шаккаттырдым. Әни – ялгыз хатын: рәттән ике туйны ничекләр үткәрде икән, хәзер дә уйлыйм ул турыда. Кибетләрдә берни юк чак бит әле. Үзем дә хәзер әни яшендә: мондый берәр мәҗлес уздырасы булса, борчыла башлыйсың...

Без өйләнешкәндә, сәхнәдә эшләү теләге Габделфәткә караганда миндә күбрәк иде. Театрда уйныйсым килә! Инде бу хыял шундый якын да кебек... Казан мәдәният институтын мин читтән торып тәмамладым. Ректорыбыз Рәис Кыямович Беляев татарларны бик ярата, чыгышларыбызны карап бара. Институт коридорында очраса, исәнләшә, хәлләрне белешә. Бик кече күңелле кеше иде... «Театрда уйнарга теләсәң әйт, мин сине Сәлимҗановка урнаштырам», – дигәне булды. Өйләнешеп бергә яши башлагач, мин бу хакта Габделфәткә дә сөйләдем. Икәү Беляев янына киттек... «Театр гастрольдән кайтуга яныма килсен», – дигән Марсель Хәкимович. Ә мин балага уздым... «Бу килеш ничек барам инде хәзер?» – дип уйладым. Резинотехник эшләнмәләр заводы каршындагы «Техниклар йорты»на эшкә урнаштым.

Әдилә тугач, Габделфәткә «Горгаз» дүрт бүлмәле кооператив фатир бирде. Ә безнең бер тиен акчабыз юк! Беренче взносны – 16 меңне әти-әниләрдән алып тордык. 1991 ел бу. «Челнок»лар заманы. Эштәге кассир кыз: «Хәзер сезгә акча бик кирәк бит, әйдә, безнең белән Польшага барасыңмы?» – дип чакырды. Тәвәккәлләдем... Әдиләгә яшь тә ике айлар тирәсе. Аны Арчага, әниләргә кайтарып куябыз да, бер атна Казан буйлап кибетләрдән товар җыям. Бару-кайтулар тагын бер атнага җыела. Кайткач, атна буе сатам... Өч ел буе Польшага, Венгриягә, Төркиягә йөрдем. Фатирыбыз төзелеп беткәндә бурычлар калмаган иде инде.

Ордер алып кайткан көнне үк Габделфәт эштән китте. Икенче көнне үк филармониягә, Илһам Шакиров янына барды. «Ярты сәгать тыңлады да, бар кер, гариза яз, дип әйтте», – диде. Музыкаль белеме дә юк килеш бит... Бер ел Рабига апа Сибгатуллина бригадасында йөрде – бөтен Татарстанны әйләнеп чыктылар. Аннан үз төркемен төзергә уйлады. Габделфәт шундый, курыкмый – максат куя да шуңа бара. Ә мин... Минем андый максатым юк. Дөресрәге, бар ул, тик шундый ерракта... Мин аңа бик әкрен барам. Белмим, хатын-кызның, бәлки, шулай булырга тиештер. Безнең өчен гаилә – ир, балалар беренче урында бит.

Габделфәт концертлар куеп, акча эшли башлагач, икенче балабызны табарга уйладык. Улыбыз Зөлфәтне алып кайттык. Ә Габделфәтнең бер концерт артыннан икенчесе, өченчесе... Администраторлары булды, билгеле. Әмма мин аңа кулайрак идем. Беренчедән, мине бернәрсәгә дә өйрәтәсе юк. Икенчедән, бер түбә астында яшәгәч, аңа нәрсә кирәген, ничек әйбәтрәк булганны яхшырак аңлыйм. Инде бу вакыт «Ак күлмәгем» җыры бар, заллар инде тул-тулы... Мин режиссерлык бүлеген тәмамладым – Габделфәт сүземә барыбер колак сала, киңәшләшә иде. Җырларын иң элек син тыңлыйсың: ошыймы, юкмы – син әйтәсең. Кием сайлашасың, образын тудырасың... Репертуарында мин тапкан җырлар да бар. «Соңгы кыңгырау», мәсәлән. Бу көйне ишеткәч, Соңгы кыңгырау бәйрәме, укытучы-укучы образлары күз алдыма килде. Сүзләрен язарга Вазыйх Фатыйховка бирдек. Өч көн язды – өч көн телефоннан аралаштык.

Кайчак Габделфәт кырысрак та була иде. Тик ул чакта аның андый сүзләрен ишетмәгәнмен. Ул сәхнәдә – бу иң мөһиме! Минем дә иҗатым, күңелем дә бар бит әле дип уйланылмаган. Үземне ир хатыны итеп кенә күрдем.

«Әйдә, игълан итәм, сәхнәгә чыгасыңмы?» – дигәне булды аның. Бу хакта районлашларым да гел исенә төшереп тора иде. Бер тапкыр хәтта чыгып та карадым. 1996 нчы еллар бу. Махсус күлмәкләр тектердем. Алып баручы егетләре ул чакта икәү иде аның – Данил Гыйниятов һәм Азат Низамиев. Мин өченчесе булырга тиеш идем. Автобус юлда бик озак барды, Баулыга соң барып җиттек. Халык инде безне көтеп тора, микрофон көйләргә дә җай булмады. Габделфәт үзенекен генә карады да, концертны башладык. Тамаша беткәч, ул миңа: «Башка чыкмыйсың», – диде. Каршы килеп маташмадым...

Габделфәтнең 50 яшьлек юбилеен «Корстон»да үткәрдек. Мин беренче тапкыр шунда үземә читтән карадым. Концерт-тамаша өстәлләр артында үтте, 470 кешегә билет сатылды. Барысын да оештырдым... Үзем сүз әйтергә чынлап торып әзерләнә дә алмадым, әмма ихластан сөйләдем... Кунакларның берсе – Уфадан килгән зур эшмәкәр соңыннан, үзебез генә калгач: «Беләсеңме, Габделфәт, мин бүген нәрсә аңладым. Син сәхнәдә булсын өчен Рузилә үз иҗатыннан баш тарткан икән бит», – диде. Чит кеше әйткән колакка керә бит ул. Мине бу сүз сискәндерде бугай...

Юбилейда: «Бүген шушы сәхнәдә, шушы кадәр кунаклар алдында синең янәшәңдә басып торам икән, димәк, яшьлектәге хыялым тормышка ашкан. Ирем – башкалар хөрмәт итә торган кеше булсын иде, шул чакта мине дә хөрмәт итәрләр дип хыялландым», – дидем. Әтисез үскәнгә, авырлыклар күргәнгә шулай теләгәнмендер, күрәсең. Әти 35 яшьтә үк вафат булды. Миңа – 5, абыйга – 7, энемә 1,5 яшь кенә иде... Беренче булам, танылам дигән уй булмады миндә.

Ә шигырьләрне биш-алты ел элек яздыра башлаган идем инде. 50 яшем тулганда «Ел хатын-кызы. Ел ираты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә катнаштым. Шунда портфолио өчен бер шигырь яздырып карадым. Гөлнур Әхмәдуллинаның туган якка багышланган шигырен сайладым. Авторы күптән таныш кеше. Гөлнурның ире безнең авылда партком секретаре булып эшләде, ул үзе мәктәптә укытты. Кама буйлары турында яза. Миңа шундый якын җирләр! Укыйм да, яшьлегемә кай-

там... Шигырьне яздыруга Гөлнурның үзенә дә җибәрдем. «Бик матур килеп чыккан, дикцияң дә шәп!» – дип җавап бирде ул. Бу да дәртләндерде. Карале, минем бит әле тавышым бетмәгән икән, дим. Эштә кечкенә генә студия бар безнең. Азрак вакыт булганда, керәм дә тагын шигырьләр яздырам. Шактый җыелды болар. Габделфәткә дә бик тыңлатып карыйсым килә. Берсендә хәтта каршысына ноутбукны китереп куйдым. Барыбер тыңламады...

Һәр гаиләдә дә аңлашылмаучанлыклар чыгып тора. Шундый чагыбыз иде. Габделфәт бер атнага ял итәргә китеп барды. Салкынрак саубуллаштык. Эч поша... Мине шуның алдыннан гына Казанда чыга торган «Бизнес-журнал» үткәргән «Женщина года – Топ 50» конкурсында катнашырга чакырдылар. Баш тарткан идем. Үзем генә калгач, шуларга шалтыраттым. Инде ике атна әзерләнәләр икән. Мин дә барып кушылдым. Подиумда йөрергә өйрәнәбез, кием сайларга... Габделфәт кайтканчы, бер атна эчендә шактый үзгәрдем – үземне хатын-кыз итеп тоя башладым. Көн саен яңа кием киясем килә. Югыйсә бар бит алар, элгечтә эленеп торалар. Чаллыга бер атнага гастрольгә баргач: «Бер кием белән килдегез, шуның белән киттегез», – дигәннәре булды. Чемодан тутырып кием алып барып бит. Үземне карарга гел вакыт җитмәде... Бу бәйгедә «Ел табышы» номинациясендә җиңү яуладым. Залда Габделфәт, балалар, бөтен хезмәттәшләрем утырды. Әлеге проект белән берничә тапкыр Мәскәүгә дә бардым, үземнең җырларым белән чыгыш ясадым, радиолардан сөйләдем.

«Ел хатын-кызы» бәйгесендә катнашу җаныма бер рәхәтлек бирде. Тик шул ук вакытта: «Әле – аңа, әле моңа тотынам икән, димәк, һаман да үз-үземне тапмаган, үз мөмкинлекләремне файдаланмаган булып чыгам», – дип уйлана башладым. Бу хакта Габделфәткә дә әйттем. «Шулкадәр эшләп, ике бала үстереп ничек болай дия аласың? Сәхнәгә чыккан никадәр яшьләргә үз образларын табарга гына булыштың?!» – диде ул аптырап. Ул хаклы, мондый очраклар байтак җыелды. Бүген илкүләм танылган җырчыбыз Динә Гарипова – шуларның берсе. Безгә килгәндә бала гына иде бит әле, аны да сәхнәдә җырларга гына түгел, яшәргә дә өйрәттем...

Мин шушы конкурсларда катнашканнан соң, «Алтын тавышка – алтын «Акчарлак» җыр бәйгесе оештыра башладык. Хыялланып та сәхнәгә күтәрелә алмаучылар бик күп бит алар. Кемнеңдер әти-әнисе риза булмаган, кемнедер ире тыйган... Беренче елны Яшел Үзән районы Бишнә авылыннан Фирдәвес Шиһапова җиңде. Китапханәче булып эшли ул. Габделфәт бер ел буе аны үзенең концертларында йөртте. Киткәндә елады Фирдәвес: «Их, сәхнәгә элегрәк чыккан булсам, күптән танылыр идем!» – диде.

Бу миңа да яңа адымга этәргеч булды. «Рузилә, ә нигә син шигырьләреңне видеога төшермисең?» – дидем берсендә үз-үземә. Тотынып эшләп карадым... «Ерактагы якын кешем» (Гөлнур Әхмәдуллина) шигыренә төшерелгән ул клипны «Мәйдан» каналы әйләндерә башлады. Габделфәткә әле берсе, әле икенчесе килеп: «Рузиләне тыңладык, бик матур укый», – дип әйттеләр. Ниһаять ул да ишетте... Моңарчы анның мине сәхнәдә күргәне юк иде бит. Группасына администратор буларак кына килеп кердем.

Хәзер күбрәк үз иҗатым белән шөгыльләнәсе килә. Элеккеге Рузиләгә кайтасым... Инде үзем иҗат иткән җиде-сигез җырым бар. Өчесен Габделфәт җырлый. «Гафу итәм»не: «Яңа җыр җибәрделәр, тыңлап карыйсыңмы?» – дип бирдем. Ошатты, аранжировка ясатты – шуннан соң гына серне ачтым.

Габделфәткә 55 яшь тулу уңаеннан оештырылган концертларның беренчесе Питрәчтә узды. Сәхнәгә үзем иҗат иткән җыр белән мин дә чыктым. Ул көнне күңелемнең тынычлыгын күрсәгез?! Җан шулай тыныч та була ала икән дип шаккаттым. Гел бәргәләнә идем бит: әле монысы, әле тегесе җитми... Кеше үз-үзен табалмаганда да шулай күп эшли башлый икән. Газета ачтык – аңа тотындым. Кыйбласын Габделфәт билгеләсә дә, оештыру эшләре минем өстә булды. Бер газета гына түгел, әллә ничә реклама журналы да чыгардык бит. Аларга күпме энергиям китте! Ә анның барысын иҗатка салган булсам?! Ничә еллар үз-үземне эзләгәнмен! «Башка сәхнәгә чыкмыйсың», дигән сүзне ишеткәч, үземә үзем ышанмау булдымы икән соң бу?! Юк, боларны үпкәләп сөйләмим. Димәк, шушы юлны узарга тиеш булганмын.

Күрәм, соңгы вакытларда Габделфәт тә үзгәрә. Янындагы кешең үзгәрсен өчен, иң элек үзең үзгәрү кирәк. Барысы да, димәк, хатын-кызның үзеннән тора... Яраткан эшең белән шөгыльләнгәндә арытмый да икән. «Элегрәк нигә сәхнәгә чыкмадыгыз?» – дип язучылар бар. Габделфәт аларның барысын да укып бара һәм: «Сиңа әле хәзер дә соң түгел», – ди...

Һәркайсыбызның да гомере бер генә. Элек өйдә утыру, йорт карау, балалар тәрбияләү белән генә дә канәгатьләнүчеләр булган. Бүген дә бар андыйлар, әлбәттә. Әмма хәзер заман башка. Күпләр үз җаны теләгән эшне табарга омтыла. Моның өчен хатын-кызны гаепләргә кирәкми. Танышларым арасында, байлыкка күмелеп яшәсәләр дә, каядыр эшкә урнашырга теләгән хатын-кызлар бар. «Бөтен нәрсәң бар! Сиңа нәрсә җитми?!» – дип аптырый ирләре. «Туйдым идән чүпрәге булып яшәүдән! Өйдә утырган хатын-кызның дәрәҗәсе юк аның. Хәтта ире алдында да. Аннан эшләмәгән хатын-кыз иртәрәк тә картая. Берниндди кыйммәтле кремнар да коткармый. Башкалар кебек эшләп кайту җаныңа көч өсти», – ди берсе. Әйе, акча, байлык кына кешегә бәхет китерми...

Планнарым турында сөйләүдән куркам. Үземне Габделфәт группасында күрмәвем турында гына әйтә алам. Ул да мине сәхнәдә үз янәшәсендә күрми. Анның концертлары бер спектакль кебек бара, һәм андагы образларны инде үзгәртергә кирәкми. Мин алар арасына килеп керсәм, инде хәзер хатыны буларак кына килеп керәм. Ә безнең тамашачы моны яратмый.



■ Рузилә Сафина башкаруында «Миләүшә көндәлегеннән» (Ә. Атнабаев) шигырен тыңлау өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

– Пандемия башланды да, без эшкә күчендек. Әйе, әйе, Лесхоз картлар-инвалидлар йортыннан бөтенләй кайтмадык та... Мин генә түгел, барыбыз да. Өлкән пешекче Рәмзия Әүхәдиева һәм Нәзирә Галиева белән бергә эшләдек. Көн саен 80 гә якын кешене ашатырга-эчертергә кирәк иде. Монысы әллә ни авырлык тудырмады, иялəшкән көндәлек эшебез бит. Күбрәк өй өчен, балалар өчен борчылдым. Иң кечкенәсе – 7 яшьлеге минем өйдә булмавымны авыр кичерде. Бер ай бит! Болай озак вакыт күрешмичә торганыбыз юк иде әле. «Әнием кайтмый», – дип елаштырып та алган, баштарак төнлә йокламаган да. Әни малае шул анысы... Телефоннан сөйләшеп торсак та, барыбер юксынган. Ә олылары кайчакта эш урыныма килгәләделәр: еректан, тимер койма аша гына аралаша идек. Күземә күренгәч, җиңел булып кала... Ул чакта ирем Радикның вакытлыча өйдә булуы ярады. Ул минем хезмәтемнең җаваплылыгын аңлый, бик тә гаилә җанлы...





«БИШ БАЛАМ – БИШ БӘХЕТЕМ»

Гүзәлиягә карыйсың да, аның бар җиһанга җитәрлек күңел җылысына сокланасың. Дөньяга гашыйк ул, кечкенә генә шатлыкны да зур итеп кабул итеп, һәр тыныч, имин туган таңга сөенеп яши белә. Юкка гына Сабабаш егете Радик Габдрахманов туган авылына кунакка килгән бу сөйкемле, йөзеннән нур чәчеп торган Олы Кибәче кызын тизрәк үзенә пар итәргә ашыкмагандыр. Нибары икеөч тапкыр гына очраша егет белән кыз: бер-беренә тиң икәнлекләрен аңларга шул да җитә... Бүген инде бергә яши башлауларына 21 ел. Аларның җылы канаты астында биш бала үсә. Бер кочак! Балалары хакында сөйләгәндә Гүзәлиянең күзләре очкынланып яна, тавышына җылы иңә:

– Мин бик бай кеше. Аллаһының олы бүләге – биш балам – биш бәхетем, тормышымның ныклы терәге – ышанычлы ирем бар. Шушы байлыгыма куанып бетә алмыйм... Кичләрен, балаларым тезелешеп йокларга яткач, һәрберсен яратып, сөеп, башларыннан сыйпап йөрим. Безгә аларны тигезлектә үстерергә язсын...

Әти-әнисе аның үзен бер эштән дә курыкмаска өйрәткән, хезмәтең булса – дәүләтең була дип тәрбияләгән. Хәзер инде үзе бу алтын кагыйдәне балаларына сеңдерә. Гомумән, эшне ир-атныкына, хатын-кызныкына бүлү юк Габдрахмановларда.

– Өйләнешкәч, үз көчебез белән өй салырга керештек. Кайнанам да, кайнатам да мәрхүмнәр иде инде – булышыр кешебез юк. Радик кирпечен салды, мин измә ясап, кирпеч биреп тордым. Тырыштык, дәүләттән ярдәм көтмәдек, 2012 елда яңа өйгә күчтек. Көч түкмичә генә бернәрсәгә дә ирешеп булмый...

Балалары да әти-әнисе үрнәгендә, яшьтән чыныгып, кул арасына кереп үсә аларның. Өч өлкән балалары – Инсаф, Зилә, Илфар – Саба аграр көллиятендә белем ала. Ильяс Сабабаш мәктәбендә 7 нче сыйныфта укый. Төпчекләре Илфирга 7 яшь.

Габдрахмановларны Сабабашта спортчылар гаиләсе буларак беләләр.

Хатын-кызның иң зур бәхете – әни булу-да. «Ана даны» медале иясе Гүзәлия шулай ди.

Егетләрнең дүртесе дә кечкенәдән көрәш белән мавыга, кулларыннан сөлге төшми. Мавыгу дип әйтү дөрес тә булмас, егетләрнең спорт дөньясында инде лаеклы урыннары бар. Инсафлары Татарстан, Россия, Дөнья беренчелеге ярышлары җиңүчесе. 2019 елда билбау көрәше буенча 2001–2002 елгы яшүсмерләр арасында узган дөнья беренчелегендә 55 кг авырлык категориясендә I урынны алып, Дөнья чемпионы булды. 35 илдән 200 дән артык көрәшче катнашкан бәйгедә чемпион булуга ирешү өчен күпме физик әзерлек, ихтыяр көче, тырышлык соралганын чамалау авыр түгел... Россиянең җыелма командасы составында спорт мастеры дигән югары дәрәҗәне йөртүче Инсаф быел, Саба аграр көллиятен тәмамлап, механик белгечлеге алачак. Абыйлары үрнәгендә энеләре дә бер-бер артлы спортта үрләр яулый тора. Әлбәттә, әни кеше, бер яктан, улларының спорт белән дуслыгына шат булса да, икенче яктан, күңеле тыныч түгел: җәрәхәт, имгәнүләр куркыта. «Ярышка дип чыгып китсәләр, үземә урын тапмыйм... Ана йөрәге гел борчылуда, гел начарны уйлауда... Спорт бит гел җиңүләрдән генә тормый, җиңелүләр дә бар. Инсафыбыз ярышларда һәр әйләнеш саен хәбәр биреп, бөтен яңалыкны җиткереп тора. Элемтәгә чыкмый, югала икән, димәк, аңа уңыш елмаймаган дигән сүз... Шуннан аңлыйбыз. Андый очраклар сирәк була анысы», – ди ул.

Бердәнбер кызлары – Саба аграр көллиятендә бухгалтер-икътисадчы белгечлеге үзләштерүче Зилә дә өстәл теннисы буенча физик мөмкинлекләре чикле спортчылар арасында узучы бәйгеләрдә призлы урыннар яулый. Инде спорт мастерлыгына кандидат нормасын үтәгән.

– Безнең өйдә медальдән дә күп нәрсә юк! – ди Гүзәлия. – Һәм алар бер-бер артлы өстәлеп кенә тора. Балаларымның спортка тартылуы үземнән күчкәндер дип уйлыйм. Мәктәптә укыганда бер генә спорт ярышыннан да калмадым. Чаңгы ярышында да, җиңел атлетика буенча ярышларда да гел призлы урыннар алдым. Физкультура укытучыларыма бүген дә рәхмәтлемен. Спорт чыныктыра, ихтыяр көче өсти. Кечкенәдән милиционер булырга хыялландым – хәрби кием киясем килде. Мәктәпне тәмамлагач, берничә тапкыр Район эчке эшләр бүлегенә дә барып карадым. Тик ишекләрен ачып кереп, теләгемне әйтергә, юнәлеш сорарга кыюлыгым җитмәде. Борылып кайтып китүдән уза алмадым... Мәрхүм әти-әниемнең эштән калып, безне җитәкләп йөрергә, каядыр урнаштырырга вакытлары булмады. «Терлекләр ач тора алмый бит, кызым», – дия иде Кибәче терлекчелек комплексында эшләүче әнием. Нишлисең, миңа насыйп эш булмагандыр...

Үкенүе түгел, искә төшерүе генә. Бүген башкарган хезмәтеннән бик тә канәгать Гүзәлия. Лесхоз картлар-инвалидлар йортында тәрбияләнүчеләргә бөтен йөрәк җылысын кушып тәмле ашлар пешерә. Инде биредә ашчы булып эшли башлавына да 11 ел вакыт узган. Авыр, җаваплы эш. Быел пандемия исә аларны, әйткәнемчә, бөтенләй көтелмәгәнчә сынаган. Үзизоляция режимы вакытында бер айга якын көн-төн хезмәт урыннарында булганнар. Ә өйдә биш бала... Әйтергә генә җиңел...

Гүзәлия кабат ирен телгә ала. Кабат: «Әле ярый ул аңлады, ул булышты», – ди.

Әңгәмәгә Радик үзе дә кушылды:

– Ничек инде аңламыйсың?! Бөтен коллективларына килгән сынау иде бит ул. Балалар зурлар булса да, өйдә әниләре юклыгы шактый сиздерде. Әмма без барыбыз да бик тырыштык. Төпчегебез Илфир гына ямансулап йөрде, гел: «Әни кайчан кайта инде?» – дип сорап торды... Гүзәлия – өебезнең кояшы, нуры инде ул. Бик эшчән, җитез, уңган... Аның белән тормыш итүе дә рәхәт...



Бер-берсен күз карашыннан аңлап, яклап-саклап яшәгәннәре әллә кайдан аңлашыла. Бәхет бит ул җитәкләшеп бер юлдан атлау гына түгел, уртак уй-хыяллар белән бер якка карап бару, дигән бер акыл иясе. Габдрахмановлар да әлеге гыйбарәнең асылына күптән инанган. «Үземнең дә, иремнең дә әти-әниләребез бик иртә вафат булды. Әллә шуңа да өлкәннәрне аерым ятаммы икән соң, белмим... Интернатта әби-бабайлар белән аралашырга безгә вакыт бик тими инде, әмма җай чыккан саен аркаларыннан булса да сөеп узам. Мондый язмышлардан үзең сакла, Ходаем, дип телим. Алар да балаларын безнең кебек кадерләп-сөеп үстергән бит», – дип моңсуланып ала Гүзәлия.

Юкка борчыла ул, Габдрахмановлар гаиләсендә балалар берсе өчен берсе терәк булып, туган кадерен, әти-әни хакын аңлап үсә. «Бөтен эшне гаиләбез белән башкарабыз. Бәйрәм табыннарын да бергәләп әзерлибез. Югыйсә Зилә белән икебез генә ничек өлгерик?! Улларыбыз кече яшьтән хатын-кыз эшен дә белеп үсә. Кызым ризыклар пешерсә, Илфар улым өстәлләрне бизәргә ярата. Эшләгәннәре минем өчен булса, өйрәнгәннәре үзләре өчен: тормыш булгач, барысының да кирәге чыгар. Теләсә нинди эштән курыкмаска кирәк», – ди Гүзәлия.


Балалар өчен иң әйбәт тәрбия ысулы – яхшы үрнәк икәнлеге күптән билгеле. Тәрбияле бала – җанга шатлык, йөзгә аклык китерер дигән борынгылар.

Фәридә ВИЛДАНОВА.
Саба районы,
Сабабаш авылы.

Фото: гаилә архивыннан

PRESSA

ХАТЫН-КЫЗ – ФӘРЕШТӘ УЛ!



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Фирзәр Мортазин – җырчы, композитор, Татарстанның халык артисты; гаилә стажы – 42 ел; балалары – Чулпан, Ленар; Оныклары – Алинә, Алисә, Сафина.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Минем хатын шикелле булсыннар. Чибәрлеге дә булсын, акылы да. Дуслар төнге икенче яртыда чакырып шалтыраталар иде, «Ник барасың?» – дип әйткәне булмады. Хатын-кыз таныш булмаган ирләр янында аларны узып сөйләмәсен, сүзгә кысылмасын иде ул. Һәр кеше үз урынын белергә тиеш. Бер дә таныш булмаган хатын-кызның сүзгә килеп кушылуын, гомумән, яратмыйм. Матурлыкка карамыйм. Кемнең кем икәне ике сүз алышуга ук аңлашыла.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Тиз үпкәләвен. Хатын-кыз бик тиз үпкәле инде ул. Ачыктан-ачык хыянәт итмәсә, барысын да гафу итәсең. Бер-береңә үпкәләп йөрү ике көннән артмаска тиеш. Үпкәләшкәндә, беренче үзем сөйләшә башлыйм. Бик кызу мин, әмма бервакытта та кул күтәргән кеше түгелмен. Гаилә өчен янып-көеп яшим. Шуңа хыянәттән башка барысына күз йомам.

3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Ялган сөйләгәнне һәм хыянәтне. Анысын да үзем күрсәм генә. Кеше сүзенә карап яшәргә ярамый. Хатын-кыз хыянәте ирләрнең мин-минлегенә бик нык тия. Сине хөрмәтләмәү дигән сүз ул. Аннан соң хатын-кыз ул – матурлык. Хатын-кыз ул – фәрештә. Аны ир-ат белән чагыштырып та булмый.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Аның бөтенесе бер кешедә булырга тиеш. Икесен бергә үзендә туплаган хатын-кызлар бар. Андый гаиләләрне күп беләм. Бәлки, аларга карап без дә үрнәк алганбыздыр. Мин, кая барсам да, хатын белән йөрергә яратам. Өйдә дә: «Кил әле, утыр, сөйләшик», – дим. Хатын-кыз бит ул өйдә гел нидер эшли. Миңа бер-береңне аңлап, киңәшеп яшәгән тормыш ошый. Кайбер гаиләләрдә ир белән хатын бер-берсеннән сер саклый. Без барысы турында да утырып сөйләшәбез. Заманында миңа икешәр капчык хат килә иде. Икәүләп утырып укыдык. Анда төрле хатлар бар иде.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә! Бергә озак еллар яшәгән саен, бер-береңә ярашасың. Дус та буласың, ике көн күрми торсаң, сагынасың. Менә мәхәббәт шул инде ул.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Тәкъдим ясап тормадым. Сыптырып алып кайттым кич. *(Рәхәтләнеп көлә.)* Наилә белән без бер авылдан. Мин ике сыйныф алдарак укыдым. Ул мине мәктәптә белмәгән. Өченче курстан соң каникулга кайткач, абыйлары белән бергә су коенырга барган идек. Ул да утырып барган булган. «Безгә мондый егетләр эләкмәс инде дип уйлаган идем», – ди ул шул вакытларны искә төшереп. Чәче озын, матур итеп киенгән, ябык вакыты. Укып бетереп, клубка эшләргә кайттым. Элек «вечер»лар була иде. Шунда таныштык. Ул әле кичке мәктәптә укый иде. Ике ел йөрдек тә өйләнештек. Хәзерге кебек төчеләнеп тәкъдим ясаулар булмагандыр ул чакта. Кич чыккач: «Әйдә, кайтабыз», – дидем дә алып кайттым. Туй да булмады, балдак та кидертмәдем. Үпкәләмәде, андый кеше түгел. Икенче көнне туганнар җыелышып утырдык та, өченче көнне икәүләп бәхет эзләп Златоустка чыгып киттек. Балдакны бер елдан соң кидерттем. Мин үзем аны бик тиз салдым – әткәйгә бирдем. Наилә дә кими.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?

– Юк инде. Әнисенә охшаган кыз булса, әнисе көнләшә башлый. Андый гаиләләр озак яши алмый. Хатын белән әниеңнең җаннары охшаш булсын. Ул яктан бәхетлемен. Әнкәйнең үлгәненә унбиш ел, һаман сагына аны хатын. Бик нык дус яшәделәр.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Исәп-хисап буенча өйләнгән ирләр бар. Аннан үзенең юк кеше икәнен яши-яши аңлый. Хатын акчаны күп эшләгәч, ул командир була инде. Заманында Наиләнең миннән күп эшләгән вакытлары булды. Җәлли идем. Нужа күрде. Аннан соң өйдә тавыш акча җитмәүдән дә чыга. Концертлар белән йөри башлагач, тормыш бөтенләй икенче төрле төсмер алды. Иркенәйдек. Ун ел эшләде дә, аннан соң өйдә булды, эшләмәде Наилә. Юк, дөрес әйтмим, хатын-кызның эше, Алла сакласын, тавык та чүпләп бетерерлек түгел.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Җирәнгеч инде. Ир-ат ясарга тиеш нәтиҗәне. Хатын-кыз яратып, ир яратмаса, нәрсә була инде ул?! Ир бик тиз үзгәрәчәк. Сәхнәгә менеп, колакка пышылдап мәхәббәт аңлатучылар булды. Мин аны бервакытта да җитдигә алмадым. Наилә апагыз белән дә мәхәббәт турында сөйләшеп утырмыйбыз. Ул күзләрдән, кылган эшләрдән күренә. Хатын-кыз үзен ир беренче булып мәхәббәт аңлатырлык итеп тотарга тиеш. Менә шул вакытта чын хатын-кыз була инде ул! Ир кеше яратуын әйтсен ул, хатын-кыз әйтмичә генә яратсын. Яраттыра алсын. Хәйләкәр булсын.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Хәзер акча җәлеп итә. Миңа бер акыллы кеше: «Нинди генә чибәр булып та, кесәңдә акчаң булмаса, синең белән беркем сөйләшми», – диде. Шундый замана килеп җитте хәзер.

11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Берни көтмим. Ничек бар, шундый мин. Килеп мактаганнарын яратмыйм, чөнки икейөзле кешеләр күп.

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Матур һәм көчле хатын-кызлар тикторммый алар. Аңладыгыз инде, әйеме?! Матур булса, аны бөтен кешенең карыйсы килә. Шуңа уртача матурлыкта булсын инде ул. Көчле хатын-кызларга очраганым юк.

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Хатын-кызның рульдә утыруын яратмыйм. Бик сак кына йөриләр, диләр алар турында. Дөрес түгел. Ул борылганда утын кабызып куя да, үзен хаклы дип уйлый – каршыңа килә дә чыга. Яратмыйм шуңа. Ирләр белән парлап аракы эчеп утырган, бездән дә узып сөйләп утырган хатыннарны яратмыйм. Спиртлы эчемлек эчкәннән соң теләсә нинди матур хатын ямьсезләнә. Бик чибәре дә!

14 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы, әллә инде юл куясызмы?

– Мин исбатлыйм. Ахырга кадәр барам. Минем хатын йолдызлык билгесе буенча Чаян булса да, күбрәк ул юл бирә. Наилә дә хаклы була, әмма минем аста каласым килми. Дөрес түгеллегеңне ничек танымак кирәк?! Мин сезгә ачыктан-ачык әйтәм: бер ир дә танымаячак аны. *(Көлә.)* Кайвакыт хаксызлыгыңны да беләсең, әмма барыбер үзеңнекен исбатларга тырышасың. «Без – хуҗа, без – баш», – дип йөрибез, ләкин хатын-кыз үзенекен эшләми калмый. Геройланабыз гына инде. *(Көлә.)*

15 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?

– Кайчан кайтсам да, хатын йокламыйча көтеп тора. Иртәнге өчләрдә-дүртләрдә гастрольләрдән кайткан вакытларда да йокламый, өстәл әзерләнгән. Казанга килгәч: «Наилә, бүген кайтмыйм. Зинһар, йокла, яме», – дип шалтыратсам, йокларга мөмкин. Күбрәк Салаватларда кунам. Аның хатыны Ләйсән дә шулай. Йокламый көтеп тора, өстәле әзер. Безнең хатыннар бу! Башкаларныкын белмим. Наилә берәр кая китсә, пешереп, полуфабрикатлар ясап калдыра. Бер айга җитәрлек итеп әзерли. Үзем пешермим. Минем бит хатыным бар. *(Көлә.)* Безгә берәр кунак киләсе булса, ул ике көн йокламый әзерләнә башлый инде. Күршеләр бик яхшы безнең. Алар кереп җитә. Субботник оештырып, пилмәннәр ясап аталар. Гомер буе шулай яшәдек.

16 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

– Наилә миннән алда киенеп куя. Кибетләрдә көтеп утырганда гына ачу килә инде. «Теге бетерә дип йөрим», – ди үзе дә. *(Көлә.)* Аның өчен ызгышкан юк. Кеше яши-яши бербөтенгә әйләнә. Аларны аерып алып булмый. Без дә шулай.

17 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм иң ошамаганы?

– Бәйрәм саен бүләк бирешә торган кешеләр түгел без. 8 Мартка чәчәк алып кайтсам да: «Ике көндә шиңә ул, акча әрәм итеп нигә алдың инде? Нәрсәгә кирәк ул миңа, Фирзәр», – ди. *(Көлә.)* Бүләк дип тормыйбыз, нәрсә кирәк, шуны барабыз да сатып алабыз. Наилә 60 яшемә 60 мең акча җыйган. Шуңа исем китте инде. Әкренләп җыйган бит ул аны. Туган көнемә ау мылтыгы алып бирде. Дуслар белән ауга чыгар өчен генә инде ул мылтык. Рәхәтләнеп аралашып, сөйләшеп кайтасың шуннан. Мин киекләрне атарга җәллим, әмма янымда мылтык булсын. Наиләгә бүләкне үзеннән сорап кына алып бирәм. Нигә кирәкмәгән әйбер алырга? Мин романтик түгел. «Үчти-үчтиләр»не, гомумән, яратмыйм. Әмма Наилә белә: ул булмаса, мин дә булмас идем. Өйдә көтеп торучың булмаса, менә монда килеп җырлыйсы да килмәс иде. (Интервью концерт алдыннан алынды. – *Ред.*) Хатын-кыз – яшәүнең яме. Бер-береңне ихтирам итеп, кирәклегеңне белеп яшәгән вакытта гына яшәү ямьле була.



Бәләкәчебезнең һәр иртәдә сөенечтән балкыган күзләрен күрү нинди бәхет! Аларда гел елмаю гына чагылсын өчен без, әти-әниләр, барысын да эшләргә әзер. Тик кайчагында нарасый иртән күзен ачып карый алмый – керфекләре бер-берсенә ябышкан була. Күзнең ялкынсынуы сабый балаларда еш очрый. Республика балалар клиник хастаханәсенең табиб-офтальмологы Фәрит Гыйльманов белән конъюнктивитның сәбәпләре һәм аны кисәтү юллары хакында сөйләшәбез.

КОНЪЮНКТИВИТ

Күз алмасын һәм күз кабакларын юка элпә – конъюнктива каплый. Әлеге элпә күзне җәрәхәтләнүдән, төрле микроблардан саклый. Конъюнктиваның бөтенлеге бозылу ялкынсынуга китерә, һәм бу халәт конъюнктивит дип атала. Ялкынсыну бактерияләр, вируслар һәм аллергия аркасында килеп чыгарга мөмкин. Конъюнктивит, аеруча вируслар белән бәйле булганы, йогышлы авырулардан санала.

Бактериаль һәм вируслы төрләреннән аермалы буларак, аллергияле конъюнктивит кинәт башлана. Гадәттә бу хәл бала берәр ят ризык ашаганнан, йорт хайваннары белән аралашкан, косметика чаралары кулланганнан соң күзәтелә. Ялкынсынган күз башта түзә алмаслык булып кычыта. Аннары кызара, яшьләнә...

Әлбәттә, баланың күзендә ялкынсыну процессы башлануын күрү белән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ниндидер тамчылар тамыза башлаганчы, ялкынсынуның нилектән килеп чыгуын ачыклау мөһим. Дәва чаралары шуңа карап билгеләнә. Аллергия аркасында башланган конъюнктивитны дәвалауның төп нигезе – аллергия процессын китереп чыгарган матдәне ачыклау һәм ул аллерген белән контактны туктату.

Конъюнктивитның нәкъ менә бәләкәй балаларда ешрак күзәтелүенең сәбәбе аларның иммунитетлары ныгып җитмәүдә. Икенчедән, кечкенә балалар күзләренә пычрак куллары белән кагылырга, төрлечә җәрәхәтләргә мөмкин. Бу исә бактерия һәм вирусларга юл ача. Балалар бакчасына йөрүчеләр бер-берләренең уенчыклары белән уйный, бу да чирнең таралуына китерә. Еш кына конъюнктивит белән бер үк вакытта баланың тамак, борын эчләре дә ялкынсынырга мөмкин.

Сәбәпләре

- төрле инфекцияләр: стрептококк, гонококк, стафилококк һәм башкалар;
- шартлы-патоген бактерия һәм гөмбәләр;
- вируслар, шул исәптән, герпес һәм аденовируслар;
- көчле аллергеннар;
- күзнең механик җәрәхәтләнүе;
- гигиена таләпләрен үтәмәү;
- дәвамлы колак-тамак-борын ялкынсынулары.



Моны белү мөһим

- Сирәк очракта конъюнктива ялкынсынуы җитдирәк һәм куркынычрак авыруларга да китерә: чир күзнең тирәнрәк өлешләренә керә һәм анда үзгәрешләр тудыра. Конъюнктивит булганда йомшак линза киюне туктатырга, ә кулланылган линзаны ыргытырга яки тиешенчә йогышсызландырырга кирәк.
- Профилактикага беренче чиратта иммунитетны күтәрү чаралары керә. Икенчедән, юмаган кул белән күзгә кагылмаска; өченчедән, коллективта конъюнктивит белән авыручы баланы тиз арада күреп алып, сәламәт балалардан аралар тырышыгыз.





Табиб киңәш итә: баланың керфекләре эренләп ябышу аңа кыенлык тудыра. Һәр күз өчен аерым мамык кисәге алып, күзне кайнаган җылымса су белән юарга кирәк. Чирләүче баланы балалар бакчасына, мәктәпкә җибәрми торалар. Бу чир өйдәгеләргә дә йогарга мөмкин, шуңа күрә кулларны ешрак юыгыз, күзләрегезгә орынмагыз. Өйдәге һәр кешенең сөлгесе аерым булырга тиеш.

Билгеләре:

- күзнең кызаруы, ялкынсынуы;
- күз кабакларының шешенүе;
- күз кабакларының эренләве;
- йокыдан уянганда керфекләренең бер-берсенә ябышуы;
- баланың йокысы начарлану һәм аппетит булмавы;
- еш кына куллары белән күзен ышкуы;
- зуррак балаларның күзнең кыруыннан, әчетүеннән зарлануы.



Фото: www.pixabay.com

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Әлеге чир белән һәр хатын-кыз үз гомерендә бер генә тапкыр булса да авырмый калмый. Күп вакытта без аңа игътибар итмәскә тырышабыз яисә дус хатыннар киңәше белән үзбелдекләнеп дәваланган булабыз. Ләкин кольпит җиңел генә бирешә торган чир түгел. Республика клиник хастаханәсенең гинекология бүлеге табибы Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА белән шул хакта сөйләшәбез.

КОЛЬПИТ

Кольпит яисә вагинит – аналык җиңсәсенең лайлалы тышчасы ялкынсынуы ул. Һәр хатын-кызның үзенә генә хас микрофлорасы бар. Әлеге эчке тирәлек гел үзгәреп тора. Микрофлора, нигездә, лактобактерияләрдән гыйбарәт, һәм ул патоген микроорганизмнардан саклау вазыйфасын башкара. Лактобактерияләр җитәрлек булганда, хатын-кызның җенси сәламәтлегендә проблемалар килеп чыкмый.

Табибка кольпит аркасында мөрәҗәгать итүче хатын-кызларның 60 проценты 18 яшьтән 48 яшькәчә булганнар. Ул яшүсмерләрдә, хәтта кечкенә кызларда да очрарга мөмкин. Кыз балаларда төп сәбәп – интим гигиена таләпләрен төгәл үтәмәү. Кольпит климакс алды яшендәге хатын-кызларда да еш күзәтелә. Бу очракта ул организмдагы гормоннар үзгәреше белән дә бәйле.

Кольпитның специфик булган һәм специфик булмаган төре бар. Беренче очракта ялкынсынуның сәбәбе – организмга зарарлы микроорганизмнарның үтеп керүе. Болар: төрле бактерияләр, вируслар, гөмбәләр. Икенче очракта исә кольпитны шартлы-патоген бактерияләр китереп чыгара. Алар организмда даими яши, ләкин күп күләмдә булмаганга, сәламәтлеккә зыян китерми.

Беркадәр бүлендек – хатын-кыз организмы өчен норма. Алар үтә күренмәле, аксыл, кайчак саргылт төстә һәм аз күләмдә була. Күп вакытта иссез яисә җиңелчә генә әчкелтем исле булуы мөмкин. Бүлендек килү көчәйсә, авыр ис сизелсә, җенес әгъзасында уңайсызлык барлыкка килсә, хатын-кыз табибына күренүне кичектермәскә кирәк.

Дәваны бары тик табиб кына билгели ала. Күп очракта хатын-кыз үз белдеге белән дәвалана башлый. Әйе, баштарак нәтиҗәсе дә булырга мөмкин, ләкин бераз вакыттан соң чир кабат килеп чыга. Дәва комплекслы булырга тиеш. Иң элек аның сәбәбе ачыклана. Шуңа карап дару препаратлары сайлана. Кольпит белән берлектә, организмдагы башка чирләрне дә дәваларга кирәк була.

Дәваланганда, җенси тормыш тукталып тора. Шулай ук ир кешенең дә тикшеренү узуы һәм дәвалануы мөһим.

Сәбәпләре

- җенси юл белән таралучы патоген һәм шартлы-патоген бактерияләрнең өстенлек алуы;
- үз белдегең белән генә төрле дарулар, мазьлар куллану;
- аналык җиңсәсендәге төрле җәрәхәтләр;
- балага узудан саклаучы препаратларның тәэсире;
- интим гигиена таләпләрен үтәмәү;
- организмда гормональ үзгәрешләр;
- эндокрин чирләр;
- эчке киемне дөрес сайламау.

Билгеләре

- җенес әгъзасының кызаруы, кычытуы, әчетеп әрнүе;
- үлекле бүлендек килүе;
- авыр ис сизелү;
- якынлык кылганда авырту тою;
- кече йомыш белән еш кысталу;
- эчнең аскы өлеше авыртып тору.

Профилактика

- елга бер тапкыр, ә иң яхшысы: ике тапкыр гинекологка күренү;
- кышкы-язгы чорда поливитаминнар кабул итү;
- көндәлек астарлардан баш тарту;
- эчке киемнең табигый тукымалардан тегелгәнен генә сайлау;
- спринцовка белән мавыкмау;



Табиб кисәтә

■ Тиешенчә дәваланмаганда кольпит хроник формага күчәргә мөмкин. Ә моның исә тора-бара кысырлыкка яисә яралгының аналыктан читтә урнашуына китерүе ихтимал. Ялкынсыну процессы аналык җиңсәсен генә түгел, аналыкның үзен, күкәйлекләрне дә зарарларга мөмкин. Болар инде җитди халәт. Кольпит аркасында йөклелекнең вакытыннан алда өзелү куркынычы да бар. Шуңа күрә билгеләре булмаганда да, мазокта патоген микроблар барлыгы ачыкланса, хатын-кыз дәваланырга тиеш.

БУ МӨҺИМ: специфик кольпит ир белән хатынның бергә дәвалануын һәм дәвалану вакытында җенси мөнәсәбәтләрне туктатып торуны яисә барьерлы саклык чаралары куллануны таләп итә.



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.

PRESSA

ТАМЧЫЛАР ТАМГАН ЧАКТА

Яз ул – яңа тормышның башлануы. Җир уяна, табигать терелә. Ә безгә – бакчачыларга эш арта гына бара. Тәрәзә төбендәге «бакчабыз» киңәя, чөнки март – яшелчәләрне савытларга чәчүнең иң кызган вакыты.

Яшелчәчегә

Март аенда һәвәскәр яшелчәчеләрнең тәрәзә төбе питомникны хәтерләтә. Хәзер помидорларның – уртача соң һәм уртача өлгерешле, ә борыч белән баклажанның иртә өлгерүче сортларын чәчү вакыты. Безнең полосада моны мартның беренче ун көнлегендә эшләсәң яхшырак. Иртә өлгерешле томатларны март ахырында чәчсәң дә ярый.

Быел март аенда орлыкларны чәчү өчен уңай булып 3–8, 15–18, 22–26, 30–31 нче көннәр санала.

Пикировкалауны исә ике чын яфрак чыгуга ук башкарсаң яхшы. Тамырларның артык зураеп, бер-берсе белән үрелеп беткәнен көтәргә кирәкми.

Тәрәзә төбендә яшелчә үсентеләре сузаеп китүчән. Төп сәбәбе – температураның югары булуы. Бу хәл килеп чыкмасын өчен, тишелеп чыккан үсентеләрне салкынча урынга куярга кирәк. 16 градус җылылык – иң кулае. Кәбестә үсентеләре өчен исә 12 градус җылы да җитә. Тагын бер сәбәбе – яктылык җитмәү һәм дымның күп булуы. Иртә язда үсентеләр өчен көн яктысы 12–16 сәгатьлек булырга тиеш. Исегездә тотыгыз: дым күп булса, үсемлекләр сабакка үсә, ә тамырлары өлгерми кала.

Бакчачыга

Март башында, агачлар әле кышкы йокыдан уянып җитмәгән мәлдә, ябалдашларны формалаштырып, санитар кисү үткәрелә. Кәүсәләрдә су йөри башлаганчы, киселгән урыннар җөйләнеп өлгерергә тиеш. Моның өчен һава температурасы 3–5 градус җылы булган көнне сайлыйлар.

Агачны башта җентекләп тикшереп чыгыгыз. Турыга үсеп, ябалдашларны куертучы бер еллык ботакларны (русча – «волчки») кызганмыйча, юк итегез. Аларны аеруы кыен түгел: кайрысы ачык төстә, яфрак бөреләре сирәк, ә җимеш бирә торган кыска тармаклары бөтенләй дә юк. Кайчагында алмагачта үзара чалышып үскән ботаклар пәйда була. Бер-берсенә комачаулый торган мондый ботакларның зәгыйфьрәген яисә башкаларына комачаулык тудыра торганын кисәргә кирәк. Мул җимеш бирсен һәм чирләмәсен өчен, ябалдаш ачык булырга, кояш нурлары иң аскы ботакларга да яхшы үтеп керергә, арадан җил йөрерлек булырга тиеш. Агач артык биек булып үсеп китсә, аны тәрбияләве дә, җимешләрен җыюы да кыен. Шуның өчен төп кәүсәне һәм скелет ботакларны әледән-әле кыскартып кисеп торалар.

Юанрак ботакларны кискән урыннарга бакча җилеме (садовый вар) сылап куярга онытмагыз.



Үсемлекләрне тукландыру

Үсентеләр яхшы булып үссен өчен, аларны вакытында тукландырып тору мөһим. Беренче тапкыр бу эшне 2–4 чын яфрак фазасында башкаралар. 10–12 көннән соң икенче кат тукландыралар. Өченче тапкыр үсемлекләрне даими урынга күчереп утыртып, 10–12 көннән соң ашлыйлар.



Азот, фосфор, калий – үсемлекләргә кирәкле өч төп элемент. Үскән мәлдә үсемлекләр азотлы ашламаларга мохтаҗ. Бу максаттан нашатырьлы спирт кулланырга мөмкин. Ул 82 процент азоттан тора. Азот үсемлекләрнең сабак-яфрак системасын үстерү өчен мөһим.

Икенче тапкыр тукландырганда исә фосфорлы ашламалар кулланыла. Үсемлекләрнең тамыр системасы ныгысын өчен фосфор кирәк. Чәчәккә бөреләнгән чорда да алар фосфорга мохтаҗ.

Үсемлекләрне җимеш биргән чорда калийлы ашламалар белән туклandыралар.

Бүлмә гөлләре

Март ае – бүлмә гөлләрен формалаштыру вакыты. Озын булып үскән сабакларны кисеп, янтармаклар үсүне тизләтәбез. Күп кенә гөлләрнең чәчәкләре нәкъ менә яшь сабакларда күбрәк була. Бу айда яраткан гөлләрегезне үрчетергә керешә аласыз. Төбеннән яңа үсентеләр чыккан булса, аларны яңа савытларга күчереп утыртыгыз.

Көздән күчерелми калган бүлмә гөлләренең туфрагын мартта алыштырырга була. Ләкин чәчәккә бөреләнгән, актив үсү чорындагы яисә туфрагы әле яңа булганнарын күчерүне кичектерәләр.

Күчереп утыртуның да үз кагыйдәләре бар. Артык озын булып үскән тамырларны беркадәр кыскартып кисәргә һәм араларга кирәк. Киселгән урыннарга спирт тидереп, йогышсызландыралар. Чүлмәкнең элеккегесеннән 2–3 см зуррак булганын сайлыйлар.

Күчереп утыртылган яисә тармаклары кыскартып киселгән гөлләрне берничә көнгә туры кояш нурларыннан сакларга кирәген дә онытмагыз.

Кыш буе чәчәктә булган цикламен, миләүшәләрнең хәзер тынлык чоры башлана. Аларга су сибүне сирәгәйтәләр, ләкин туфрагының тулысынча кибүенә юл куймыйлар.



Фото: www.pixabay.com

ХАЙЛАЙТЕРНЫ ДӨРЕС КУЛЛАНАБЫЗ



Замана хатын-кызының макияжын битне контурлаудан башка күз алдына китереп булмый хәзер. Контур ясау яисә битнең формасын матурлау өчен бронзер, румяна һәм хайлайтер кулланыла. Алар ярдәмендә биттәге кимчелекләрне яшереп, кирәкле урыннарын күрсәтеп була. Румяналны инде күптән кулланалар, ә менә бронзатор белән хайлайтер кулланылышка яңа кереп бара. Хайлайтер ару билгеләрен бетерә, бит ял иткән кешенеке кебек ягымлы, нәфис күренә. Аның текстурасы яктылыкны тотып (кояш йә ясалма ут яктысы), аны чагылдыра, шул рәвешле табигый матурлыкны арттыра. Визажист Алсу ГОМӘРОВА безгә хайлайтер сөртү серләрен өйрәтер.









Хайлайтерны скульптор, румяна белән бергә кулланалар. Скульпторны яңак сөяге астына сөртәләр (бит җәенке булган очракта гына, озынча тар битлеләргә сөртергә кирәк түгел), борын яфракларына тидерәләр. Румяна, матрешкалардагы кебек, бит уртасына сөртелә.

Текстурасы буенча хайлайтер пудра, крем кебек, карандаш рәвешендә дә була. Көндәлек макияж өчен тыгыз пудра кебек хайлайтерны кулланырга киңәш итәм. Беренчедән, битне майландырмый; икенчедән, ул кечкенә, аны сумкада да йөртергә була.

Хайлайтер биттә берничә зонада сөртелә.

Яңак сөяге өстенә. Дөрес, сөяк нык чыгып торганнарга кулланырга киңәш ителми. Яктылыкны чагылдырып, хайлайтер күләм эффекты бирә. Яссы битле кешеләр өчен менә дигән табыш.

Борын өстенә. Шулай эшләгәндә, борын нәзек һәм юка күренәчәк. Борыны озын кешеләргә хайлайтерны борын очына кадәр сөртергә кирәкми. Ул урынны каралту хәерлерәк. Борын киң булганда яфракларын каралтыгыз.

Күзнең эчке почмакларына. Күзләре якын урнашканнар өчен бу үзенә күрә бер лайфхак. Кечкенә пумала белән хайлайтер тидергәннән соң, күзләр бер-берсеннән ерактарак күренә башлый. Хайлайтерны бераз гына өске ирен өстенә тидерсәгез, иреннәр кабарынкы төсмер алыр.

Ияккә сөртелә. Күпләр аны ияк очына сөртеп хаталана. Һич тә алай ярамый. Хайлайтер биттә шәүләләр булган урынга сөртелә. Шундый бер урын – ияктә аскы ирен бөкләнеп киткән зона. Кашлар күтәрелеп торган эффект бирсен өчен, кашның аскы ягына да әз генә сөртәсе. Кашның кырыена гына, күз кабагы өстенә түгел. Юкса күзләр шешенгән кебек тоелыр.

Шуны онытмагыз: бар нәрсәнең чамасы булырга тиеш. Артык күп хайлайтер сөртү дә битне яңа ел чыршысы кебек ялтыратыр. Әз-әзләп, кирәкле урыннарга гына тидерергә өйрәнегез.



Хайлайтер куллануны QR-код аша кереп, видеодан да карый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



ТАБИГЫЙ КОСМЕТИКА

Natura Siberika компаниясе бүген, Себер һәм тайга үсемлекләренең бар көчен һәм шифасын туплап, гүзәллек һәм сәламәтлек косметикасын җитештереп чыгара.
Natura Siberika косметикасын ясаучылар, дәвалау үзлегенә ия иң яхшы ингредиентларны эзләп, ерак экспедицияләргә чыгып китә.



Поши сөте. Natura Siberika продуктларының яңа – кыргый Себернең иң сирәк ингредиентларын туплаган Wild Siberika сериясе поши сөте үзлекләренә нигезләнгән. Пошиның үт куыгы булмый, шуңа күрә алар организмында әчү процессы бармый, үсемлекләрнең барлык файдалы матдәләре сөткә эшкәртелә. Шулай итеп, ана поши – үләннәрне шифалы сөт итеп җитештерүче «фабрика». Ул гипоаллерген, тире тарафыннан 100 процент үзләштерелә. Кыргый пошилар 200 дән артык төрдәге кыргый җиләк, үлән һәм куаклар – гөлҗимеш, камырлык, балан, агач кайрылары, тал ботаклары, каен, усак яфраклары, төрле тамырлар һәм гөмбәләр белән туклана. Поши сөтенең майлылыгы 14–18 процент тәшкил итә, аксым – 10 процент чамасы. Витаминнар, микроэлементлар, аминокислоталар сыер сөтенә караганда биш тапкыр күбрәк. Ферментлар һәм аксым күп булу аркасында, сөт дымландыру сәләтенә ия, тирене картаюдан саклый.

Камчатка эдельвейсы. Составында танинның күп микъдарда булуы бик көчле саклау үзлеге хасил итә, тирене тышкы тирәлекнең зарарлы тәэсиреннән, кояш яндыруыннан, вакытыннан алда картаюдан саклый. Тирене яхшырта, тигезли, сәламәт төс бирә. Антисептик, бактерияләргә каршы тору үзлегенә ия.
Арктика розасы. Кыргый арктик роза Таймырның таулы өлешләреннән башлап Төньяк Җирнең арктик чүлләренә кадәр мәйданда идеаль экологик шартларда үсә. Ул үзеннән чыккан җылылык хисабына үзен саклап кала ала. Тирә-яктагы карны эретеп, су белән туена, һәм ул корылыклар башланганчы суны яфракларында саклап утыра. Арктика розасының менә шушы гаҗәеп үзлеге иң коры тирене дә йомшарта ала. Арктик роза мае – A, B, PP витаминнары һәм тирене ныгытучы, йомшартучы, ефәк кебек шомартучы антиоксидантлар чыганагы.
Амур бәрхете. Амур бәрхете экстракты тирене ныгыту һәм дымландыру өчен кулланыла. Шулай ук коллаген синтезын стимуллаштыра, тирене йомшак кына чистарта, аны зарарлы тышкы тәэсирдән һәм инфекцияләрдән саклый. Нанай халык медицинасында Амур бәрхетенең кайры асты катламы дерматитны һәм хроник дерматомикозны дәвалый торган мазьларда кулланыла.


РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



RESEDA ODOR
PROFESSIONAL MOLECULAR COSMETICS

Ковид бөтен дөнья өчен зур сынау булды. Бу мәкерле авыру аша узганнарның чирләре озакка сузылды, сәламәтлекләре какшады. Чәчләргә дә зыяны булды аның. Чәчләрне элекке хәленә кайтару өчен нишләргә? Озын кыштан соң организмдагы авитаминоз да үзен сиздерә: чәчләргә аның да тискәре тәэсире бар. Косметика сәнәгате бу җәһәттән эшне ничек оештыра? Могҗизага тиң нинди чаралар хатын-кызны сәламәт һәм матур итә ала?

Россиядә табигый косметика җитештерүчеләрне күп дип әйтеп булмый. Ә безнең республикада исә алар тагын да санаулы. Шулай булса да, фән һәм заманча технологияләр белән бергә атлаучы татарстанлылар искиткеч нәтиҗәләр күрсәтә. «РеседаОДОР» молекуляр косметикасы организмның яшерен резервларын эшкә җигеп, биологик запасларның җитешмәгән компонентларын тулыландырырга ярдәм итә. Матурлыгыбыз өчен җаваплы эчке ресурсларыбызны саклау өчен, организмны тернәкләндерү һәм баету белән нәкъ менә хәзер шөгыльләнә башларга вакыттыр, бәлки.



info@resedaodor.com **resedaodor.com** **@resedaodor**

РЕКЛАМА

ТЫЛСЫМЛЫ ХУШ ИСЛӘР...

Үзеннән ассоциацияләр һәм истәлекләр белән бәйле сизелер-сизелмәс шлейф калдыручы нәфис хуш ис кемне генә дулкынландырмый икән. Очраклы гына таныш исләрне тоеп алып, күз ачып йомган арада үзең дә сизмәстән рәхәт бер халәткә чумасың. Ул хуш исләр дулкынландыра, үзенә тарта, сихерли, тәмам күңелне кузгата.

«Мәхәббәт – беренче чиратта, химия ул, аннан соң гына хисләр, башкасы», – ди галимнәр. Бик мөмкин. Кайчак бинага кергән кешедән бик примитив парфюм исе тарала да, аннан тизрәк котыласың килә башлый.

Синең парфюм башкаларда канәгатьсезлек тудырса, бер дә күңелле түгел. Киресенчә дә булырга мөмкин: әллә ни күзгә дә ташланмый торган ханым узып китә – ирләр аның артыннан сихерләнгәндәй карап кала. Парфюмны дөрес сайлый белергә кирәк шул! Ошау-ошамау – бер нәрсә. Кайчак дус кызыңның йә берәр танышыңның хушбуе бик ошап та, синең тәндә алардагы кебек ачылмаска мөмкин... Тән тиресе, аның структурасы, дымлылыгы һәм майлылыгы төрле кешедә төрлечә бит. Аннары инде күңел кайта.

Хуш исле беренче композицияләр борынгы Мисырда барлыкка килгән, диләр. Ул вакытта парфюмериянең ике төре булган.

Гыйбадәтханәләрнеке. Дини йола буенча, тәтенгә аерым ис бирер өчен, төрле сорттагы ароматлы матдәләрне яндырганнар. Баллы исләр таратып, аллаларны җәлеп иткәннәр, явыз көчләрне, чума һәм башка авыруларны куганнар.

Халыкныкы. Көнкүреш парфюмериясе хуш исле майлардан торган. Аны, кояштан саклану чарасы буларак, тирегә сөрткәннәр. Мисырда югары катлау ирләре һәм хатын-кызлары, үз статусларын белдерер өчен, лилия чәчәге хуш исен файдаланган.

Грециядә парфюмерия Аллаһы Тәгаләдән бирелгән промысел саналган. Һәм алар билгеле бер аромат буенча аерылган. Мәсәлән, матурлык һәм мәхәббәт алиһәсе Афродитага роза һәм миләүшә чәчәкләре исе туры килгән. Кешелек дөньясына хушбуйны Афродита керткән дигән риваять яши.

Парфюм җитештерү өчен иң популяр ингредиентлар гарәпләр яши торган ярымутрауда табылуын искәртсәк, ислам мәдәниятенең дә мондый һөнәрчелек үсешенә йогынтысы булу гаҗәп түгел. Безнең эрага кадәр VI гасырда ук хуш исләр таратучы әйберләр кулланылышта булган. Гарәп философы һәм галиме Әл-Кинди, шәрабны дистилляцияләп, чиста спирт җитештереп булганын ачкан. Аны бүгенге көн парфюмериясенең атасы дип йөртәләр. Әл-Кинди сирәк үләннәр һәм чәчәкләрнең майларыннан күптөрле хушбуйлар уйлап тапкан. Духилар, майлар, мазьлар әзерләү буенча аның 100 сере һәм рецепты бар.

Ә безнең борынгы әбиләребез нәрсәләр кулланган, татар хатын-кызлары нинди ароматларга өстенлек биргән? XIX гасыр ахырында татар хатын-кызлары исле сабыннарны, роза майларын яратып кулланган. Авыл кызлары ярминкәләрдә роза суын сатып алып, шуны мулдан кульяулыкларына сипкән. Җиләк сабыны, канәфер һәм бөтнек майлары әбиләр күңеленә хуш килгән. Мунчада юынганнан соң, тәнгә бөтнек мае сөрткәннәр. Көнкүрештә хәзер дә төрле үләннәрдән бәйләнгән себеркеләр кулланыла. Алар организмны ял иттерә, үпкәләрне чистарта. Сәүдәгәрләр катлавыннан булган хәлле татар хатыннары одеколоннарга өстенлек биргән, ә татар буржуазиясе һәм югары катлау кешеләре Франция хушбуйларын, гарәп һәм һинд майларын кайтарткан.

Парфюмны кәефкә, ел фасылына карап үзгәртеп торырга була. Бер үк хушбуйны еллар буе кулланып йөрүчеләр дә бар. Хушбуй, ислемайлар – образны тулыландыра торган деталь. Нәкъ менә шулар сезне әйләнә-тирәдәгеләргә таныта, шул хуш ис сез булып хәтергә сеңеп кала.

Без парфюмнан файдалана беләбезме, иң мөһиме – аны сайлап ала беләбезме? Парфюмның җәлеп итү сәбәпләре төрлечә булырга мөмкин. Әниең йә дәү әниең яратып кулланган классик Шанельнең исе, яшүсмер чакта үзең беренче тапкыр сайлап алган нәфис чәчәк исе сезгә бик якын булу гаҗәп түгел. Шулай да, белгечкә мөрәҗәгать итеп, парфюмыбызны яңартыргадыр, бәлки? Хәзер бит консультантлар бар, һәм парфюмны алардан алу күпкә арзангарак төшә: чөнки бу бәягә парфюмерия салоннары һәм андагы хезмәткәрләр штаты өчен аренда түләүләре керми.

P. S. Сез исә консультант Алина Нәбиуллинага мөрәҗәгать итә аласыз. Алина натураль һәм сертификацияләнгән парфюмерия белән шөгыльләнә, парфюм сайлауда тәҗрибәле белгеч исәпләнә. Ул эшли торган Essens компаниясе теләсә кайсы зәвыкка туры килерлек сыйфатлы товар белән җәлеп итә. Элиталы парфюмериянең кабатланмас үрнәкләре тәкъдим ителеп, алар гел яңартылып тора. Алина сезнең имиджга туры килә торган, матурлыгыгызны ача торган парфюмны сайлашырга һәрвакыт әзер.

Рәмзия КАШАПОВА

ESSENS АРОМАТЫ
Синең шармны ача һәм кабатланмас образ тудыра!
Essens ароматлары буенча синең шәхси консультант @_alina_nabiullina
89196346771
✓ Коллекциядә җиде аромат: хатын-кызлар / ир-атлар өчен.
✓ Ароматлар – билгеле брендлар стилистикасында.
✓ хушбуйлар 20% концентрацияле.
✓ өч нотада тәмам ачылалар, җиңел таралып, үзенә тартып тора торган шлейф калдыралар.
✓ Бик озак саклаunion!
РЕКЛАМА

ЭКО-дизайн

Бүгенге архитектура һәм дизайн дөньясында бар да шулкадәр тиз үзгәрештә. Бер тенденцияне икенчесе алыштыра, бер материал урынына яңасы барлыкка килә. Ләкин вакытлар үтсә дә, актуальлеген югалтмый, кыйммәте кимеми торган әйберләр бар. Мәсәлән, агач, таш, табигый тукымалар, металл беркайчан да модадан чыкмаячак. «Интерьер» рубрикасының бүгенге кунагы – архитектор һәм дизайнер Рәис МИНГАЛИЕВ табигый материалларны заманча интерьерда куллану хакында сөйләп кенә калмый, кызыклы идеяләре белән дә бүлешә.





Фото: Р. Мингалиев

Хәзерге дизайнерларның күбесе интерьерларда ЭКО-стиль элементларын кулланырга омтыла. Әлеге стиль табигый һәм гади материаллар белән эшләүне күздә тота. Ләкин мондый материаллар шактый кыйммәт тора. Үз өйләрендә эко-стильдәге интерьер булдырырга теләүчеләр артык зур чыгымнар тотмыйча да максатларына ирешә ала. Ничек кенә кызык тоелмасын, бүгенге көндә төгәл җайланмаларда искиткеч камил җиһазлар җитештерү мөмкинлеге булса да, кулдан ясалган әйберләр барыбер күпкә кыйммәтрәк бәяләнә. Беренчедән, алар уникаль һәм бары тик бер генә данәдә. Икенчедән, ул сезнең интерьер үзенчәлекләрен күздә тотып эшләнгән. Өченчедән, үз кулың белән эшләгән әйбер артык кыйммәткә дә чыкмый.

Чаллы шәһәрендәге бер фатирның кунак бүлмәсе мисалында әнә шундый кызыклы идеяләрнең тормышка ашырылуын күрергә мөмкин.






Җиһазлар

Фантазиягезне эшкә җигеп, беренче карашка яраксыз кебек тоелган агач кисәкләреннән дә оригиналь җиһазлар ясарга мөмкин. Рәсемдәге кызыклы тумбочкалар тирәк агачы слэбыннан ясалган. Слэб – таш эшкәртүдән алынган термин. Үзенчәлекле формалы һәм төрле җитешсезлекләре булган агач кисәген аңлата. Материалдагы тигезсезлекләр һәм җөйләр мөмкин кадәр ачыграк итеп күрсәтелә. Әлеге тумбочкаларны ясау өчен 50 мм калынлыгындагы слэб кулланылган. Нигезе исә 15 мм кисемле шакмаклы тимер торбадан ясалган. Тимер өлешләре алтынсу төскә буялган. Ә агач махсус май белән эшкәртелгән.

Диван кырыендагы кечкенә өстәл өслеге – чикләвек агачыннан. Өстәлнең аяклары тимердән эретеп ябыштырылган. Агач өслек май белән капланган. Күрәсез, кул астындагы материаллардан гына да әллә ниләр эшләп була.

Мондый җиһазларны үзең ясау әллә ни катлаулы түгел. Кибеттә исә андый авторлык эшләре бик кыйммәт тора.





Агач стеналар

Табигый төсләр һәм материаллар кешене табигатькә якынайта. Мондый интерьер тынычландыра, ялыктырмый. Рәис Мингалиев агач белән эшләргә ярата. Аны хәтта стеналарны бизәгәндә дә куллана. Агачның фактурасы үзе үк кызыклы. Өстәвенә, ул интерьерга җылылык өсти. Рәсемдәге стена панельләре төзелештән артып калган имән бруcларны кисеп ясалган. Әлеге вариантта төрле калынлыктагы брус кисәкләре фанера нигезгә иректе тәртиптә ябыштырылган. Кисемнәрнең калынлыгы 2–4–6 см. Соңыннан ул агачка тон бирүче состав белән буялган.

Текстиль

Эко-стильнең үзенчәлеге – табигыйлектә, дидек. Табигый тукымалардан тегелгән пәрдәләр, йон яисә ефәк җепләрдән тукылган келәмнәр мондый интерьерны тулыландыра гына. Пэчворк стилендә кулдан тукылган келәм бүлмәгә үзенчәлекле колорит һәм уңайлылык өсти. Ләкин, килешәсездер, андыйны алырга һәркемнең җае булмаска да мөмкин. Рәсемдәге бу борынгы келәм чынлыкта төрле кисәкләрдән җыелып, калын тукымага тегелеп ясалган корамадан гыйбарәт. Әлбәттә, башта һәр кисәк яхшылап чистартылган һәм чит-читләре эшкәртелгән. Теләк һәм фантазия булганда, инде тузып, яраксызга чыгарылган әйберләрдән дә әллә ниләр эшләргә мөмкин.

Декор

Интерьерга бөтенлек һәм төгәлләнгәнлек тәэсирен декорлар бирә. Бу кагыйдә эко-стильгә дә хас. Декорны да үзегез иҗат итә аласыз. Мәсәлән, бу поднослардагы бизәкләр майлы буяу белән кулдан төшерелгән. Буяуның тимер җирлекләр өчен ярашлысын гына сайларга кирәк. Кайдадыр, күгәреп, кирәксез яткан мондый подносларга әнә шулай яңа тормыш биреп була.

Декор сыйфатында үзенчәлекле формадагы пыяла шешә яисә банкаларны да кулланырга мөмкин.

Артык зур чыгымнар тотмыйча гына да өегезне үзенчәлекле һәм кыйммәтле итеп бизи аласыз.





Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

Борай, судак һәм...



Беренче карашка гап-гади шушы ризыклардан бәйрәм табынын бизәрлек, кунаклар «аһ» итәрлек сый әзерләп буламы? Әгәр дә фантазияң көчле, кайсы ризыкның тәмен ничек ачарга икәнен белсәң, әле ничек кенә була! «Бәхетле» челтәренең бренд-шефы Илгиз ГАЛИЕВны хәзерге заман татар кухнясының амбассадоры, ягъни илчесе дип атыйлар. Илгиз чынлап та үзенчәлекле оста. Ул үзебездә җитештерелгән һәм үстерелгән ризыкларны көтелмәгәнчә әзерләп, аларны табынга яңача тәкъдим итү юлларын эзли. Бу – әле бөтенләй яңа юнәлеш. Әнә шул рәвешле Илгиз татар милли кухнясының заманча йөзен булдыра. Онытыла төшкән, артык популяр булмаган кабак, борай, корт ише ризыкларга да оригиналь кулланыш таба. Әйтик, күпләребез бары гөбәдиядә яисә чәй табынында гына күреп ияләнгән корттан ул бөтенләй көтелмәгән яңа ризыклар әзерли. Хәтта гап-гади кебек тоелган борай ярмасының тәме дә бөтенләй башкача ачыла ала икән! 8 Март бәйрәме уңаеннан оста үзе генә белгән серләрен безнең белән дә уртаклашты. Автор үзе иҗат иткән оригиналь рецепт буенча әзерләве сезнең өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Кирәк

(бер порция өчен)

- 100 г судак балыгы филесы;
- 60 г борай ярмасы (полба);
- 30 г коры корт;
- 120 г 33 процентлы сөт өсте;
- 25 г укроп;
- 25 г петрушка;
- 100 г үсемлек мае;
- брокколи һәм черри помидоры;
- тәменчә тоз (адыгей тозы кулланылды).





Эш барышы

■ Судак балыгын чистартып, 100 граммлы кисәкләргә бүләбез (әзер филе гына да алырга була). Һәр кисәкнең ике ягына да тоз тидереп, пергамент кәгазьгә тезәбез. Өстеннән үсемлек мае сибеп чыгабыз.

■ Балыкны пергаментка төреп, 180 градус кызулыктагы мичтә 8 минут пешерәбез (мичне алдан кыздырырга кирәк).

■ Борай ярмасын юып, тозлы суда яртылаш әзер булганчы пешерәбез. Артык суын саркытып, 100 г ярмага 70 г исәбеннән сөт өсте салабыз (калганы соус өчен). Ботканы әзер булганчы пешереп бетерәбез.

■ Калын төпле кечкенә кәстрүлгә (сотейник) корт, тоз һәм калган сөт өстен салып, кайнатып чыгарабыз да, минут ярым сүрән утта пешерәбез.

■ Сөт өстендә пешеп йомшарган кортны блендер белән издерәбез. Яшел май өстибез. Яшел май 1 өлеш үләнгә (укроп белән петрушка) 2 өлеш үсемлек мае салып ясала. Майны башта 90 градуска кадәр җылытырга кирәк. Әзерлеген белер өчен, бер тармак укропны майга салып карыйлар. Май чыжылдарга тиеш түгел. Кайнар булса, чыжылдау беткәнче суыталар. Җылы майны үләннәр өстенә агызып, 2 минут (!!!) блендер белән ваклатабыз, майны сөзәбез.

■ Брокколи кәбестәсен 2 минутка кайнап торган суга салып, йомшартып алабыз. Суынгач, 2 миллиметрлы юка телемнәргә – слайсларга телəбез.

■ Черри помидорын урталай бүләбез.

■ Брокколи һәм черриның тышкы ягын бәләкәй газ баллоны ярдәмендә көйдереп алабыз. Газ баллоны булмаса, коры табага тезеп тә җиңелчә генә кызартырга мөмкин.

■ Табынга биргәндә сай тәлинкәгә башта борай боткасын, аның өстенә балык филесын куеп, корттан әзерләгән соусны сибәбез. Кызартып алган яшелчәләр һәм укроп яфраклары белән бизибез.

■ Ризыкларыгыз тәмле, бәйрәмегез күңелле булсын!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия



Үз сәламәтлеген кайгыртучы кешенең рационында яшелчәләрнең мөмкин кадәр күбрәк булырга тиешлеге сер түгел. Алардан әзерләнгән салат яисә гарнир белән беркемне дә шаккаттыра алмабыз, ә менә яшелчәдән чып-чын десерт ясасак? Дөрес туклану рубрикасының даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА бу эшкә бик теләп алына! Ләкин ни өчен нәкъ менә чөгендерне сайлавыбызны аңлар өчен, башта аның файдалы үзлекләрен барлыйк. Бик үзенчәлекле тамыразык ул, һәм аны башка бер генә яшелчә белән дә алыштыру мөмкин түгел.



Чөгендердән брауни

Чөгендердәге микроэлементлар җыелмасы башка яшелчәләрнекен кабатламый. Моннан тыш, әлеге файдалы матдәләр югары температурада да таркалмый һәм организм өчен кыйммәтле үзлеген югалтмый.

Гадәти азык чөгендерендә шикәр (7–9%), аксым, май, аминокислоталар, минераль матдәләрдән – калий, тимер, кобальт һәм башкалар бар.

Ул рубидий һәм цезий микроэлементына, антоцианга, C, B_1, B_2, P, PP витаминнарына, фолий кислотасына бай.

Чөгендер үз составында йод, тимер, цинк булуы белән кыйммәтле. Әлеге элементлар бүтән бер яшелчәдә дә чөгендердәге кебек үк күләмдә түгел. Табигый дәва сыйфатында, ул организмдагы кан ясалышы, җенес бизләре һәм матдәләр алмашы белән бәйле проблемаларны җиңеләйтергә булыша.

Чөгендернең файдасы

- азканлылыкны кисәтә һәм гемоглобинны арттыра;
- организмда яңа күзәнәкләр ясалышын яхшырта, яшәртү үзлегенә ия;
- ашкайнатуны һәм эчәкләрнең эшчәнлеген көйли;
- матдәләр алмашын көчәйтә, ябыктыра;
- организмнан токсиннарны чыгара;
- яман шеш күзәнәкләре барлыкка килүне һәм аларның үрчүен кисәтә;
- кан тамырларын чистарта;
- югары кан басымын һәм атеросклерозны дәваларга булыша;
- ялкынсынуларны киметә;
- авыртуларны баса, савыгуны тизләтә;
- депрессияне җиңәргә ярдәм итә;
- организмның көчен арттыра;
- күзнең күрү сәләтен яхшырта;
- составында йод булуы белән калкансыман биз авыруларын кисәтә.

Йә, ничек, чөгендердән шоколадлы брауни әзерлибезме?

Кирәк:

- 150 г чистартылган чи чөгендер;
- 100 г солы оны (солы лачавын кофе тарткычтан вакларга була);
- 50 г какао порошогы;
- 1 чәй кашыгы камыр көпшәкләндергеч (разрыхлитель);
- 1 йомырка һәм 2 йомырка агы;
- баллы тәм бирү өчен җиләк-җимеш: хөрмә, банан, ширбәт яисә шикәр алыштыргыч;
- бер чеметем тоз;
- 50–150 мл сөт яисә чиста су. Суны аз-азлап кына салырга кирәк, кашык белән аз гына болгатып җибәргәндә, камыр формага үзе агарлык куелыкта булырга тиеш.

Эш барышы

- Чөгендерне йомшарганчы мичтә пешерәбез. Аны фольгага төрергә яисә пешерү өчен махсус капка тыгарга (пакет для запекания) мөмкин.
- Суынган чөгендерне блендерда ваклатабыз, шунда ук йомырка, тоз һәм баллы тәм бирүче ингредиентны салабыз.
- Вакланган чөгендергә сөт яисә су, он, камыр көпшәкләндергеч һәм какао кушабыз.
- Форманы майлап, барлыкка килгән камырны агызабыз.
- 170 градус кызулыктагы мичтә 30 минут пешерәбез.
- Суынгач, кисәкләргә кисәбез.
- Табынга биргәндә брауни өстенә шоколадлы балсыз сироп сибәргә, чикләвек белән бизәргә була.

Тәмле булсын!

Фото: Камилә Димөхәммәтова

балык хатын-кыз

Нәфислек, хислелек, зирәклек, аралашучанлык – Балык йолдызлыгында туган хатын-кызларга хас төп сыйфатлар шушылар. Аларның көче – көчсез булып күренә белүдә. Ул үз бәясен яхшы аңлый, үзе өчен кызыксыз кешеләр белән аралашудан кача. Балыклар тынычлык ярата, үзләренә бик таләпчән. Шул ук вакытта бик ярдәмчелләр дә. Еш кына аларның бу сыйфаты белән тирә-юньдәгеләр файдаланып калырга тырыша.

Мәхәббәт

Хисле һәм сөйкемле Балыклар ир-атлардан игътибар аз булуга зарлана алмый. Алар тумыштан ук яхшы психолог – үзләренә җәлеп иттерә беләләр. Ир-егетләрнең игътибарын кабул итсәләр дә, тиешле дистанциядән артыгын якынайтмыйлар. Алар үз идеалларын яхшы белә һәм андый кешене еллар буе да көтәргә риза. Ә инде гашыйк була икән, Балыкны танырмын димә. Элеккеге салкын акыл урынына бары хисләр генә идарә итәчәк.

Гаилә

Балыклар – менә дигән хуҗабикәләр: ирләре дә, балалары да караулы, өйләрендә тәртип. Гаиләсе аның өчен беренче урында. Балыклар бөтереп алган дәртне түгел, ә чын хисләрне, җылы мөнәсәбәтләрне ныграк бәяли.

Карьера

Балыклар нәрсә белән шөгыльләнәселәрен бик уйлап сайлый. Ләкин хыялдагы эш белән чынбарлык туры килмәскә мөмкин. Шуңа да еш кына Балыкларның күңеле кайтучан. Үзе теләгән эш белән шөгыльләнү өчен күп очракта тәвәккәллек җитеп бетмәү дә аяк чала. Ә инде күңеленә ошаган эшне таба икән, аны берни дә туктата алмаячак. Эшкә килгәндә, алар бик тырышлар, бөтен көчләрен биреп хезмәт куялар.

йолдызнамә апрель

Кучкар. Ай башында шәхси тормышта үзгәрешләр көтелә. Профессиональ өлкә икенчерәк планга күчәр. Карарларны ашыгып кабул итмәгез. Бу айда башкарган кечкенә генә эшнең дә нәтиҗәсе зур булырга мөмкин.

Үгезбозау. Айның беренче яртысы вакыйгаларга бай булыр. Ә менә икенче яртысында үзегезне күрсәтү өчен шәп кенә форсат килеп чыгар. Тормышны үзгәртергә теләсәгез, моның өчен хәзер бик яхшы вакыт.

Игезәкләр. Сездән игътибарлылык сорала. Ниндидер мөһим мәсьәләләрне хәл итәсе булыр. Мәшәкатьле булса да, уңышлы чор. Финанслар ягыннан борчылырлык түгел, ә менә яңа танышуларга сак карагыз.

Кысла. Яңа үрләргә ирешү өчен тырышлыгыгыз да, көчегез дә җитәрлек. Ай уртасы – яңа мөмкинлекләр чоры. Бу вакытны ычкындырмагыз, бәхетегезнең нигезен төзеп калдырыгыз.

Арыслан. Бу айда барысы да сезнең тирәли әйләнә кебек. Уйлар бөтереп алыр. Фәлсәфәгә бирелеп, тормышның мөһим якларына игътибарны киметеп җибәрүегез бар. Күрә белсәгез, алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылачак.

Сөмбелә. Көтелмәгән очрашуларга бай вакыт. Мондый сюрпризлардан югалып калуыгыз да ихтимал. Ә икенче яктан, нәкъ менә көтелмәгән хәлләрдән башкача фикерләү сәләтегез ачылып китәр.

Бизмән. Приоритетларны дөрес билгеләү мөһим. Беренче урында якыннарыгыз булырга тиешлеген онытып җибәрмәгез. Хисләр бик киеренке, кешеләр белән аралашуда кыенлыклар туарга мөмкин. Үзегезне кулда тотарга тырышыгыз.

Чаян. Катлаулы чор. Профессиональ даирәдә торгынлык сизелә. Үз-үзегездән канәгатьсезлек кичерерсез. Тормышның тискәре якларына артык игътибар бирмәскә тырышыгыз. Үзегезне башка өлкәләрдә сынап карарга була.

Укчы. Ак һәм кара полоса чиратлашып бара. Бу кешеләр белән мөнәсәбәтләргә дә, эчке халәткә дә кагыла. Җәмгыятьтә үзегезне күрсәтү һәм ихтирам казану өчен мөмкинлек туар. Яңа эшләргә керешү өчен яхшы вакыт.

Кәҗәмөгез. Әзер торыгыз: шактый ыгы-зыгылы ай булыр. Сез берни дә үзгәртә алмыйсыз, ситуациягә үз җаена куегыз. Нәрсәнең мөһимрәк булуын ачыклап, өстенлекне генә дөрес билгеләгез.


Сукояр. Комфорт зонасыннан чыгарга туры килер. Үзегезнең нәрсәгә сәләтле булуыгызны күрсәтү өчен җай чыгарга тора. Көтелмәгән хәлләр барысы да сезнең файдага.

Балык. Тормышның матди ягы беренче планга чыгар. Капиталыгызны арттыру өчен кулдан килгәнчә тырыша торган вакыт. Моның нәтиҗәсе дә озак көттермәс. Әмма җиңелгә генә өметләнмәгез.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.







СВЕТЛАНАНЫҢ МОГҖИЗАЛАР ИЛЕ

Көмешсу төс белән язган картинасындагы уенчык аю тоткан кыз образына карап кына да Светлана Румакның үзенчәлекле, нәфис хатын-кыз дөньясын иҗат итүен аңларга мөмкин! Светлана 1969 елда Украинада туган. 1974–2001 елларда – Чаллыда, ә 2001–2005 елларда Казанда яшәгән, Россия сынлы сәнгать академиясенең Казандагы филиалы остаханәсендә стажировка үткән.

Башлангыч сыйныф укытучыларының балаларны сул кул белән язудан тыя торган елларда укыган ул. «Сул кул белән яза башласа, кулына китереп сук!» – дигән укытучы Светлана янәшәсендә утырган кызчыкка. «Син борчылма, авырттырырлык итеп сукмам», – дип юаткан партадашы. Ул таләпләр күптән артта калды инде хәзер. Светлана сул кулы белән дә, уңы белән дә бик яхшы яза, рәсемнәр ясый, картиналар иҗат итә. Бүген ул Мәскәүдә үз арт-мәктәбендә укыта. Анда белем алучылар, укытучылары кебек үк, үзенчәлекле әсәрләр язмаса да, дәресләрен көтеп алалар. Рәссам исә безне картиналарындагы бик тә үзенчәлекле, шул ук вакытта бераз сәеррәк образларыннан төзелгән сәнгати дөньяга әйди. Һәм без, Алисадай, серле могҗизалар иленә эләгәбез. Бу ил – әкияти дә, декоратив та, анда борынгы картиналардан күчкән образлар да, төрле фильм каһарманнарына охшаш затлар да җитәрлек. Иҗатында нибары берничә төс кулланып кына да рәссам безне төрле чорларга сәяхәткә алып чыга. Билгеле, анда алтын һәм ачык төсләр дә өстенлек итә, шуңа күрә без картиналарда «алтынсуга манчылган ир балаларны» да («Алтын малайлар»), җирән һәм аксыл чәчле уйчан кызларны да («Кыз туганнар») очратабыз. Өстәлдәге чәчәкләр, китаплар, тыгыз итеп бәйләп куелган көндәлекләр дә күпләргә таныш кебек тоелыр. Рәссамның иҗат ысуллары башкаларныкыннан шактый аерылып тора. Бәлки, шуңа күрә дә аңа уңыш һәрчак елмаядыр. Светлананың үзенчәлекле эшләрен Нидерландта, Франциядә, Европаның башка илләрендә, АКШта күргәзмәләрдә күреп сокланалар. Уңыш өчен сәнгатьне аның кебек ярата белергә кирәк шул! Бу уңайдан рәссамның үз уй-фикерләре бар.

«Картинаң башкаларга бик позитив, игелек нурларына коенган булып күренәчәк, ләкин аны язганда күпме борчылганыңны, яңадан тагын бер кат буяганнарыңны, үзүзеңне битәрләгәннәреңне үзең генә беләчәксең... Әмма моңа карап сынлы сәнгать агенты булудан туктамаячаксың. Чөнки үзем дә бит, әйтик, үз арт-мәктәбемә укучылар җыям, әнә шулай Светлана Румак дигән кечкенә очкычның бортына йолдызчыклар тезәм. Шат һәм бәхетле рәссамнар күбәя барган саен, бу дөньяда матурлык та артачак! Чөнки сынлы сәнгать дәвалый... Ул шундый көчкә ия!.. Бүгенге көн мөмкинлекләре белән хозурланып яшим. Рәссамнар бәхетле алар, чөнки тылсымлы бер «ишегебез» бар. Аның аша, берничә сәгатькә булса да, хыял иленә чыгабыз, җирдәге бу дөнья ритмыннан бушанып, үз дөньябызны тудырабыз... Бар да гади генә: яраткан көйне куясың, үләннәрдән тәмле чәй яисә кардамонлы каһвә пешерәсең... Һәм иҗатка чумасың».

Киндерләрдә сурәтләнгән геройлар рәссамның үзе кебек үк: һәрчак нидер хакында уйланалар, яшәешләренә тын гына сокланалар. Анда бу гасырның шаушуы, ыгы-зыгысы, таҗлы вирусы... берсе дә юк! Талантлы якташыбыз Светлана Румак иҗаты Галактикасында – хатын-кыз планеталары гына диярлек. Һәм ул үз тамашачысына шуның белән якын!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА













СВЕТЛАНА РУМАК

2021 

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ


Фото: Анна Арахамия

Галина ПЕТРОВА. Балтач районы, Кече Лыза авылы

Галина Денисовна лаеклы ялда булса да, авыл тормышында кайнап яши. Әле мәдәният йортында, әле мәктәптә, ул да булмый, ансамбленә йөрүче балаларны җыеп, Казанга – фестивальгә үк чыгып китә. Танышуга ук: «Үзегезгә ничек җайлы, шул телдә сөйләшик!» – дип гаҗәпләндерде Галина Денисовна. Үзен ул ярым удмурт, ярым рус, ярым татар дип саный. Озак еллар китапханәдә һәм клубта эшләгән әнисе Зинаида рус кызы булган. Удмурт егетенә кияүгә чыгып, матур гаилә корганнар, балалар үстергәннәр. «Әнием дә өч телдә иркен сөйләште. Сәхнәдә татарча да, удмуртча да җырлый иде. Шуңа күрә безнең дә татарча белүебез табигый. Гомеребез татарлар арасында үтте. Көн дә аралашкач, ничек инде өйрәнмисең телне! Тыңлый-тыңлый, сүзләр үзеннән-үзе аңлашыла башлый. Миңа татар теле дә, удмурт теле дә, рус теле дә бик якын. Әңгәмәдәшем кайсы милләттән булса, үзеннән-үзе шул телгә күчәм, сизми дә калам», – ди ул. Галина Денисовна үзе дә матур җырлый. Әнисеннән аңа яңгыравыклы матур тавыш күчкән. «Җырлыйбыз да, биибез дә, спектакльләр дә куябыз», – дип горурлана ул авылдашлары белән. Галина ханымның ире Ринат – татар милләтеннән. Мәдәният йортында гитаристлар түгәрәген җитәкли. «Киявем дә татар егете, – дип елмая Галина Денисовна. – «Әни» дип кенә тора. Балтачта яшиләр. Оныкларым Раил белән Риянаның да өч тел белеп үсүенә куанам. Тел бит ул ачкыч. Һәр халыкның никадәр бай мәдәнияте бар. Телен белсәң, син шул бай мәгарәнең мәңгелек хәзинәсеннән файдалана аласың».


Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

